Безнең МИРАС

ISSN:2500-011x

08

август 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

17 июльдә Татарстан Республикасының Балтач районы Бөрбаш авылында Сабан туе – IX Мөселман балалары бәйрәме оештырылды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Балтач районы башлыгы Рамил Нотфуллин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Балтач районы имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев катнашты.

Сабыйларның ихлас бәйрәме

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас

12 +

8(55)

август 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

22

52 **МИЛЛӘТНЕ КАЙГЫРТУЧЫ БАСМА.**
Әгъзам Фәйзрахманов

86 **НУРЛЫ СӘХНӘДӘ ИҖАТ НУРЫ.**
Әхтәм Зарипов

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Харрас Әюп**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Хан сарае.**
6 **Һади Атласи турында яңа чыганаклар.** *И.Гафаров*
13 **Һади Атласиның «Йолдыз» газетасында басылган ике мәкаләсе**
17 **Йосыф Акчурин йорты.** *Н.Таиров, И.Таиров*
20 **Изге Синодның Православлау Грек-Россия Чиркәвенең тугрылыклы балаларына мөрәҗәгате илә граф Лев Толстой турындагы 1901 ел 20-22 февраль карары**
22 **Синодның 20-22 февраль карарына һәм шул уңайдан миңа килгән хатларга җавап.** *Л.Толстой*
30 **Казан губернасы керәшеннәре ышануларында мәҗүсилек күренешләре.** *С.Максимов*
38 **Иске Кулаткы**

ТАТАР ГАМЕ

40 **Илдар Гыйльметдинов: «Булачак һәр педагогны әүвәл педколледжда укытыр идем...»**

ТАТАР МӨҺАҖИРЛӘРЕ

48 **Хәмит Зөбәер Кошай.** *Ф.Гаффарова*

«БЕЗНЕҢ МИРАС»КА – 25

52 **Милләтне кайгыртучы басма.** *Ә.Фәйзрахманов*
58 **Мирасыбызның колачы киң.** *М.Госманов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

60 **Сүз һәм сурәт.** *Н.Дунаев*

ӘДӘБИ МИРАС

64 **Кутадгу билик. (Котаиткыч белем).** *Й.Баласагуни*
68 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
74 **Сабирҗан агай: 1906 сәнәдә булган ачлыкны тасвир кыйлган роман.** *К.Бикколый*

СӘНГАТИ МИРАС

86 **Нурлы сәхнәдә иҗат нуры.** *Ә.Зарипов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча
мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

92 **Якты күңелле олуг җырчы.** *А.Хәкимова*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

98 **Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Габденнасыйр Курсави, Шәмсетдин Зәки, Әхмәтҗан Тубыли, Мифтахетдин Акмулла.** *Р.Мөхәммәтша*

ХӘТЕР САГЫНДА

102 **ТАССР мирасы.** *Г.Җәләлева*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

104 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
106 **Фидакяребез.** *Р.Акъегет*

ТАТАР ҖЫРЫ

109 **Сагыштан туган сабырлык.** *А.Хәлим*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның август ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Вак-вак ләтыйфәләр һәм хикәя кисәкләре.** *Р.Шәрәфиева*

118 **Мирасворд**

119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Август*
120 **Содержание. Content**

Заказ №М-1821. Тираж – 1825 данә. Формат 70 X 108 $^1/_{16}$
Басарга кул куелды: 26.07.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Болгар. Ак мәчет». 2014 ел.
Киндер, майлы буяу. *Әлфия Ильясова рәсеме*

ХАРРАС ӘЮП (1946-2008)



*****

Артык та һәм ким дә түгел: Дөнья – бары бер гомерлек; Җирдә безгә бертуктамый Гомер буе йөгерерлек!..

*****

Илләр имин чакта – бәхетле мин, Бәхет барда җирдә – мин исән!..

*****

Гөл тамыры җирдә була, Җырда була халык җаны.

*****

Шушындадыр бу дөньяның Бәрәкәтләр ятар җире: Уятадыр, уйлатадыр, Юатадыр татар җыры...

*****

Илендә бер аты калмаганда, Алмаштырды җырлар бар атны. Ат тарталмас кайгы-хәсрәтләрне Җыр күтәрде, җырлар таратты.

*****

Булыр-булмас арба юл бозар, ди,
Булыр-булмас мулла дин бозар...

*****

Барыбыз да – ата балалары, Һәркайсыбыз – бала атасы. Никадәрле тармаклансак та без, Тамырыңа кире кайтасы.

*****

Язмыш бердер барлык чорларда да: Агач булса – балта табыла. Ләкин белә тарих агачларның балталарны ваткан чагын да...

*****

Гомер буе кеше йөгермәктә, Бөтен кургәннәре – бер йөрәктә. Язмышларны узып киталмыйбыз, Никадәрле генә йөгерсәк тә!..

*****

Белеп торам: елау – бәхет түгел,Кызыкмыйдыр һичкем елауга; Тик шунсы бар – безнең бу гомердә Бәхет түгел елый алмау да.

*****

Тыштан күпме ялтыраса да ул, Мәкерлекнең һаман эче кара.

*****

Заманнарга тынгылык юк икән, Җир йөзендә яраланса халык...

*****

Киткәннәрнең йөрәк уты булып, Киләчәккә бара исәннәр...

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Болгар. Хан сарае

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

XIV гасырның беренче яртысында Болгар архитектура истәлекләренең үзәк комплексы тулысынча формалашкан. Аңа Хан сарае – почмакларында багана-пилоннары булган монументаль корылма да кергән. Бу – турыпочмак рәвешендәге (эчке үлчәмнәре 24 метрга 29 метр) бина, шәһәрлекнең өске платосы кырыенда, Җамигъ мәчетеннән төньяк-көнчыгышка таба, Кызыл пулат өстендә урнашкан. Ул төньяктан көньякка сузылган, почмакларында түгәрәк баганалары булган турыпочмаклы формадагы кирпеч-таш корылма калдыкларыннан гыйбарәт. Бу Үзәк Азия, Иран, Һиндстан сарай комплексларына хас типик ансамбль.

Казу эшләре ачыклаганча, бина көнбатыш дивары астыннан төньяктан көньякка таба үтә торган элеккеге оборона чокыры урынында төзелгән. Ул чордан диварлар, вак буттан төзелгән, өстенә известь измәсе коелган нигезләр, цоколь сакланып калган. Диварның тышкы ягы – бик яхшы тезелгән ак таш блоклардан, эчке ягы – кирпеч плинфадан төзелгән, үзәк өлеше бут кирпечләреннән известь измәсе кулланып ясалган. Аннан соңгы чорда михраб урынына көньяктан зур тамбур рәвешендә ишек тоташтырылган.

Бу бинада археологлар 1994 елда казу эшләре алып барган, 1000 кв. метрдан артык җирне ачканнар. Биредә табылган әйберләр Хан сарае төзелешенең XIII гасыр уртасында башлануын раслый.

Тикшеренү барышында объектны 1227 елдан Алтын Урданың хакиме, Җүчи улы, Чыңгыз хан оныгы булган Батый хан (1208-1255) сарае комплексына керүен раслый торган дәлилләр табылган.

Комплексның үзенчәлеге һәм табылдыклар шуны раслап тора. Анда XIII гасыр уртасына караучы әйберләр, шул исәптән 1240-1259 елларда сугылган тәңкәләр табылган.

2011-2012 елларда «ТСНРУ» белгечләре сакланып калган нигезләрне консервацияләү, бинаның юкка чыккан элементларын өлешчә реконструкцияләү буенча эшләр башкарды: тышкы диварлар һәм почмактагы баганалар ак таш блокларның 1 нче-3 нче рәтенә кадәр күтәрелеп, плинфа кирпечләрдән тезелгән эчке диварга тоташтырылды, археологлар казып чыгарган корылмаларның һәм бинаның эчке өлешенең фрагментлары музейлаштырылды. ■

Һади Атласи турында яңа чыганаклар

Иршад Гафаров

Тарих – төпсез диңгез кебек. Күпме тирәнгәрәк төшәсең, казынасың, эзләнәсең, ул шулкадәр күбрәк серен ача. Бер тарихчының да: «Булды, бөтен нәрсә ачыкланды, белмәгән мәгълүмат калмады, инде ял итсәң дә ярый!» – дип әйткәне түгел, хәтта мондый уйны башына китергәне дә юк.

Чүпрәле районында исеменә Чәке сүзе кергән берничә авыл бар: Түбән, Югары, Иске һәм Яңа Чәкеләр. Бу өч авыл янәшә, бер-берсенә кушылып урнашкан, аларны Якла (кайбер чыганакларда Аксу) елгасы гына аера.

Әлеге авылларның ут күрше булуы архив мәгълүматларында да теркәлгән. Бу турыда «Межевая книга дачи деревень: Старая Чувашская, Старая Татарская и Нижняя Чекурская»да язылган. Әлеге чыганактан бер өзек китерәбез: *«1884 года ноября 25 дня по указу Его Императорского Величества Государя Императора Александра Александровича, самодержца Всероссийского, и прочая, и прочая, и прочая, утверждена межа и эта межевая книга составлена Курмышским уездным Земледельческим Коллежским Асессором и кавалером Иваном Вентор, на участок Симбирской губернии Буинского уезда под названием деревень* ***Старое Чувашское, Старое Татарское*** *и* ***Нижнее Чекурское…****»*

1909 елда җирне яңадан бүлү үткәрелгән. Бу мәгълүматтан да өзек китерәсебез килә: *«1909 г. октября 7 дня мы нижеподписавшиеся жители д.Нижнее Чекурское на сходе при присутствии сельской старосты Идиятуллы Сулейманова 150 чел. из 196, имеющих право голоса в присутствии земельного начальника 6 участка рассмотрели проект добровольного раздела, принадлежащего* ***д.Старое и Нижнее Чекурской*** *земли между стоящим в этих 3-х обществах вместе с составленным на этот раздел землемером М.Г.Ивановым планом. Голосовали против – нет, единогласно»*.

Чәке турындагы без тапкан әүвәлге мәгълүмат 1665 елга карый: *«Слобода Чекурская Чюрачка, Семенов Вобатаров он жа, на речке на Аксе»*. Дөрес, әлегә аның кайсы торак пунктка караганын төгәл белә алмадык.

Элек Иске Чәке авылында татарлар һәм чуашлар бергә яшәгән, бередә ике мәчет эшләгән. Хәзерге заманда исә

авылда бары тик чуашлар гына яши. Үткән гасырның 20 нче елларында авылның татарлар яши торган өлешен Югары Чәке дип атый башлыйлар. Анысын республикабыз архивында сакланган чыганаклардан белештек. Бу, үз чиратында, кайбер аңлашылмаучанлык, ялгышлар китереп чыгара.

Якташыбыз, күренекле галим, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласиның тормыш юлы турындагы язмаларда аның туган авылы Иске Чәке яки Түбән Чәке дип күрсәтелә.

Заманында аны: Иске Чәке авылында туган, дип язган идем. Әмма ялгышканбыз икән. Кабат 1858 елгы Түбән Чәке авылының «Ревизская сказка»сын карап, тикшереп чыктым һәм соңгы биттә мулла **Хәмди Алтынбаев** һәм аның **улы Мифтахетдин** турында мәгълүматка тап булдым. Анда: *«Семейство это перечислено в 1851 г. из д.Верхние Каракитян Буинского уезда»*, – дип язылган. Димәк, әлеге гаилә берничә ел элек үк Каракитәдән Түбән Чәкегә күчеп килгән, Һади биредә 1876 елда дөньяга аваз салган. Галимне Иске Чәкедә туган дип санаганда да, аны «хәзерге Югары Чәке авылында» дип тәгаенләү дөрес булыр иде, чөнки беренчесендә чуашлар гына яши.

ТР Милли архивында 1886-1887 елларга караган «Дело Буинского уездного по воинской повинности присутствия по призыву молодых людей на службу по Городищенской волости» исемле эштән без Түбән Чәке авылында указлы мулланың Мифтахетдин Хәмди улы булганын ачыкладык. Шулай итеп, тагын бер мәртәбә Мифтахетдиннең әтисе хезмәтен дәвам иткәнлегенә, Һадинең Түбән Чәкедә туганына инандык.

Соңрак, Ульяновск өлкәсе дәүләт архивына мөрәҗәгать итеп, Сембер губернасы Түбән Чәке һәм Югары Каракитә авылларының халык санын алу кәгазьләре белән дә таныштым. 1834 елда Хәмдинең хатыны **Зарифә** (1786) дип теркәлгән. Ир балалары **Аит** (1814) һәм **Мифтах(етдин)**, кыз балалары **Салихә** (21 яшь) һәм **Әсхап** (5 яшь) булган. Шулай итеп, Мифтахетдинның әнисе – Хәмдинең беренче хатыны Зарифә икәнлеген белдек. Соңрак Хәмдинең икенче хатыны **Маукай Хаяр кызы** икәнен дә ачыкладык.

Мифтахетдингә бу вакытта 17 яшь булып, ул аннан алдагы халык санын алу документында «новорожденный» дип язылa. Шуңа да ул 1816 елгы «Ревизская сказка»да телгә алынмый.

Хәмдинең **Аит** исемле улы 1816 елда 2 яшендә була. Ләкин аның гомере бик кыска булып, 1819 елда фани дөньядан бакыйлыкка күчә. Шуңа да аның исеме бүтән чыганакларда искә алынмый.

Инде Хәмдинең үзенә килсәк, 1816 елда аны 30, ә 1834 елда 48 яшендә икәнен язалар. Димәк, ул 1786 елда дөньяга аваз сала. Хәмдинең әтисе, алда искә алынган мәгълүмат нигезендә, Алтынбай булып, 1750 елда туган, дип исәпләдек.

Шуннан бездә әлеге нәселнең мөмкин кадәр булган нәсел-тамырын барларга кирәк, дигән фикер туды. Бу турыда Мәскәүгә, Рәсәйнең борынгы актлар саклана торган архивка мөрәҗәгать иттек. Эзләнүләр бушка китмәде. Ниһаять, атаклы якташыбызның ерак бабаларын ачыкладык.

1762 елда үткәрелгән җан алу мәгълүматларыннан күренгәнчә, бу вакытта Югары Каракитә авылында 12 яшьлек **Абдулла улы Алтынбай** яшәгән. Шул ук мәгълүматтан әлеге чорда авылда мондый исемдәге бүтән кеше булмавын белдек. Шуннан соңгы елларда үткәрелгән җан исәбен алу мәгълүматларында теркәлгән Алтынбайлар бер нәсел кешеләре, дигән нәтиҗәгә килдек.

1747 елдагы икенче ревизия мәгълүматларыннан **Мостафа Кандрат**, аның энеләре – 46 яшьлек **Мортаза**, 39 яшендәге **Абдулланы** таптык.

1723 елда (әле патша Петр I исән чак) үткәрелгән җан исәбен алу кәгазьләре дә сакланган булып чыкты. Аннан күренгәнчә, Кандратның 40 яшендәге **Алмат** исемле улы да була. Буыннар арасын уртача 25 ел дип алсак, Кандратны 1658 елда туган, дип чамаларга мөмкин.

Билгеле, кемнедер Кандрат исеме шиккә салырга мөмкин. Бу рус исеме бит... Тик шуны ассызыкларга кирәк: беренчедән, бу вакытта Югары Каракитә авылында йомышлы татарлар гына яшәгән, дип күрсәтелә; икенчедән, «Книга строельная»да 1649 елда «Каракоте» авылында йомышлы татарлар – **Васка Богданов** һәм аның иптәшләре, барлыгы 50 кешегә (ир-атка) 3 мең 180 чирек сөрү җире бирелү турында мәгълүмат бар. Шуның өстенә әлеге мәгълүмат бу чорда Каракитә авылының булуын да раслый, дип әйтә алабыз.

Икенче бер чыганакта шул ук чорда йомышлы татарлар **Ишмайка Васильев** һәм аның 20 иптәшенә 400 чирек (600 дисәтинә) җир бүленеп бирүе турында языла. Сүз хәзерге Чүпрәле районының Зур Чынлы авылы турында бара. Ике чыганакта да «служилые татары» дип язылсалар да, рус исем-фамилияләре бирелә. Шулай булгач, безнең карашка, язучы кеше алда атап үтелгән исемнәрне русчалатып яки кушамат нигезендә язган булырга тиеш. Мондый күренеш белән безгә бер генә тапкыр очрашырга туры килмәде. Шуңа да җан исәбе алу кәгазьләрендәге кайбер төгәлсезлекләргә укучыларның исе китмәсен иде.

Инде укучылырыбызны Атласиның бабалары турындагы табылган мәгълүматлар белән таныштырырга кирәк, дип саныйбыз. Алда искә алган Кандратның олы улы Алмат сукыр була. 1723 елда аның сигез яшьлек **Әликә**, алты яшьлек **Күчүм**, алты айлык **Батырша** исемле уллары теркәлгән.

Шулай ук Алматның 30 яшьлек **Мостафа** исемле энесе, ә аның ике яшьлек **Усман**, ике айлык **Али** исемле уллары күрсәтелә. Мостафаның 25 яшьлек **Мортаза**, 15 яшьлек **Абдулла** исемле энеләре турында да хәбәр ителә.

Мортазаның 1747 елда 18 яшьлек **Бакый**, 8 яшьлек **Муса**, 6 яшьлек **Ризван**, 5 яшьлек **Бакай**, 4 яшьлек **Биккол** исемле уллары булган. Абдулланың исә бу вакытта 7 яшендәге **Җәлил**, 1 яшьлек **Али** исемле уллары теркәлгән.

Өченче җан исәбен алу кәгазьләрендә (1762) без **Абдулла гаиләсенә** игътибар итек. Алардан күренгәнчә, бу вакытта 16 яшь кенә булуга да карамастан Алиның алты айлык **Бәгди** исемле улы була. Хатыны шул ук авылның **Зария Мортаза кызы**. Бирердә Абдулланың кызлары **Мукилә** (25 яшь, ул Тимерсән авылының **Искәндәр** исемле йомышлы татарында тормышта була), 20 яшьлек **Гөлшанрия**, 4 яшьлек **Зәкия** турында да мәгълүмат табылды. Шулай ук чыганакта Алтынбай турында да языла. Аңа бу вакытта 12 яшь була.

1782 елгы җан исәбен алу кәгазьләрендә Алтынбайга 31 яшь, дип язылган. Аның шул ук авылдан алган 30 яшьлек **Сәлия Абдулла кызы** исемле хатыны була (1752). Алтынбай бик яшьли – 14 яшендә 13 яшьлек кызга өйләнгән булып чыга, чөнки җан исәбен алганда аларның бу вакытта 17 яшьлек **Бәшир** исемле уллары (1765) теркәлгән. Аңардан башка ир белән хатынның 7 яшендәге **Мөхәммәт**, бер яшьлек **Хәмит** исемле уллары да була.

Аның хуҗалыгында шулай ук 1742 елда туган, Бизнә авылына кияүгә чыккан **Гөлшанрия** исемле апасы, 1759 елгы, Чәке авылына тормышка бирелгән **Гөлзәния** исемле сеңлесе күрсәтелә.

1816 елгы җан исәбен алу мәгълүматларына килсәк, бу вакытта Алтынбайга 64 яшь, дип укыйбыз. Билгеле, бирердә төгәлсезлек бар, ләкин калган мәгълүмат белән чагыштырсак шулай килеп чыга да. Чөнки аның улы Бәширгә

бу вакытта 50 яшь була, без алдарак Алтынбайның 14 яшьтә өйләнүе турында әйткән идек. Бу вакытта Бәширнең, абыйсы Хәмит каралты-курасы янәшәсендәге аерым хуҗалыкта яшәп, 19 яшендәге **Зәбир** исемле улы, 16 яшендәге **Тутия**, 8 яшендәге **Мәүлия** мсемле кызлары турында мәгълүмат бирелә. Ә 1811 елгы җан исәбе алудан соң туган улы Әхмәт 1812 елда вафат була.

Алтынбай бу вакытта **Хәмит** исемле улында яши, дип күрсәтелә. Хәмитнең 1810 елда туган улы **Хаби** 1812 елда фани дөньядан китеп бара. Гаиләдә тагын өч яшьлек **Даут**, ике яшьлек Абидулла исемле угыллары да була. Алтынбайның икенче хатыны **Сафура** (1761), Хәмитнеке **Нәзбүхан** (1786) исемле.



1782 елгы җан исәбе алу кенәгәсендә Алтынбай Абдулла улының гаиләсе турында мәгълүмат

Бәширнең күршесендә **Хәмди** исемле энесе дә яшәгән. Бу вакытта аңа 30 яшь була. Әлеге йортта без аның 30 яшьлек **Зарифә** исемле хатыны, 3 яшьлек **Сәлихә** исемле кызы һәм 2 яшьлек **Аит** исемле улы белән бергә яшәгәнен күрәбез.

Инде 1834 елгы җан исәбе алу мәгълүматына күчик. Аннан күренгәнчә, өч бертуган Алтынбай уллары элеккечә үк ут күрше булып яши. Тик бу вакытта инде аларның әтиләре исән булмый, ул 1819 елда бакыйлыкка күчә. Хәмитнең Даут исемле улы да 1822 елда вафат була. Шул ук вакытта аның соңгы җан исәбен алудан соң туган **Нәүмәт** (1818), **Давыд** (1822), **Әхмәт** (1824), **Вәлит** (1827) исемле улларын, **Хөсни** (1820), **Мәрьям** (1831) исемле кызлары бар икәнен беләбез.

Язмалардан күренгәнчә, Бәшир 1826 елда фани дөньяны куйган. Аның улы Зәбирнең гаиләсе арта: уллары **Җәббар** (1816) һәм **Зәйнетдин** (1834), кызы **Гарифә** (1825) дөньяга килә. Бәширнең йортында хатыны **Мөнәвәрә** (1809), каенанасы **Назыма Әбдрәшит кызы** (1780), балдызлары **Миләйхан** (1811), **Гүстәрә** (1824) бергә яшәгән.

Хәмди гаиләсенә килсәк, 1817 елда аның **Мифтахетдин** исемле улы, 1829 елда **Әсхап** исемле кызының тууы турында мәгълүмат табабыз.

Инде яңадан 1858 елның 5 мартында Түбән Чәке авылында үткәрелгән җан исәбе алу кәгазьләренә әйләнеп кайтыйк. Аңардан күренгәнчә, Хәмди улы Мифтахетдинның гаиләсендә яши. Биредә 28 яшьлек **Әсхәпҗамал** исемле кызы да булуы күрсәтелгән. Мифтахетдинның хатыны **Мәрхәмә Хәмзә кызы** 37 яшьтә дип күрсәтелә. Бу вакытта Мифтахетдинның 13 яшьлек **Сафиулла** исемле улы, 6 яшендәге **Бибинәсимә**, 5 яшьтәге **Бибимотыйга**,

1 яшьлек **Бибимагибә** исемле кызлары була. Шуны да ассызыклап үтәргә кирәк, әлеге гаиләне исемлеккә иң соңыннан, 67 нче сан астында язганнар.

Шулай ук 1858 елның 12 апрелендә Югары Каракитә авылында җан исәбен алу кәгазьләрендәге Һ.Атласиның туганнары турындагы мәгълүматка да тукталырга кирәк, дип саныйбыз. Бу вакытта алар ике хуҗалыкта язылалар.

Алардан күренгәнчә Хәмит (1853 елда вафат) хуҗалыгында 19 кеше яши. Шулардан беренче улы **Абидулла** белән **Хафизә Халик кызы**ның **Вәлиулла** (1840), **Хәйрулла** (1846), **Нуретдин** (1849), **Камалетдин** (1855), **Җамалетдин** (1858) исемле; икенче улы **Нәүмәт**нең (1857 елда үлә) беренче хатынынннан **Идрис** (1849), **Хисмәтулла** (1854), икенче хатынынан **Исхак** (1854), **Хәерниса** (1857) исемле балалары; өченче улы **Әхмәт** белән хатыны **Хөснижан**ның (1833), кызы **Мәүхимә** (1856), 4 нче улы **Вәлит** белән хатыны **Хафизә Азизовна** (1833), аларның **Ләтифә** (1856), **Гафифә** (1858) исемле кызлары язылган.

Фәнни хезмәтләрдән Һ.Атласи башлангыч белемне әтисеннән ала, соңрак Буада гыйлем эсти, дип укыйбыз. Якташларының искә алуыннан күренгәнчә, ул Рус Шатрашаны дигән авылда да (хәзер Ульяновск өлкәсе) белем ала. Анда укытучы булып рус кешесе эшли һәм аңарда бары хәлле кешеләрнең балалары гына укый алган. Бу турыда Һ.Атласиның авылдашы, минем якташым һәм хезмәттәшем профессор И.Х.Мөдәрисов миңа ниләр сөйләде: *«Һади белән бер елларда туып, бергә үскән кешеләрнең сөйләшкәннәрен үзем тыңлап торган чакларым булды. Ул вакытларда миңа 7-8 яшьләр булгандыр. Һадилар йортына каршы якта Касыйм бабай, сулда землянкада Шәйҗан абзый* (аның кушаматы «камун Шәйҗаны». – **И.Г.**)*, уңда безнең өй урнашкан иде. Һадилардан 4-5 йорт аша гына Баһаутдинов Зартдин яшәде. Искә алган бабайлар арасында иң яше минем бабай Нәсибулла булып, ул алардан 5-6 яшькә яшьрәк иде. Шуны ассызыклыйсы килә: аларның барысы да 95-100 ел гомер кичерде.*

Ул чорларда телевизорның, радионың нәрсә икәнен дә белмиләр иде бит әле. Шуңа да бабайлар кичләрен Шәйҗан абзыйның өй төзергә әзерләгән бүрәнәләре өстенә, яз җитеп көннәр җылына башлагач ук җыелышып утырдылар. Шуннан инде әңгәмә башлана. Без, бабайлар сөйләгәнне тыңлар өчен, аларның аяк очларына җыелышып утырабыз. Без дигәнем, мин, Зартдин абзый оныгы Фән, Касыйм бабайныкы – Рузин (бу кешеләрне мин дә бик яхшы хәтерлим. – **И.Г.**). *Картларның салмак кына сөйләүләрен тыңлый-тыңлый йоклап киткән чаклар да аз булмады.*

Алар сөйләшендә мулла Һадие дигән исем дә еш яңгырады. Сүз мулла Мифтахетдиннең малаен русча укытырга Рус Шатрашаны авылына (әлеге авыл Түбән Чәкедән 5 чакрым гына ераклыкта. – **И.Г.**) *йөртүе турында бара иде. Һава торышының нинди булуына да карамастан, кышлыкта булса, тунга чорнап утыртып, махсус кеше аны алда искә алынган авыл мәктәбенә алып барган һәм кайткан. Шуңа авылда: «Үзе мулла, ә малаен урыс мәктәбендә укыта», – дигән сүзләр дә ишетелә. Бу вакыйгалар 1943-1944 елларда булуына карамастан, бабайлар еш кына мулла Һадие кайда икән, исәнме икән, ни эшләп йөри икән, дип сорашканнарын да хәтерлим. Бу чорларда алар инде алтмышны узып киткәнгә сугышка чакырылмадылар.*

Рус Шатрашаны мәктәбе ул вакытларда тирә-якта дан тоткан булган. Шул авылда туып, шушы мәктәпне тәмамлаган генерал ***Иван Теленов*** *үзенең* ***«Мои воспоминания»*** *дигән китабында: «Состоятельные татары водили своих детей в нашу школу», – дип язган.*

Һади Атласиның нәсел шәҗәрәсе



Әлеге мәктәпнең директоры булып ярты гасырдан артык Иван Степанович Челноков исемле кеше эшли. Минем әти дә сугыш башланганчы да, сугыштан соң да югарыда искә алынган авылдан 400 метр ераклыкта гына урнашкан Татар Шатрашаны мәктәбендә директор булып эшләгәнгә, алар дуслар иде. Шушы китапны ул әтигә дә укыта. Шуннан әти мондый нәтиҗәгә килеп безгә дә сөйләде: «Рус Шатрашаны авылына безнекеннән дә якынрак татар авылы юк, бары чуашлар гына. Чокалы авылы 15 чакрым ераклыкта булып, аннан беркем дә баласын мәктәпкә йөртмәгән. Һади белән бер чорда үскән Нәсибулла бабай да: «Безнең анда йөрергә мөмкинлегебез юк иде шул», – дип әтигә сөйләгән».

Шулай булгач Һадидан башка бүтән татар угылының рус мәктәбендә укуына ышану мөмкин түгел. Шуны да ассызыкларга кирәк, Һадилар таза тор-

мышлы булган. Моны И.Х.Мөдәрисов истәлеге дә раслый: *«Һадиларның йорты биек, якынча 2 метрлы койма белән әйләндереп алынган иде. Койма бүрәнәләр урталай ярылып, бастырып, ягъни вертикаль рәвештә эшләнгән. Ул шундый тыгыз итеп корылган, тотынып менәр өчен бернинди тишек тә, ярык та калдырылмаган. Шулай да без бала-чага аның артында нәрсә бар икән, дип, җиләк-җимешләрне күрер өчен булса да койма өстенә менгәли идек.*

Сугышта бер кулын калдырып кайткан Мурасов Гаязны (мин аны яхшы хәтерлим. – **И.Г.***) авыл советы рәисе итеп куйдылар. Өйләнгәч, Һадилар йортын алып, шунда озак еллар торганга күрә, йорт искереп чередe. Гаяз абый аның урынына яңасын ясады һәм бакчасына бәрәңге дә утырта башлады. Бер елны, мунчадан ерак булмаган урында, ат сукасына черек такталар эләгеп чыга. Агач сандык күренгәч, аны казып та алалар. Анда төлке, бүре тиресеннән тегелгән туннар сакланган икән. Дөрес, алар инде череп беткән була. Моңардан башка, әнинең сеңелесе Нурания апа бәрәңге утырткан вакытта, туннар яшерелгән урыннан ерак түгел, калын һәм киң итеп эшләнгән берничә алтын балдак табып, әнигә күрсәтә. Соңыннан, имеш, «...алтын яшерелгән хәзинә шунда булган, тик табылган әйберләрне беркемгә дә күрсәтмәделәр», – дигән сүзләр ишетелде».*

Алда әйтеп үтелгән Касыйм бабайның кызы Шәмсекай апа (93 яшенә җитеп вафат була) Илгиз Хәбибулла улына Г.Тукайның үзе исән вакытта ук нәшер ителгән китабын күрсәтә. Тукайның һәр шигыренә Һади Атласи үз фикерен, кайсыберләренә шактый кискен булганнарын да, язган була. Шәмсекай, укымышлы булганга, бу китапның тарихи әһәмияткә ия булуын аңлаган. Илгиз аспирантурада укыганда ул китапны 30 сумга сатып ала. Соңрак бу турыда тарих укытучысына сөйли, бик үтенеп сорагач, аңарга укып торырга бирә. Кызганыч ки, китап яңадан Илгизгә кайтмый. Элеге укытучы вафат булгач, аның хатынына мөрәҗәгать иткән идем. Тик күпме эзләсәләр дә таба алмадылар...

Һ.Атласиның күрше авыл мәктәбендә белем алуын рус телен яхшы белүе дә раслый. Чөнки, әтисенең дә, соңрак Буада Нургали дәмелла мәдрәсәсендә укыганда да аңа рус теленнән дәресләр бирүче булуына ышану кыен. Дөрес, Атласи Буада укыган чакта ук гарәп, фарсы һәм төрек телләрен камил үзләштергән. Бу мәдрәсәләрнең ныклы белем бирүен раслый торган мәгълүмат. Юкка гына Совет хөкүмәте мәдрәсә тәмамлау турындагы таныклыкны педагогик көллият дипломына тәңгәл булу турында махсус карар кабул итмәгән шул. Шул чорда укытучыларга хезмәт хакын да әлеге карар нигезендә түләделәр.

Хезмәтебезнең соңында Һадиның әтисе Мифтахетдин мулланың 1892 елда вафат булуын искәртеп үтәсебез килә. Аның икенче хатыны, Һадиның әнисе **Сәрвиҗамал** әби 1842 елда туган. Һади үзе 1885 елда туган **Хөсникамал**га өйләнә. Аның әтисе – **Габделфәттах Габделкаюм улы**, ә әнисе – **Мөхәммәтшаһ кызы Гайшә**. Әлеге гаилә таза тормышлы булып, Мөхәммәтшаһның он ясату фабрикасы да була. Хөсникамал 1967 елда бакыйлыкка күчә. Һадиларның җиде балалары туып, шуларның бишесенә бу дөньяда яшәргә, игелекле гамәлләр кылырга насыйп була.

Язмабызга кушымта итеп, үзебезнең эзләнү нәтиҗәсендә табылган мәгълүмат нигезендә Һ.Атласи нәселенең шәҗәрәсен бирергә булдык. Без аны Мөхәммәтһади исеме белән тәмамлыйбыз, чөнки калган өлеше бүтән авторларның хезмәтләрендә язылган. ■

«Казан ханлыгы», «Сөен-бикә», «Себер ханлыгы» исемле әсәрләре белән мәшһүр булган Һади Атласи «Йолдыз», «Вакыт» газеталары, «Мәктәп», «Шура», «Аң» кебек журналларның да даими авторы булган. Әлеге публицистик мирас 2010 елда «Җыен» нәшрияты тарафыннан чыгарылган Һ.Атласи сайланма әсәрләренең II нче томында басылды (төзүчеләр: И.Гыймадиев, Л.Гобәйдуллин, Р.Миңнуллин, Э.Сәлахова). Ә бер өлеше җыентыкка һәм хәтта аның азагындагы библиографик күрсәткечкә дә кертелми калды. 1910 (№552, 15 июнь) һәм 1914 (№1168, 16 апрель) елларда «Йолдыз» газетасында басылган бер үк исемдәге ике мәкалә – «Безнең байлар» шундыйлардан.

ҺАДИ АТЛАСИНЫҢ «ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛГАН ИКЕ МӘКАЛӘСЕ



Татар сәүдәгәренең йорты. XIX гасырның беренче яртысы

БЕЗНЕҢ БАЙЛАР

Инсанның гәүдәсендәге һәр әгъза үзенә хас хидмәт *(эш, хезмәт)* өчен яратылган (мисал: күз күрергә, колак ишетергә, аяк йөрергә, кул тотарга хәлык ителгән *(бар кылынган))* вә шул әгъзаларның һәрберсеннән үзләренә лаек хидмәтләр өмид ителгән кебек, милләт әгъзалары саналган кешеләрнең һәм һәрберсеннән үзләренә лаек хидмәтләр өмид ителмәктәдер. Бер кешенең әгъзалары кылырга тиешле булган бер эшне эшләүдә иттифак итә алмасалар, ягъни әгъзалар үзләренә тиешле булган эшләрне эшләмәсәләр, әлбәттә, бу кеше үзенең көндәшләре булган адәмнәр илә узыша алмый, артта калып харап булырга мәҗбүр була.

Менә шуның кебек үк, бер милләт булып та, ул милләтнең әгъзалары арасында милли эшләр уртак ителеп эшләнмәсә; берсе мең бәла берлән булдырырга тырышкан эшкә икенчесе каршы төшеп, булдыртмый калса; һәркем үзенә фарыз ителгән эшне башкаларга тапшырып эшләми калдырса; үзарадагы вак дошманлыкларга бик зур әһәмият биреп, дошманнан шәхси ачуны алачак урынга, милләткә җинаять итеп ачу алса, әлбәттә, әгъзалары явыз эшләрдә булган милләт тә бетәчәктер. Буны бетерергә дә

яңадан бер сәбәп кирәк булмыйча, уртасыннан черергә тотынган агач кебек, бу милләт үзлегеннән үзе бетәчәктер.

Безнең тарихларымыз үзенең куркынычлы тукынулары илә йөрәкне берьюлы тотыкландырган кебек, хәзерге китешемездәге вакыйгалар борынгылары кебек үк һәм ачы һәм куркынычлылардыр. Татарларның борынгылары, эшне уртак итеп эшләмәү сәбәпле, һәлак булган кебек, хәзергеләре дә милли эшләрне уртак эшләмәү сәбәпле йир йөзеннән бөтенләй югалырга маташалар. Татарларны тәрәккыйдән чынлап туктатып торучы сәбәпләрнең иң беренчесе вә татар милләте башына бәла булган сәбәпләрнең иң көчлесе, һич шөбһәсез, һәркемнең үзенә тиешле булган бурычны үтәмәве, ягъни үзенең хәсасына *(өлешенә)* төшкән хидмәтен кылмавыдыр.

Толстойның халыкны яхшыландыру хакында бик кызыклы бер фикере бар. Ул: *«Һәркем үзен үзе яхшыландырырга тиешле. Бөтен кеше яхшылангач дөнья да яхшырачак, галәмдә гадаләт (гаделлек) тә хөкем сөрәчәк. Бөтен дөньяның яхшыруы өчен кайгыртканчы, һәркем үзен яхшыртса иде, дөнья төзәлер иде»*, – дидер.

Толстойның бу фикере үзенең тирән фәлсәфәсе нигезе өстенә корылганлыктан, әллә никадәр олуг мәгънәләрне эченә алганлыгы илә бәрабәр: *«Һәркем үзенең бурычын үтәсә, милләт тә тәрәккый итәр иде»*, – дигән сүзне һәм аңлата.

Вакыйгда *(чынлыкта)* эш шулай булырга тиешле булса да, ләкин безнең тормыштагы агым бу кагыйдәгә бөтенләй киреседер, чөнки руханилар арасында үз вазифасын үтәмәенчә милләткә җинаять кылучылар ничаклы күп булса, татар байлары арасында да малын милләт юлына сарыф кылмаенча, гел нәфес арзулары *(теләк)* урынына гына сарыф кылып, милләткә хыянәт иткәннәре бик күптер.

Күз алдымыздадыр ки: аңлы бай илә аңлы мелла кулын-кулга биреп, милли хидмәтләрне уртак эшләгән урыннарда 5-10 ел эчендә авыл халкының яртысына якыны укырга-язарга белеп, шундый авылларда хәят (тереклек әсәрләре), иман нуры, милләт мәхәббәте хөкем сөрә башлады. Билгакес *(киресенчә)*, аңсыз руханилар илә аңсыз байлар башлык иткән авылларда наданлык мөстәкыйль хөкемдар булып, хөкемне иҗраэ итә *(башкара)*: ул урыннарда һәм дингә һәм милләткә зур-зур җинаятьләр кылына. Бу эшләр барысы да безнең күз алдымыздадыр.

Татар байлары арасында тышкы яктан укыган кеше сыман булып йөрүче вә әлхасыйль *(кыскасы)*, милләтнең тәрәккые өчен файдасы юк, Ауропаның тышкы гадәтләрен кабул итүче мәймүннәр *(маймыллар)* булгаласа да, болар голүм вә мәгариф бабларында борынгыдагы мөрид татарлар кебек барыбер чеп-чиләрдер. Боларны без ачык белдек һәм күп сынадык. **Мәрхүм Әхмәд һәм Гани байларның атаклыклары ат чаптырып йөрдекләре вә бер кичтә әллә кай урыннарда меңләп акчалар түктекләре өчен түгел, тир чыгарып тапкан йөзәр меңнәрен кызганмый милләтнең кирәгенә сарыф иттекләре һәм дә татарларның гыйлем вә мәгърифәтләренә тырышдыклары өчендер.**

Без бик күп байларны беләмез. Анлар тышкы яктан суфи сыман күренсәләр дә, дин юлында файдасызлар вә Аурупалашкан күренсәләр дә, хакыйкәтьтә милләт юлына бер тиен файда итми, голүм вә мәгариф хөрмәтенә бер тиен дә бирми торган чеп-чи наданнардыр. Билгакес, без бик күп байларны беләмез, тышкы катлары гадәтчә генә булдыгы хәлдә, милләт юлына меңләп-меңләп сарыф итәләр. Мисал: Яхшыбай карьясенең *(авылының)* мәрхүм Мортаза бай, тышы гадәтчә генә булган бер сала бае булдыгы хәлдә, милләт юлында йөз меңләп вәкыф калдырды. Менә без шул кебек милләт хидмәтчеләрен вә шул ке-

бек голүм вә мәгариф өчен малларын сарыф иткән һиммәт ияләрен мактарга мәҗбүрмез. Менә шунларны гына без инсан һәм мөселман димез. Менә шунларны гына без хакыйкый байлар димез. **Татарлар арасында егермеләп Барудилар, ун-унбиш Әхмәд һәм Гани байлар вә һәр губернада берничә Хәлфиннәр булса иде, татарлар голүм вә мәгариф бабларында кыяс ителми *(тиңе булмый)* торган дәрәҗәдә алга киткән булырлар вә анларның бу көннәрдәге алыш-бирешләре башкача булыр иде.**

Ләкин мәгаттәәссеф *(кызганычка каршы)*, безнең руханилар арасында корсак кайгысыннан бушый алмый торганнары күберәк булган кебек, байлар арасында һәм шөһрәтне тышкы кат берлән генә алырга тырышып, гыйлем вә мәгърифәт юлына кирәгенчә сарыф итми торганнары күбрәктер.

Минем язганнарымның хөласасы *(йомгагы)*: милләт уртак хидмәттә уртак булырга тиешле. Милләтнең һәр әгъзасы үзенә тиешле булган хидмәтне үтәргә гакыл вә вөҗдан берлә бурычлылардыр. Байлар маллары илән белеклеләр, белекләре илән хидмәт итмәсәләр, без тәрәккый итә алмаячакмыз.

Коры кием берлән генә суфи булып та булмый, Ауропалашып та булмый, **акчаны гыйлем вә мәгърифәт юлына сарыф итеп кенә чын бай булып була**. «Коры телеңне корытсын», – дигән мәкальгә охшашлы: «Коры киемең, коры гүләйт итүең корсын», – димәктән гыйбарәттер.

БЕЗНЕҢ БАЙЛАР

Һәр милләтнең алга китүендә шактый зур урын тоткан затларның берсе, һичшиксез, шул йирнең байларыдыр. Ауропадагы искиткеч тәрәккыйгә шундагы байларның бик зур катнашлары булдыгы кеби, Америкадагы тәрәккыйгә дә андагы байларның бик зур катнашлары бар. Мәктәпнең дәресләре шуларны белүчеләр тарафыннан бирелсәләр дә, шул мәктәпләрнең бипалары акча илә вөҗүдкә *(барлыкка)* килүләрендә шөбһә юк. Шуңа күрә гыйльми мөәсәсәләрнең *(оешмаларның)* рухын мөгаллимнәр, җисемен шуларны вөҗүдкә *(барлыкка)* китерүче һиммәтле байлар, дип санарга ярый. Аңлы байлар һәр падишаһлыкта халыкның тәрәккыенә акча илә зур хидмәт итеп килгәннәр вә һаман шулай итеп баралар.

Бу хосуста Америка байлары бигрәк тә алда булып, боларның гыйлем юлына тоткан акчаларын хисаплап карaганда, хәйран булмый мөмкин түгел. Американың атаклы байларыннан «Кәрнәҗи»нең үз гомерендә гыйлем һәм хәйрат юлына сарыф иткән акчасы 600 миллион сумга йитә. Америка байларының хәйрат юлына һәр елны сарыф итеп килмәктә булган акчалары бергә җыелганда, ел саен 320 миллион чамасында булып бара.

1905 нче елда Америка байлары гыйльми эшләр файдасына 140 миллион, музейлар өчен 20 миллион, больницаларга 24 миллион, чиркәүләргә 16 миллион, үксезләр йорты һәм приютларга 12 миллион сум иганә иткәннәр. Американың бар халкы 86 миллион чамасында булганлыктан, байларның еллык иганәләре андагы һәр кеше башына 4 сум чамасы төшә. Бу рәкымнәрне *(саннарны)* безгә тәтбыйк итеп караганда болай булып чыгарга тиешле була. Мисал: Уфа губернасында 1миллион 500 мең, Казан губернасында 600 мең чамасы мөселман бар. Уфа байлары америкалыларча иганә иткәндә, аларның еллык иганәләре 6 миллион, казанлыларның 2 миллион 400 мең сум булырга тиеш. Хәлбуки, Уфа губернасы үзенең вөҗүдкә *(барлыкка)* килүеннән башлап, ул чаклы иганәне күргәне юк, һәм тиз генә булачак та түгел. Американың зур байлары гыйлем юлында ничаклы иҗтиһад итсәләр, андагы кечкенә байлар да шулай иҗтиһад итәләр. Хәлле хәленчә халыкның белемле булуына иҗтиһад итеп, ул юлда һичбер нәрсә кызганмыйлар. Шуңа күрә милләт искиткеч тизлек илә тәрәккый итә, алга бара.

Бездә исә эш бөтенләй киресенчә. Безнең байларның кысык-фисад *(бозыклык)* юлына сарыф итәргә азмы-күпме акчалары булса да, белем юлына сарыф итәр өчен бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Аңлы милләтләр үзләренең гыйлем мөәссәсәләренә *(учреждениеләренә)* милләтнең уртак милке итеп карыйлар. Аның матди вә мәгънәви тәрәккый итүенә тырышу милләтнең һәрбер фәрденә *(затына)* тиешле эш дип беләләр. Шуңа күрә анларның байлары мондый мөәссәсәләрнең матди җәһәтләрен, голәмәсе исә рухани яклары тәэмин итәләр. Безнең мәктәп вә мәдрәсәләремезгә исә халык тарафыннан милли мөәссәсәләр дип каралмыйча, аңа бер мелла яки мөдәрриснең хосусый милке сыман итеп карала. Халык аңа акча бирүне әлеге мелла илә мөдәррискә сәдака бирү дип белә. Байларымызның күп өлеше аңсыз вә чын мәгънәсе илә милли һәм дини хистән мәхрүм булганлыклары өчен, анлар хәйрат юлына үзләре белеп бирә белмиләр, соралганда да бер тиенне мең тиенгә хисаплап бирәләр. Шушы тиеннәре бәрабәренә әллә нинди миннәтләр[1] итүдән дә тартынмыйлар. Шунларны алучы тарафыннан үзләренең мәңгелек «вәли нигъмәт[2]» саналуларын да чын күңелдән арзу итәләр *(телиләр)*. Борынгы заманның аңсыз меллалары тарафыннан татар байлары тәмам бозылып, бер тиенгә мең тиенлек миннәт итәрдәй ясалганнар. Менә бу начар гадәт безнең татар арасында «милли холык» рәвешенә кереп, алар бер эшнең мөкатдәсе идекен үзләре белеп акча сарыф итә белмиләр. Тиеннәре бәрабәренә борынгы заманның аңсыз меллаларын ничек багындырган булсалар, бу көнге хәлдәге аңлы милләт хадимнәрен дә шулай багындырмакчы булалар. Безнең татар байлары арасында дин бетүдән, халыкның бозылуыннан, меллаларның намазга сирәк йөрүләреннән һәм ишракта утырмауларыннан[3], яшьләрнең дәһрилегеннән зарланып фәлсәфә сатучылар бик күп булса да, бер мәктәп вә яхуд мәдрәсәнең тәрбиясен үз өстенә алып баручылар бик сирәк.

Үткән атналарда миңа милләт хадиме булган бер мелла илә утырышырга туры килде. Бу кешенең ирләр мәктәбендә йөзләп шәкерт укыдыгы кеби, кызлар мәктәбендә дә 50ләп кыз балалар укый. Мелла үзенең мәктәбендә вазифасыз хидмәт итә. Мелла бай түгел, ярлы. Авылында ничәләп бай булдыгы хәлдә, ярлы мелла үз кесәсеннән мәктәп өчен 40 сумлап акча тоткан. Дөньяда моннан артык ят эш булуы бик сирәк булыр. Үзе һәм хатыны вазифасыз хидмәт итсен, өстәвенә ярлы булдыгы хәлдә 40 сум акча тотсын!.. Татар акчасы илә баеган татар бае исә фәлсәфә сатып, шундый бичараларның аһларына тузан чаклы булса да игътибар итсен!.. Мондый меллалар бер урында гына булмаенча, Русиянең һәр почмагы шундый гаҗиз милләт хадимнәре илә тулган. Аларның һәркаюсы бар көчләрен сарыф итеп хидмәт кылалар. Әмма халык, һиммәтсез байлар ул бичараларның мең бәла илә хидмәт итүләрен ерактан карап, күзәтеп торалар. Дини гамәлләрнең һәрберсе фәкать Алла ризалыгы өчен генә кылынырга тиешле булдыгы кеби, милләт хидмәтләре дә халис *(бары тик)* Алла ризалыгы өчен булырга тиештер. Шуңа күрә безнең байлар дини һәм милли булган эшләрнең кодсиятен *(изгелеген)* үзләре белеп, шул эшләр файдасына икенчеләрне багындырмаенча ярдәм итәргә тиешледер. Борынгы заман үтеп киттеке кеби, ислам галәмен, татар милләтен бетерергә сәбәп булган борынгы гадәтләр дә бетәргә тиеш.

Текст һәм искәрмәләрне басмага
Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

[1] Миннәт – бирәүгә иткән яхшылыкны, ярдәмне һаман искә төшереп тору, шуның белән битәрләү.
[2] Вәли нигъмәт – ашамлык-эчемлек иясе, туйдыручы кеше.
[3] Ишракта утыру – кояш чыгып 10-15 минут вакыт узгач ишрак намазын уку.

АКЧУРИННАР МИРАСЫ

Ульяновск өлкәсендә халкыбызның милли-мәдәни, икътисади тормышына мөнәсәбәтле тарихи ядкярләр шактый. Аларның бер өлеше атаклы сәнәгатьче, хәйрияче Акчуриннардан мирас булып калган. Журналның бу һәм алдагы саннарында укучыларны әлеге бай хәзинә белән таныштырырга телибез, ә фото һәм видеоязмаларны www.beznenmiras.ru сайтыннан карый аласыз.

ЙОСЫФ АКЧУРИН ЙОРТЫ

Наил Таиров, Илһам Таиров

Барыш районы Зөябаш авылында агач бүрәнәләрдән төзелгән, ике катлы, балконлы Йосыф Сөләйман улы Акчуринның йорты бар. Авылның көнчыгыш өлешендәге әлеге бина заманында гүзәл бакча һәм парк янында урнашкан. Парк территориясендә ясалма күл дә булган.

Шунысы да кызык, утарны күренекле сәясәтче һәм галим Йосыф Хәсән улы Акчура да якын иткән, туган җиренә кунакка кайткан вакытта шунда тукталган, кунак булган. Галим үзенең кайбер әсәрләрен дә Зөябаш авылындагы әлеге күркәм йортта иҗат иткән. Кардәш эне һәм сеңелләре аны яратып һәм хөрмәт итеп «Париж-Йосыф абзый» дип йөрткән. Истәлекләргә караганда, Йосыф Акчура Зөябаш авылына һәм йортка килүче иң мәртәбәле, дәрәҗәле кунакларның берсе булган.

1917-1918 елларда фабрикантның йортына югары уку йорты студенты Гайнетдин Дебердиев та килә. Ул биредә башкаладагы ыгы-зыгылардан качып, җан тынычлыгы табарга тели. Атаклы сәүдәгәр һәм фабрикантлар нәселеннән булган Гайнетдин, Йосыф бай хатынының туганы булган. Әмма бу елларда кызыллар байның йортына еш килеп тентегән, шундый «тикшерү»нең берсендә Гайнетдин балконга чыга һәм атып үтерелә. Студентның җәсәде Зөябаш авылы зиратына җирләнә. Җирле халык әлеге канлы вакыйга уңаеннан бәет тә чыгарган. Без бу бәетне Калны авылында яшәүче Зөләйха Габдерәшит кызы Таировадан (1916-2002) язып алган идек. Шуннан бер өзек китерәбез:

«Шамил иде минем исем,
Красногвардеецлар башлыгы булып,
Бөтен Россияне гиздем,
Гайнетдиннең башына җиттем»...

Төбәкне өйрәнүче Габделхәй Урмиев истәлекләре Йосыф байның гаять эшлекле һәм тырыш кеше булуы турында сөйли. Аның бар уйлаганы, кылган һәр гамәле сукно фабрикасының эшен камилләштерү булган. Кайбер кешеләр, Йосыф байны иртән фабрика ишегалдында күреп, көлемсерәп: «Кем өчен һәм нигә шултикле тырышасың?» – дип сораган (Йосыф байның балалары булмаган). Йосыф бай җитди итеп:

«Сезнең өчен тырышам. Фабрикада сезгә эш булмаса, харап булачаксыз!» – дип җавап биргән.

Октябрь революциясеннән соң фабрика байлар кулыннан китә, Йосыф Акчуринның йортын, каралты-курасын да тартып алалар. Архив документларына караганда, аны 1919 елның 18 декабрендә постау фабрикасының мәдәни-агарту секциясе карамагына тапшыралар.

Хәерчелектә калган Йосыф Акчурин үзенең борчу-мәшәкатьләре белән яңа хакимияткә мөрәҗәгать итә. Моны 1919 елның 31 июлендә үзенең фәкыйрьлеген, мескенлеген белдереп, ярдәм сорап язган гаризасы дәлилли. Постау фабрикасы идарәсе һәм аның карамагындагы тукучылар профсоюзының 1919 елның 19 августында булган утырышында Йосыфның гаризасы карала һәм аңа социаль тәэминат бүлегенә үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә, аның кәгазен кичекмичә Көнчыгыш фронтның махсус бүлегенә җибәрергә, дип карар чыгарыла...

Биредә элек көймәдә йөзеп, ял иткәннәр

Акчуриннар чорыннан калган тупыллар

Йосыф Акчурин авылдан юкка чыга. Соңрак туганнары, авыл кешеләре 70 яшьлек, сәләмә киемле, авыру картны берничә мәртәбә урамда күргәли. Аның бу вакытта хатыны Гайшәне җирләп йөргән көннәре була. Аннары ул Уфага китеп югала һәм бүтән күренми.

Йосыф бай төзеткән бина һәм утарга совет чорында балалар йорты урнаша. Бүген исә биредә инде таркалырга өлгергән, хәрабәләре генә торып калган фабриканың элекке эшчеләре үз гаиләләре белән көн күрә. Парктан да берничә тупыл агачы һәм саегып, кибеп баручы күл (боларны www.beznenmiras.ru сайтыннан карарга мөмкин), кызыл кирпечтән төзелгән берничә склад корылмасы гына сакланган. Җимерелеп килүче һәм капиталь ремонт таләп итә торган бинаны авыл халкы әле дә «Йосыф бай йорты» дип атый. ■

Ленар Гобәйдуллин фотолары

Изге Синодның Праваслау Грек-Россия Чиркәвенең тугрылыклы балаларына мөрәҗәгате илә граф Лев Толстой турындагы1901 ел 20-22 февраль карары[1]


24 Февраля ═══ ГОДЪ ЧЕТЫРНАДЦАТЫЙ ═══ 1901 года.

ЦЕРКОВНЫЯ ВѢДОМОСТИ,

ИЗДАВАЕМЫЯ

ПРИ СВЯТѢЙШЕМЪ ПРАВИТЕЛЬСТВУЮЩЕМЪ СѴНОДѢ.

№ 8	ЕЖЕНЕДѢЛЬНОЕ ИЗДАНІЕ СЪ ПРИБАВЛЕНІЯМИ.	№ 8

Опредѣленіе Святѣйшаго Сѵнода,

отъ 20—22 февраля 1901 года № 557, съ посланіемъ вѣрнымъ чадамъ Православныя Грекороссійскія Церкви о графѣ Львѣ Толстомъ.

Святѣйшій Сѵнодъ, въ своемъ попеченіи о чадахъ Православной Церкви, объ охраненіи ихъ отъ губительнаго соблазна и о спасеніи заблуждающихся, имѣвъ сужденіе о графѣ Львѣ Толстомъ и его противохристіанскомъ и противоцерковномъ лжеученіи, призналъ благовременнымъ, въ предупрежденіе нарушенія мира церковнаго, обнародовать, чрезъ напечатаніе въ «Церковныхъ Вѣдомостяхъ», нижеслѣдующее свое посланіе:

БОЖІЕЮ МИЛОСТІЮ,

Святѣйшій Всероссійскій Сѵнодъ вѣрнымъ чадамъ Православныя Каѳолическія Грекороссійскія Церкви

о Господѣ радоватися.

«Молимъ вы, братіе, блюдитеся отъ творящихъ распри и раздоры, кромѣ ученія, емуже вы научистеся, и уклонитеся отъ нихъ» (Римл. 16, 17).

Изначала Церковь Христова терпѣла хулы и нападенія отъ многочисленныхъ еретиковъ и лжеучителей, которые стремились ниспровергнуть ее и поколебать въ существенныхъ ея основаніяхъ, утвер-

Изге Синод, Праваслау Чиркәвенең балалары турында кайгыртып, аларны һәлакәткә илтә торган әгъвадан[2] сакларга вә адашучыларны коткарырга теләп, граф Лев Толстой һәм аның нәсаралыкка вә чиркәүгә каршы ялган тәгълиматына карата мөнәсәбәт белдереп, чиркәүнең тынычлыгын җимерүне кисәтергә алынып һәм әлеге гамәлен бик вакытлы башкарылган гамәл санап, «Чиркәү хәбәрләре»ндә бастыру аша ошбу мөрәҗәгатен дөньяга чыгара:

ИЛАҺ РӘХМӘТЕ ИЛӘ,

Изге Бөтенроссия Синоды Праваслау Кафолик Грек-Россия Чиркәвенең тугрылыклы балалары өчен Ходай алдында баш ора.

> «Имандашлар, сездән ялварып сорыйм: үзегез өйрәнгән тәгълиматка карата бүленеш китереп чыгарган һәм дөрес юлдан яздыруга сәбәп тудыручылардан сакланыгыз һәм алардан читләшегез». (Паулдан римлыларга хат 16:17.)

Мәсихкә, Тере Ходай Улына ышануда расланган Мәсих Чиркәве элек-электән үзен җимерергә һәм үзенең төп нигезләрен какшатырга теләгән күп санлы денсезләрдән вә ялган мөгалимнәрдән хурлау вә һөҗүм кичерә бирде. Әмма тәмугның бар көчләре кушылып та, Ходайның рәхмәтенә ирешмичә, Изге Чиркәүне җиңә алмады вә гасырлар дәвамында җиңә алмаячак та. Инде безнең заманда, Ходайның каһәренә күрә, яңа ялган мөгаллим – граф Лев Толстой барлыкка килде. Дөньяга танылган язучы, тумышы

---

[1] Определение Святейшего Синода от 20-22 февраля 1901 года с посланием верным чадам Православной Грекороссийской Церкви о графе Льве Толстом. Церковные ведомости. – 1901. – 24 февраля.

[2] Әгъва – кызыгу, вәсвәсә.

белән урыс кавеменнән булган, чумдырылуы вә тәрбиясе белән православ динендә торган граф Толстой, үзенең горур гакылына сокланып, һич тартынусыз Ходайга вә Аның Мәсихенә вә Аның изге казанышларына каршы баш күтәрде, үзен туендырган һәм тәрбияләгән Анасыннан – Православ Чиркәвеннән җәмәгать алдында ваз кичте, һәм үзенең әдәби эшчәнлеген вә Илаһ тарафыннан иңдерелгән сәләтен Мәсихкә һәм Чиркәүгә каршы тәгълиматлар таратуга багышлады, галәмне раслаган, ата-бабаларыбыз тоткан вә аңарда гына коткару күргән һәм изге урыс иле моңарчы табынган вә шуның белән ныклы булган ата-бабалар динен, православ динен кешеләрнең гакылларыннан һәм йөрәкләреннән юдыруга сарыф итте. Үзе дә, укучылары да дөньяда, бигрәк тә кадерле Ватаныбызда күпләп-күпләп тарата барган язмаларында вә хатларында ул, фанатикларча ашкынып, Православ Чиркәвенең һәм нәсара диненең асылын тәшкил кылган барлык дини кануннарны җимерергә чакыра: Тере Алланы, галәмнең Изге Өчледә данлана торган Барлыкка китерүчесен һәм Химаячесен кире кага, Ходаебыз Гайсә Мәсихне – кеше рәвешен алган алланы, дөньяны Аклаучы һәм Коткаручыны инкяр итә, безнең өчен, кешеләр өчен газап күргән вә безне коткарыр өчен үлгәннән соң терелеп торган Мәсих Ходайның орлыксыз яралуын һәм Изге Кыз Мариянең Мәсих туганчы һәм Мәсих туганнан соң да гыйффәтле булып калуын танымый, үлгәннән соңгы тормышны һәм бүләк вә җәзаны, Чиркәүнең барлык серле йолаларын вә аларга карата Изге Рухның игелекле гамәлдә булуын кире кага һәм, православ халкы тоткан диннең иң изге кыйммәтләрен хурлап, Серле йолаларның (таинство) иң бөеге саналган изге Евхаристияне[3] мыскыллаудан да тайчанмый.

Граф Лев Толстой, православ дөньясының котын алып, ошбу фикерләрен һәм сүз аша, һәм язу аша бертуктаусыз халыкка җиткерә килде, шул рәвешле яшеренеп тә түгел, ә ачыктан ачык итеп, аңлы рәвештә вә төптән уйлап, Православ Чиркәве белән һәртөрле мөнәсәбәтен өзде. Үгет-нәсыйхәт биреп аңга китерергә тырышуларыбыз һичнинди нәтиҗә бирмәде. Шуңа күрә Чиркәү аны үзенең әгъзасы итеп саный алмый һәм кылганына үкенеп тәүбәгә килгәнче үзенең әгъзасы итеп саный алмаячак та. Ошбу мәлдә, хак юлда торучыларны яклап вә адашканнарны, бигрәк тә граф Толстойның үзен, тагын бер кат аңга китерергә тырышып, Чиркәү каршында шул хакта шаһитлек итәбез. Иманын җуймаган туган-тумачалары исә, зур көенеч илә, азаккы сәгатьләре якынлашканда аның, Чиркәү белән аралашудан һәм Чиркәүнең догаларыннан вә фатихаларыннан ваз кичүе аркасында, Илаһка вә Коткаручы Ходайга ышанудан мәхрүм калуын уйлап борчыла.

Шул сәбәпле, аның Чиркәүгә карата мөртәтлек кылганына шаһитлек итәбез һәм бергәләп баш орабыз: Ходай аны тәүбәгә китерсен һәм аңа хакыйкый гакыл бирсен (Паулдан Тимутәйгә икенче хат 2:25). Баш орабыз, мәрхәмәтле Ходай, гөнаһлы үлем бирмә, ишет вә ярлыкагыл аны һәм Үзеңнең изге Чиркәвеңә юнәт. Амин.

Ошбу язуны имзаладылар:
карусыз Антоний, Санкт-Петербург һәм Ладога митрополиты,
карусыз Феогност, Киев һәм Галиция митрополиты,
карусыз Владимир, Мәскәү һәм Коломна митрополиты,
карусыз Иероним, Холм һәм Варшау архиепископы,
карусыз Иаков, Кишинев һәм Хотино епископы,
карусыз епископ Маркелл,
карусыз епископ Борис. ■

---

[3] Евхаристия – икмәк салынган шәраб эчеп гөнаһлардан арыну йоласы.

Синодның 20-22 февраль карарына һәм шул уңайдан миңа килгән хатларга җавап

Лев Толстой

He who begins by loving Christianity better than Truth will proceed by loving his own Sect or Church better than Christianity, and end in loving himself better than all.
Coleridge

Әүвәл бу карарга җавап биреп тормам да дигән идем, вәләкин шул уңайдан нәмәгълүм затлар тарафыннан миңа юлланган бихисап хатлар – берәүләр мин һич инкяр итмәгән нәрсәләрне инкяр иткәнемә тирги; икенчеләр мин ышанудан туктамаган нәрсәләргә ышанырга үгетли; өченчеләр фикердәшлек белдерә – әмма белмим, мөмкин хәлме икән бу, һәм, анысына хакым бармы икән – кайгымны уртаклаша; һәм мин, гаделсезлеген расларга ниятләп, карарның үзенә карата да, шул уңайдан миңа нәмәгълүм затлар тарафыннан юлланган хатларга да җавап бирергә уйладым.

Синод карарының, гомумән, кимчелеге бик күп. Ул канунсыз һәм махсус рәвештә ике төрле уйларга урын калдырып гамәлгә куелган; ул башбаштаклы, нигезсез, хаксыз һәм, шуннан ары, яман фикерләргә, гамәлләргә этәрергә мөмкин яла һәм коткы тарату куркынычы тудыра.

Канунсыз һәм махсус рәвештә ике төрле уйларга урын калдырып гамәлгә куелган – чөнки, чиркәүдән куу булса, ул, ягъни карар, мондый вакытта кирәккән чиркәү кагыйдәләренә туры килергә тиеш иде, ә ул туры килми; әгәр дә бу – чиркәүгә һәм аның тәгълиматларына ышанмаган кеше чиркәү әгъзасы булып саналмый, дигән белдерү икән, ул, асылда чиркәүдән куу булмыйча, табигый ки, чиркәүдән куу булып тоелырга тиешле ишарә генә булыр иде; ул чынлыкта шулай булды да – һәркем тарафыннан тәгаен шулай кабул ителде.

[1] Л.Н.Толстой. Полное собрание сочинений в 90 томах. Том 34. – Москва: Государственное издательство художественной литературы, 1952.



Лев Толстой.
И.Е.Репин рәсеме.
1901 ел

Карар башбаштаклы, чөнки күрсәтелгән матдәләргә ышанмауда бары тик мине генә гаепли, гәрчә Россиядә күп кешеләр димим, гыйлемле кешеләрнең барысы да, диярлек, дим, минем ышанмауларымны уртаклаша һәм бу турыда үз фикерен әңгәмәләшкән вакытта да, укыганда да, китаплар аша да белдерә килә.

Карар нигезсез, чөнки аңарда минем ялган тәгълиматымны күпләп таратуым төп сылтау ителә, гәрчә бу очракта уйларымны уртаклашкан кешеләрнең саны күп дигәндә йөзгә җыеламы икән әле; өстәвенә, цензураның һәйбәт эшләве сәбәпле, дин турында басылган, ягъни нәшер ителгән язмаларымның саны шулкадәр аз ки, хәтта, хатлардан күренгәнчә, Синод карарын укыган кешеләрнең күбесе бу хакта ни-нәрсәләр язганымны белми дә икән.

Карар күзгә карап ялган сөйли: чиркәү, ничә тапкыр мине аңга китерергә тырышуына карамастан, теләгенә ирешә алмаган, имеш. Мондый хәлнең беркайчан да булганы булмады.

Карар, хокук теле белән әйткәндә, ялага тартым, чөнки ул күрәләтә гаделсез һәм минем шәхесемә зыян китерерлек карашлардан оешкан.

Карар, ниһаять, яман хисләргә һәм гамәлләргә этәргеч тә, чөнки ул, алдан көтелгәнчә, белемсез һәм фикерсез кешеләрнең күңелендә миңа карата ачу һәм нәфрәт, хәтта үтерү теләге уята. Син диннән сөрелдең, эттәй себерелеп яшәп, аяк сузачаксың да, теге дөньяда мәңгелек газапка кабачаксың... мәлгунь син, карт иблис... каһәр суксын, дип яза берсе. Икенчесе мине әлегәчә манастырга (монастырьга) олактырмаган өчен хөкүмәтне әрли һәм хатны аркылыга-буйга сүгенү сүзләре белән тутыра. Өченчесе яза: хөкүмәт тыймаса, үзебез сине авыз ачмаслык итәрбез, ди; хат каргаулар белән тәмамлана. Син кабахәтне, дип яза дүртенчесе, юк итү чарасын табармын... Яңадан ямьсез сүзләр кабатлана.

Хәзер, Синодның карары чыкканнан соң, кайбер кешеләр белән очрашканда, күрешкәндә дә үземә карата ачу хисе бөркелгәнен тоям мин. Карар чыккан көнне үк, 25 февральдә, мәйдан кичкәндә, шәхесемә атап әйтелгән сүзләр ишеттем: кеше рәвешенә кергән иблис бу; ул чакта гавам үзгәрәк кешеләрдән оешкан булса, ихтимал, кара көйдергәнче тукмарга да күп сорамаслар иде, берничә ел элек Пантелеймон кәшәнәсе (часовня) янында бәгъзе затны тукмаган кебек.

Шуңа күрә, Синод карары, гомумән, яхшы түгел. Карарның азагында исеме күрсәтелгән һәм имзасы салынган берничә затның мине дә үзләренең сыңары итәргә теләп баш орулары ул карарны һич яхшыртмый.

Бусы гомуми сүзләр булды. Түбәнәрәк төшеп карасаң, карарда гаделсез урыннар байтак, шуларга тукталыйк. Карарда язылган: дөньяга танылган язучы, тумы-

Лев Толстой – тәмугта. Тазово авылы (Курск губернасы) чиркәвенең диварындагы рәсем. 1883 ел

шы белән урыс кавеменнән булган, чумдырылуы һәм тәрбиясе белән православлау динендә йөргән граф Толстой, үзенең горур гакылына сокланып, һич тартынусыз ходайга һәм аның Мәсихенә һәм аның изге казанышларына каршы баш күтәрде, үзен туендырган һәм тәрбияләгән анасыннан – православлау чиркәвеннән җәмәгать алдында ваз кичте, диелгән.

Үзен православлау чиркәве дип атаган оешмадан ваз кичүем – хак, бу, һич шөбһәсез, гадел әйтелгән сүз. Ләкин ваз кичүнең нигезендә Ходайга каршы баш күтәрүнең әсәре дә юк, киресенчә, барлык вөҗүдем белән аңа хезмәт итәргә теләүдән чыгып кылынган гамәл бу. Чиркәүдән һәм халык бердәмлегеннән, никадәр ул миңа якын һәм кадерле булмасын, баш тартканчы мин, кайбер билгеләре буенча чиркәүнең дөреслеген, хаклыгын шик астына алып, берничә ел гомеремне теоретик һәм практик яктан чиркәү тәгълиматын өйрәнүгә багышладым: теориягә килгәндә – чиркәү өйрәтмәсенә кагылышлы барча хезмәтләрне укып, тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, өйрәнеп чыктым; практикага килгәндә – елдан артык гомерем буе чиркәүнең һәр кушкан таләбен үтәп, рузасын тотып, бер гыйбадәтен калдырмыйча яшәдем. Нәтиҗәдә, инануымча, чиркәү тәгълиматы теоретик күзлектән мәкерле һәм зарарлы ялган, практик күзлектән – нәсара өйрәтмәсенең асылын яшереп тотучы иң тупас, дорфа хорафатлар һәм сихерчелек җыелмасы булып чыкты.

Дога китабын кулга алу, православлау руханилары тарафыннан бертуктаусыз кылына һәм нәсаралар гыйбадәте дип тәкъдим ителә торган йолаларга күз төшерү җитә, аермачык күрәсең – бу йолалар тормышның төрле хәленә, төрле вакытына, төрле вәзгыятенә яраклаштырылган сихерчелектән гайре берни түгел. Үлә калса туры оҗмахка керсен өчен сабыйга, мәгълүм сүзләр кабатлап, май сөртергә һәм чумдырып өлгерергә кирәк; бала тапкан хатын сафлансын, чистарынсын өчен

әфсен пышылдарга кирәк; эштә уңыш килсен яисә яңа йорттан тыныч тормыш китмәсен өчен, икмәк уңсын өчен, корылык бетсен өчен, сәяхәт имин тәмамлансын өчен, тән сырхаудан арынсын өчен, бакыйлыкка кичкән кешенең хәле җиңеләйсен өчен – боларның һәммәсенә өстәп тагын мең-мең хәл-халәт өчен мәгълүм әфсеннәр бар һәм рухани, тиешле сәдакасыннан калмаганда, ул әфсеннәрне тиешле урында укып чыга.

Мин, чыннан да, чиркәүдән баш тарттым, аның йолаларын үтәми башладым һәм туганнарым аңлардык итеп васыятемә теркәдем: җан тәслим кылган мәлемдә чиркәү руханиларын якын китермәгез, үлек гәүдәмне, һәрбер кирәксез һәм җирәнгеч нәрсәне алып аткан кебек, әфсенләмичә-төфсенләмичә, тизрәк юкка чыгарыгыз, исән кешеләргә яшәргә комачауламасын.

Әдәби эшчәнлеген һәм илаһ тарафыннан иңдерелгән сәләтен Мәсихкә һәм чиркәүгә каршы тәгълиматлар таратуга багышлый һ.б., үзенең дә, укучыларының да дөньяда, бигрәк тә кадерле ватаныбызда күпләп-күпләп тарата барган язмаларында һәм хатларында, фанатикларча ашкынып, православ чиркәвенең һәм нәсара диненең асылын тәшкил кылган барлык дини кануннарны җимерергә чакыра, дигән бәяләмәгә килгәндә исә, бу – гаделсезлек. Мин беркайчан да үз тәгълиматымны тарату белән мавыкмадым. Дөрес, иҗатымда Мәсих өйрәтмәсен үзем аңлаганча, үзем тойганча яктырттым һәм, кызыксынучы кеше булса, язганнарымны аннан яшермәдем, вәләкин һичкайчан аларны нәшер итмәдем; сорасалар гына Мәсих өйрәтмәсен ничек аңлавымны бәян кылдым; андыйларга ни уйлаганымны яшермичә әйттем һәм, кул астында очраса, китапларымны һәдия иттем.

Аннары болай язылган: ул алланы, галәмнең изге өчледә данлана торган барлыкка китерүчесен һәм химаячесен, ходаебыз Гайсә Мәсихне, кеше рәвешен алган алланы, дөньяны аклаучы һәм коткаручыны инкяр итә, безнең өчен, кешеләр өчен газап күргән һәм безне коткарыр өчен үлгәннән соң терелеп торган Мәсих ходайның орлыксыз яралуын һәм изге кыз Мариянең Мәсих туганчы һәм Мәсих туганнан соң гыйффәтле булып калуын танымый, диелгән. Аңлаешсыз өчлене һәм бүгенге көнгә һичнинди кирәге калмаган беренче кеше турындагы мәсәлне, адәм токымын ярлыкаучы илаһның саф кыздан тууын раслаган мәсхәрәле вакыйганы инкяр кылуым – хак, бу – гадел сүз. Рух булган илаһны, ярату-мәхәббәт булган илаһны, бар нәрсәнең башлангычы булган бердәм илаһны исә инкяр кылмыйм гына түгел, дөньяда аннан гайре һичнәрсәнең булмавына, тереклек итмәвенә ант эчәм, тормышның мәгънәсен дә, нәсара тәгълиматы кушканча, илаһ ихтыярын үтәүдә күрәм.

Тагын болай диелгән: үлгәннән соңгы тормышны, бүләк һәм җәзаны кире кагам, имеш. Үлгәннән соңгы тормышны тәмугта иблисләр белән бергә мәңгелек җәфа чигү яисә оҗмахта мәңге ләззәт кичү дип алсак, чыннан да, бу – гадел сүз, мин андый тормышны кире кагам; вәләкин бакый гомерне һәм җәзаның монда һәм һәр төштә, хәзер һәм мәңге булуын шулкадәр хак дип таныйм ки, өлкән яшьтә булуым сәбәпле, хәтта бер аягым белән кабердә басып торган килеш, бәдәни үләргә, ягъни яңадан туарга теләмәс өчен шактый тырышлык куям һәм ышанам: һәр яхшы гамәлем мәңгелек тормышның чын рәхәтен, ләззәтен арттыра, ә һәр начар гамәлем аны котылгысыз киметә.

Синод мине серле йолаларны (таинство) хурлауда, мыскыллауда фаш итә. Бу, чыннан да, гадел сүз. Барлык йолаларны да мин түбән, тупас, нәсара өйрәтмәсенә

һәм илаһны аңлауга каршы төшә торган сихерчелек һәм, аннан битәр, инҗилдә күрсәтелгән шартларны бозу дип күрәм.

Өлкәннәр чукынсын да, ди – нәсаралыкны үзе теләп, аңлап кабул иткәннәр бер хәл, әмма сабыйларны чукындыру әлеге коточкыч гамәлнең асыл мәгънәсен берничек аклый алмый; элгәре үк кавышкан парларга никах йоласы үтәүне, аерылышуга юл куюны һәм аерылышкан сыңарларны янә кушуны инҗил тәгълиматының һәм мәгънәсенә, һәм таләбенә каршы төшкән эшчәнлек дип исәплим. Гөнаһларның тәүбә-истигъфар (исповедь) юлы белән кичерелүендә зарарлы, яман ялган күрәм, мондый эшләр әдәпсезлекне, әхлаксызлыкны арттыра һәм гөнаһ кылудан курку хисен юкка чыгара. Зәйтүн мае яисә миро белән майлап чукындыруны, тәрегә (икона) табынуны, черегән мәет калдыкларын хөрмәтләүне, догалык китабы тулып яткан йолаларны, догаларны, әфсеннәрне тупас сихерчелек галәмәте дип кабул итәм; икмәк салынган шәраб эчеп гөнаһлардан арыну йоласында (причащение) бәдән-гәүдәне илаһилаштыруны һәм нәсара тәгълиматын бозып аңлатуны күрәм; изгеләштерүне, күрәләтә ялганга хәзерләнүдән тыш, Мәсих сүзләренә капма-каршы кылынган эшкә тиңлим – ул кемне дә булса укытучы, ата, остаз дип атауны тыйган (Маттай бәян иткән яхшы хәбәр 23:8-10).

Карарның, ниһаять, иң азагында минем соң дәрәҗәдә зур ялгышым телгә алынган: ул православлау халкы тоткан диннең иң изге кыйммәтләрен хурлап, серле йолаларның иң бөеге саналган изге евхаристияне мыскыллаудан да тайчанмый, диелгән. Әлеге серле йоланы (имеш) башкарганда атакайның нәрсә эшләвен читләмичә, ничек бар – шулай итеп, ягъни гади, төгәл рәвештә сурәтләвемә килгәндә, әйе, чыннан да, хакыйкатькә туры килә, бу – гадел сүз; ләкин әлеге серле йоланың (имеш) изге гамәл булуы һәм аны гади генә төстә, ягъни ничек бар – шулай итеп язуның мәсхәрәгә төшерелүе – юк, бусы һич кенә дә гаделлек түгел. Киртәне «иконостас» димичә киртә дип атау, чынаякны «портир»[2] димичә чынаяк дип атау гына мәсхәрә була алмый; коточкычның коточкычы, азагы-чиге күренмәс, имәндергеч мәсхәрә – бәгъзе кешеләрнең алдау һәм гипнозлаштыру эшендә чиксез мөмкинлекләр файдаланып балаларны, гади халыкны төрле сафсатага күндерүе: икмәк кисәкләрен мәгълүм рәвештә тураклап мәгълүм сүзләр әйтеп шәрабка орындырсаң, бу кисәкләргә илаһ күчәр; бу икмәкне шәрабтән исән кешеләрнең берәрсенә багышлап чыгарасың, ул кеше саулыктан аерылмас; мәрхүмнәрнең берәрсенә багышласаң, теге дөньяда анысының рухы шат булыр; кем дә кем бу икмәк кисәген ашаса, шуның үзенә дә илаһ керер.

Чәчең үрә торырлык явызлык бит бу!

Мәсихнең шәхесен ничек кенә аңласалар да, аның дөньяда явызлыкны бетерүгә юнәлтелгән тәгълиматы гаять гади, җиңел – бозып күрсәтмәгәндә ул, һичшиксез, кешеләргә яхшылык өләшә; тәгълиматның бусында исә барысы да яшерелгән, чумдыру, май сылау, хәрәкәтләр, әфсеннәр, икмәк кисәкләре йоту дәрәҗәсенә җиткереп үзгәртелгән, Гайсә өйрәтмәсеннән һични калмаган. Аерым бер зат пәйда булып, кешеләргә Мәсих тәгълиматының асылы сихерчелектән, иртәнге һәм төшке гыйбадәтләрдән, шәмнәрдән, тәреләрдән гыйбарәт түгеллеген искә төшерсә, Мәсих өйрәтмәсенең асылы кешеләрнең бер-берсен яратудан, явызлыкка карата явызлык кылмаудан, хөкем итмәүдән, бер-берсен үтермәүдән гыйбарәт булуын искәртсә, әле генә телгә алынган алдау-йолдаулардан төрле файда күргән

[2] Портир – евхаристия вакытында кулланыла торган чынаяк.

«Алар... сабыйлар күңеленә дә ялган орлыгы төшерә...» Лев Толстой оныклары белән. 1909 ел

бәгъзеләр шаккатмалы тәвәккәллек белән чиркәүләр, газеталар, китаплар, катехизислар аша тамак ертып: юк, Мәсих беркайчан да ант эчүне (присяга) зарар санамаган, үтерүне (сугышлар, җәзалаулар) тыймаган, ә явызлыкка сабыр торуны Мәсихнең иблис хәйләкәрлегенә ия дошманнары уйлап чыгарган, дип оран салачак.

Ә иң куркынычы: бу кешеләр өлкәннәрне генә алдап калмый, чиксез мөмкинлекләреннән файдаланып, Мәсихнең «балаларны алдаучының башы бәладән чыкмас» дип вәгазьләвенә карамастан, сабыйлар күңеленә дә ялган орлыгы төшерә. Бу затлар кечкенә файда-табыш юнәтер өчен мең өлеш артык явызлык кыла, Мәсих өләшкән һәм җәмгыятькә бәхет иңдерергә тиеш булган хакыйкатьне кешеләрдән яшерә. Алар тузган кәзәкигә һәм кырык тиен акчага кызыгып бишалты кешелек гаиләне суеп чыккан башкисәрдәй кылана. Ул юньсезгә бичаралар, югыйсә, бар киемен, бар акчасын болай да китереп бирерләр иде. Харап итмәсен генә! Вәләкин ул бәндә башкача гамәл кыла алмый. Аларны ун мәртәбә шәбрәк шартларда, купшылык, затлылык эчендә яшәтергә дә күнеп булыр иде. Ялган белән агулап кешеләрне генә харап итмәсеннәр! Вәләкин алар башкача гамәл кыла алмый. Бу – коточкыч хәл. Шуңа күрә дә аларның эшчәнлеген фашлау – дөрес эш, алай гына да түгел, хәтта зарури эш тә. Дөньяда ниндидер изгелек бар икән әле, ул һич кенә дә серле йолалар түгел, ә, һичшиксез, шушы дини ялганның чын йөзен ачудан гыйбарәт.

Әгәр чуаш кешесе үз потына каймак сылый яисә аны чыбыклый икән, битараф

рәвештә янәшәсеннән узып китәргә мөмкинмен, чөнки ул миңа чит-ят хорафаты хакына гамәл кыла һәм аның бу гамәле минем өчен изге булган төшенчәләргә кагылмый; вәләкин кешеләр, никадәр күп булмасыннар, хорафатлары никадәр тирәннән, борынгылыктан килмәсен һәм никадәр кодрәтле күренмәсен, мин ышанып яшәгән илаһ һәм миңа тормыш биргән, аннан битәр, башка кешеләргә дә тормыш бирә алган Мәсих тәгълиматы хакына тупас сихерчелек белән шөгыльләнә икән, мин моны сабыр гына күзәтеп тора алмыйм. Алар кылган гамәлләрне матур сүзләр артына яшермичә, үз исеме белән атыйм икән, димәк, илаһка һәм аның нәсара тәгълиматына ышанганга күрә, башка юлым юк минем, башкача эшли алмыйм, димәк, мин. Аларның, кара эшләрен танып, котлары ботына төшәр урынга, ялганнарын ачып салучыны кара эштә гаепләүләре – ялган гамәлләренең никадәр колачлы булуын ассызыклый; мондый вакыйгалар хакыйкый илаһны яшереп торган ялганга каршы көрәшергә чакырырга, илаһка һәм Мәсих өйрәтмәсенә ышанучы кешеләрнең санын арттыруга этәрергә тиеш, югыйсә.

Әхрамнан үгезләрне, сарыкларны һәм сатучыларны куып чыгарса, Мәсихкә да бүген «мәсхәрәче» ярлыгы тагылыр иде. Әгәр дә ул, терелеп торып, чиркәүдә үз исеменнән ниләр кылынганын күрсә, ихтимал, тагын да зуррак һәм тагын да гаделрәк ачу белән бу коточкыч антиминсларны, сөңгеләрне, хачларны, шәмнәрне, тәреләрне һәм сихерчелек кылып кешеләрдән илаһны һәм аның өйрәтмәсен яшереп торган ялганнарны чыгарып ташлар иде.

Синодның минем хактагы карарында гадел һәм гадел булмаган урыннар менә шул иде. Алар ышанабыз дигән нәрсәләргә мин, чыннан да, ышанмыйм. Ләкин алар халыкка «ул ышанмый» дип аңлаткан бик күп нәрсәләргә ышанам.

Нәрсәгә ышанам соң? Рух сыйфатында, ярату сыйфатында аңлаган илаһка ышанам. Үземнең аңарда булуыма, аның миндә булуына ышанам. Илаһ ихтыярының, иң анык рәвештә, адәм баласы булган Гайсә өйрәтмәсендә чагылуына ышанам, ләкин Гайсәне илаһ дип тануны һәм аңа табынуны иң бөек мәсхәрә (кощунство) дип саныйм. Кешенең бәхете илаһ ихтыярын үтәүдә дип аңлыйм, аның ихтыяры исә, инҗилдә язылганча, бер-береңне яратуда, башкаларга карата ягымлы мөнәсәбәттә торуда; канун һәм пәйгамбәрләр инҗилдә генә урын алган дип беләм. Яшәү мәгънәсе – калебеңдә ярату хисен арттыруда, дип инанам, бу хисне арттырудан кеше тагын да күбрәк бәхеткә ирешә; кешедә ярату хисе күбрәк булган саен аның үлемнән соң да күбрәк бәхеткә ирешәчәгенә ышанам; бу хис кенә ызгыш-талаш, ялган һәм ирексезлек хөкем сөргән дөньяда хөр татулык, дереслек һәм туганнарча ярату тойгылары үстерә, ягъни чын илаһ патшалыгы урнаштыра ала. Яратуга ирешер өчен исә бер генә чара күрәм: дога; ләкин әхрамнарда укыла торган һәм Мәсих тарафыннан катгый тыелган (Маттай бәян иткән яхшы хәбәр, 8:5-13) дога түгел, ә Мәсих үзе үрнәк итеп җибәргән дога – аулакта укылганы, тормышыңның мәгънәсен яңартуга һәм ныгытуга нигезләнгәне, илаһ ихтыярына бәйлелегеңне тануга корылганы.

Ышануларым кемне дә булса мыскыллый, борчый яисә кемнеңдер күңеленә вәсвәсә сала, нәрсәгәдер комачаулый, кемгәдер ошамый икән, нишлим – килешкилбәтемне үзгәртә алмаган кебек, бу инануларымны да үзгәртү хәлемнән килми. Үземә берьялгызыма яшисе, үземә берьялгызыма үләсе (һәм бик якын арада), шуңа күрә, илаһыма барыр көнем якынлашканда, мин аерата үзгә төрле ышана, үзгә төрле инана алмыйм. Фәкать минем ышану гына һәрвакыт һәм һичшиксез

Лев Толстойның Ясная Поляна утарындагы кабере. Хәзерге Тула өлкәсе

хакыйкый булырга тиеш, дип әйтмим, вәләкин башка андый – һәм гади, һәм анык, һәм акылым белән күңелем таләпләренә туры килерлек ышану да күрмим; андыйга тап булсам, ике дә уйламый шуны кабул итәр идем; чөнки илаһка хакыйкать кенә кирәк. Шулкадәр газапланып көч-хәл арынган уй-халәткә мин һичничек кире кайта алмыйм хәзер; оча торган кош кебек – ул да ватып чыккан йомырка кабыгына кире кайта алмый бит.

Нәсаралыкны хакыйкатьтән ныграк яраткан кеше озакламый чиркәвен яисә сектасын нәсаралыктан ныграк ярата башлаячак һәм, ахыр чиктә, аның мәхәббәте фәкать үзен (үзенең тынычлыгын) ярату белән тәмамланачак, дигән Кольридж[3].

Мин үзгә юлдан киттем. Мин әүвәл православ динен тынычлыгыма караганда ныграк яраттым, аннары чиркәүгә караганда нәсаралыкны ярата-рак төштем, хәзер исә барысыннан да ныграк хакыйкатьне яратам. Хакыйкать нәсаралыкның мин аңлаган шәкеленә, рәвешенә туры килә. Һәм мин бу нәсаралыкка ышанам, тыныч күңел белән рәхәт чигеп яшим һәм тыныч күңел белән рәхәт чигеп үлемемә якынлашам.

1901 елның 4 апреле,
Мәскәү

[3] Кольридж Сэмюэль Тейлор (1772-1834) – инглиз шагыйре, тәнкыйтьче. Толстой бу урында эпиграф-та күрсәтелгән.

***Тәрҗемәчедән**: Аңлашыладыр ки, журналның алдагы битләрендә урын алган анафема (диннән сөрү) белән бергә санасаң, бүгенге Россия кануннары нигезендә граф һәм язучы Лев Толстой рәсми рәвештә өч тапкыр экстремист дип танылган.*

***Рүзәл Мөхәммәтша** тәрҗемәсе* ■



КАЗАН ГУБЕРНАСЫ КЕРӘШЕННӘРЕ ышануларында мәҗүсилек күренешләре

Семён Максимов

УРМАН ИЯСЕ

Урман иясе кара йөзле булса да кешегә охшаган. Ул урманда яши, һәрвакыт баш киемсез йөри. Аның тышкы кыяфәтен керәшеннәр төгәл әйтә алмый, урманда озак адаштырып йөртә алуына карамастан, аннан бик курыкмыйлар. Берәр кеше урманда адашып юлны озак таба алмый йөрсә, керәшеннәр аны Урман иясе юлдан яздырган, диләр.

Бервакыт ир белән хатын, кечкенә малайларын алып, ат белән урманга баралар, аланда туктап, малайларын ат янында калдыралар да урманга кереп китәләр. Бераздан аланга чыксалар, малайны тапмыйлар, кычкырып карыйлар да төрле яктан эзләргә тотыналар. Бик озак эзләп таба алмагач, пошынып, өйләренә кайтып китәләр. Таныкчылар (понятойлар) җыеп, яңадан урманга, малайларын эзләргә баралар, барыбер таба алмыйлар. Шунда ата-ана: «Безнең улыбызны Урман иясе үзенә алып киткәндер», – дигән уйга килеп, борылып кайталар. Керәшеннәр Урман иясе кешене үтерми, бары тик үзенә алып китә дә үзе белән яшәргә калдыра, дип ышаналар.

Бер керәшен миңа: «Урман иясе урманда туктаган кеше янына килеп икмәк сорый, ашарына бирсәң, бик

Ахыры. Башы журналның 7 нче санында.

сөенә», – диде. Кеше икмәк бирсә, ул кешегә Урман иясе: «Мин хәзер сиңа да, балаларыңа да тимәм», – дип әйтә. Шуңа күрә кайбер керәшеннәр урманга барганда шунда калдырыр өчен зур бөтен икмәк алалар һәм аны куе агачлар арасына куялар. Соңыннан килгәндә алар икмәкне карый, әгәр ул икмәк куйган урынында булмаса, аны Урман иясе алган, дип ышаналар.

Кайбер керәшеннәр, умартада бал караганда, буш умартага икмәк белән бал куялар, соңыннан алар умартада булмаса, Урман иясе алган, диләр. Бер карт әби миңа менә нәрсә сөйләде: «Минем бабам чүнниктә (умарталык) торганда миңа әйтә иде: «Син, кызым, миңа икмәк күбрәк алып кил, минем янга Урман иясе бик еш килеп йөри, мин икмәкнең яртысын аңар бирәм». Ә мин бабайдан сорый идем: «Урман иясе ул озын тузгак җонлымы, әллә кешегә ошаганмы?» Минем сорауга бабай гадәтенчә: «Мин әйтергә куркам, кызым, Урман иясе бу турыда сиңа әйтмәскә кушты», – дип җавап бирә иде. Шул ук карчык соңыннан миңа үзенең дә Урман иясен күргәнлеген әйтте. Мин бу турыда сөйләвен сорагач, карчык түбәндәгеләрне сөйләде: «Без дәдәй белән урманга печәнгә киттек. Урманга кереп, яхшы печәнле аланлыкта туктадык. Дәдәй печәнне чабып ташыды, мин арбада калып тордым. Шулвакыт, мин арбада торганда, безнең этебез каты итеп өрә башлады. Мин дәдәйгә: «Безнең эт ник шулай каты итеп өрә икән?» – дип әйттем. «Тирә-якка карагач, куаклар артында бер кара кеше качып торганын күрдем. Мине күргәч, ул китеп күздән югалды». Мин карчыкка: «Ул берәр качкын булмадымы икән?» – дидем. Карчык, бик ышанып: «Качкыннарны мин беләм, бу Урман иясе иде», – дип кабатлады. Керәшен татарлары Урман иясенең барлыгына әле бүген дә ышана.

ШҮРӘЛЕ

Керәшен татарлары ышануынча, Урман иясеннән башка урманда Шүрәле исемле тагын бертөрле тереклек ияләре яши. Алар кешегә охшаган, ләкин бик зурлар, чәчләре кара, озын, гәүдәләре шәрә. Кайберәүләр әйтүенчә, аның гәүдәсе юк диярлек, сөякләрен аз гына ит каплаган. Керәшеннәр әйтүенчә, кайвакытта Шүрәленең бик озын бармаклары табыла. Ул бармакларны керәшеннәр өйләрендә саклый, төрле авырулардан дәвалану өчен файдалана. Андый вакытта авыруның тәненә «Шүрәле бармаклары» белән кагылалар, тиешле сүзләрне әйтәләр. Шүрәленең бармакларын ничек югалтулары турында миңа ишетергә туры килмәде. Шаккаткыч, керәшен татарлары аңлавынча, Шүрәленең имиләре бик зур, шунлыктан алар имиләрен иңбашларына салып йөртәләр. Моннан чыгып, аларны татарлар хатынкызга саный, дип тә әйтеп булмый. Шүрәлеләрнең Урман иясе белән үзара бәйләнеше дә билгеле түгел. Казан губернасының байтак төбәкләрендә әле бүген дә «Шүрәле утравы», «Шүрәле чокыры», «Шүрәле елгасы» дигән атамалар бар. Китерелгән сүзләр бу урыннарда Шүрәлеләр күренгәләвен раслый.

Шүрәле бигрәк тә кешеләр белән кети-кети уйнарга ярата. Кешене күрү белән ул хихылдап көлеп: «Хи, хи, хи... Әйдә, синең белән кети-кети уйныйбыз!» – дип әйтә. Кеше курка, Шүрәле аны үтергәнче кытыклый. Керәшеннәр Шүрәледән бик куркалар.

[1] Максимов С. Остатки язычества в современных верованиях крещенных татар Казанской губернии. – Казань: Типография Императорского университета, 1876.

Шүрәле. Рәссам Әхсән Фәтхетдинов

Гомумән, керәшеннәр әйтүенчә, Шүрәлене күрүчеләр бик күп, аның турында бик җентекле хикәяләр сөйләнелә. Менә ул хикәяләр:

Бер кеше урманга утынга барган. Утын кисә башлагач, аның янына Шүрәле килгән дә: «Синең исемең ничек?» – дип сораган. Утын кисүче: «Минем исемем – Былтыр кысты», – дип җавап биргән. Шүрәле аңар: «Әйдә, синең белән кети-кети уйныйбыз!» – дигән. Утын кисүче бу вакыт чөй кагып төп яра икән. Шүрәленең тәкдименә җавап итеп: «Син бармакларыңны агач ярыгына тык, без төпне тизрәк ярып бетербез дә кети-кети уйнарбыз», – дигән. Шүрәле күнгән. Шүрәле бармакларын чөйләнгән төп ярыгына тыгу белән утын кисүче чөйне бәреп чыгарган да үзе читкә китеп яшеренгән. Чөй чыккач, Шүрәленең бармаклары ярыкка кысылганлыктан, ул авыртудан кычкыра башлаган. Тавышка шүрәлеләр йөгерешеп килеп җыелганнар да: «Бармакларыңны кем кысты?» – дип сораганнар. Шүрәле: «Былтыр кысты!» – дип җавап биргән. Җыелган шүрәлеләр, агай-энеләренең шундый җавабына бик гаҗәпләнгәннәр дә: «Былтыр кысканга нигә быел гына кычкырасың?» – дигәннәр. Шүрәле җавап бирмәгән. Иптәшләре Шүрәлегә ачуланганнар, бармакларын төп ярыгыннан тартып алганнар да үзләре белән алып киткәннәр.

Тагын бер керәшен миңа бабасының кырда урак урганда гаиләсе белән ашарга утыргач, алар янына Шүрәле килүе турында сөйләде. Карт бабай Шүрәлене танымаган, үзләре белән ашарга утырткан. Ашаганнан соң Шүрәле: «Әйдә, синең белән кети-кети

уйныйбыз!» – дип, Карт бабай янына килә башлаган. Карт бабай эшне аңлап алган да ыштан бавын кулына алып: «Әйдә, уйныйбыз», – дип, Шүрәле янына килә башлаган. Шүрәле ыштан бавын күргәч бәйләмәсеннәр, дип курыккан да чабып качкан. Керәшеннәр, Шүрәле ыштан бавыннан бик курка, дип ышаналар, карт бабай Шүрәлегә ыштан бавын күрсәтмәсә, Шүрәле аны исән калдырмас иде, дип уйлыйлар.

Керәшеннәр сөйләвенчә, Шүрәле кыр буйлап иң яхшы атларда чабарга ярата, озак итеп, атны тирләтеп, алҗытып бетергәнче чаба. Атта чапканда ул үзе дә ат кебек яңгыратып кешнәп җибәрә.

Бер керәшеннең бик яхшы аты булган. Атның кырдан гел күбекле тиргә батып кайтуын күреп, ул бик аптыраган, ләкин моның сәбәбен белә алмаган. Бер танышы аңар атыңа Шүрәле атланып чаба, дип әйткән. Шүрәлене атка ябыштырып авылга кайтарыр өчен хуҗа атның аркасына сумала сылап куйган. Сумалаланган ат кырга чыккач, Шүрәле гадәтенчә атланып чаба башлаган. Чабып туйгач, аттан төшәргә уйлаган, ләкин күтәрелә дә алмаган – сумала белән ат аркасына җабышкан. Шүрәле куркуыннан кычкыра башлаган. Шүрәле тавышы атны куркыткан. Ат чабып, Шүрәлене хуҗаның ишегалдына алып кайткан. Аты өстендә Шүрәлене күргәч, хуҗа күсәк алып җайдакка суккалаган да кире җибәргән. Шуннан соң Шүрәле керәшеннең атына кагылмаган.

ПӘРИ

Пәри атамасы керәшеннәрдә байтак усал рухларны күздә тота. Алар кешегә начарлык кылып, эшләрен бутарга тырышалар. Рухның атамасы аның фарсы чыгышлы икәнен күрсәтә (фарсы телендә «пәри» канатлы рухны аңлата). Керәшен татарлары Пәри рухларының бик ямьсез кешеләр рәвешендә булуын әйтәләр. Пәриләрнең йөзләре кап-кара, ике күз урынына бер генә күзле булганлыктан, бигрәк килбәтсез, тешләре гел ыржайган, чәчләре дуңгыз кылы шикелле өскә тырпаеп тора. Шундый килбәтсез, усал нәрсәләр, керәшен татарлары белгәнчә, мунчаларда, кеше тормаган ташландык, буш йортларда яшиләр. Бигрәк тә еш алар авылдан читтә, җиргә казып ясалган мунчаларда яшиләр. Андый мунчалар, буш йортлар тирәсендә керәшеннәр аеруча кич белән йөрергә куркалар, пәриләр үзләре яннарына алып кереп, алдап мыскыллар, дип уйлыйлар. Пәриләр турында керәшеннәр менә нәрсә сөйли.

Бер авыл янында җиргә казып ясалган мунча булган. Мунча яныннан узган саен керәшеннәр мунчада чабынган тавышлар ишеткән яисә мунчадан ташлар атканны күргән. Күргән керәшеннәр әйтүенчә, мунчада бик күп Пәриләр торган, шунлыктан анда кичләрен мунча ягарга ярамаган. Пәриләрдән котылу өчен керәшеннәр мунчаны сүтеп, башка урынга күчергән.

Таныш керәшен миңа үзенең Пәри күрүен болай сөйләде. «Иртән мин авылдан читтә, җиргә казып ясалган мунча яныннан узып бара идем, анда кемнеңдер чабынганын ишеттем. Мин якынрак килеп, төтен, пар күрмәсәм дә, чабынган тавышларны яхшырак ишеттем... Шаккаттым, курыктым да мунча яныннан китәргә генә җыендым, мунчадан ак кием кигән ниндидер кеше чыкты да: «Кер, чабынырбыз!» – дип, мунчага чакыра башлады. Чакыруны ишетеп, мин куркуымнан бераз читкә йөгердем дә катып калдым... Алга да, артка да бара алмыйм, күз алларым караңгыланды. Урынымнан кузгала алмаганлыгымны аңлагач, мин чирәмгә яттым да, минем яннан

күп халык узгандай булды. Барысы да гаҗәпләнделәр һәм үз-үзләренә: «Аңар пәри тимәсен тагы... Монда ятмаска иде!» – дип әйттеләр. Мин барын да ишетеп, сизеп яттым, ләкин бер сүз дә әйтә алмадым, телем әйләнмәде. Мин яткан арада өйдәгеләр борчыла башлаган. Мине эзләргә тотынганнар, таба алмаганнар. Бер карт, мине табып, эзләгәннәрен белгәнлектән, өйгә озатып куйган. Өйдәгеләр миңа Пәри кагылганын аңладылар. Күремче карчыкны чакырып, мине аңга китерделәр».

Бер керәшен хатыны миңа: «Бервакыт минем әти кабакка кереп бераз аракы эчкән дә өйгә кайтырга юнәлгән. Юлда таныш булмаган бер ят кеше очрап аны: «Әйдә, кереп бераз эчеп чыгыйк», – дип, кабакка керергә кыстый башлаган. Әти күнмәгән. Ят кеше аңар: «Монысына керәсең килмәсә, әйдә, чокырдагы кабакка керәбез», – дип әйткән. Әти, риза булып, кабакка кергән дә, ят кеше тәкъдименә кушылып, бераз аракы эчкән. Кабактан чыккач, алар тагын бер кабак янына барып җиткәннәр. Ят кеше әтинең чабуыннан тотып кабакка сөйрәгән: «Әйдә, бу кабакка да кереп эчәбез», – дип ялварган. Шунда әти: «Кит моннан! Син Пәри!» – дип әйткән. Әйткәндә әти чукынып җибәргән һәм дога әйткән. Ят кеше шунда ук юкка чыккан. Әтиебез, бик исерек булса да, нык курыккан, өйгә чабып кайткан», – дип сөйләде.

Әле күптән түгел генә бер керәшен авыланда, керәшеннәр ышануынча, Пәриләр яшәгән йорт бар иде. Ул йортка керәшеннәр керергә кыймый иде. Керәшеннәр әйтүенчә, керергә уйлаучыларга өйдә яшәүчеләр ташлар, кирпечләр аталар икән. Бу йортта берничә тапкыр келәү дә уздырган булганнар, пәриләр барыбер басылмаган, үткән-барганга таш, кирпеч ыргытуларын дәвам иткәннәр. Келәү уздырырга йортка священник ничек кергән – бер дә аңлашылмый. Керәшеннәр пәриләрнең йортта төнлә генә котырганнарын аңлыйлар, көндез анда тыныч булган. Йорт урамга караган, ә икенче ягы белән тыкрыкка чыга, дип әйтү дә артык булмас. Минем фикеремчә, уйдырма Пәриләргә төннәрен йортка кереп-чыгып йөрергә бу бик кулай була. Андый уйлар йорт хуҗасының башына да килмәгән, ул, берничә ел анда тормаганнан соң, башка авыл урысына сатып җибәрде. Пәриле йортны сатып алган кешенең бу йортта ничек яшәве ишетелмәде.

Лаеш өязендәге Колай авылында, тау башында, авылдан читтәрәк яхшы таш йорт бар. Бу йортта бер кеше дә яшәми, керәшеннәр әйтүенчә, анда Пәриләр яши икән. Мин бу йорт яныннан күп мәртәбә узып йөрдем, берничә мәртәбә хәтта руслардан да: «Бу йортта яшәргә ярамый, анда җеннәр оялаган», – дип ишеттем. Элекке заманда бу йорт рус алпавытыныкы булган, инде ул вакытта ук бу йортта җеннәр бар, дип сөйләгәннәр. Хәзер бу йорт бай татар кулында, ә җеннәр хәзер дә шунда, дип әйтәләр. Керәшеннәр сөйләвенчә, рус алпавыты йортта төне буе келәүләр оештырып караган, ләкин пәриләр таш ыргытуларын туктатмаган, шулай ук яңа хуҗа – татар агай ничә мәртәбә йорттан пәриләрне куар өчен Коръән укытып караса да, файдасы булмаган...

Керәшеннәр ышануынча, пәриләр ир, хатын-кыз, яшь егет-кыз сурәтендә һәм балалар кебек тә булалар. Мин үзем дә «пәри баласы» дип йөртелгән малайны белә идем. Ул кечкенәдән берүзе землянкада утыра иде. Күрергә бик ямьсез, йөзе кап-кара, озынча башлы, зур кара күзле, муены озын, нечкә. Ул гел яланаяк йөри иде. Керәшеннәр аны Пәри баласы, тугач, әти-әниләре җир мунчада караусыз калдырган, шунда Пәриләр алыштырып киткән, дип әйтәләр иде. Ул малайның авы-

Тәрәзәдәге Шүрәле. Рәссам Әхсән Фәтхетдинов

зы гел күбекле була иде. Урамда иптәшләре белән уйнаганнан соң ул: «Мин үземнекеләр янына кайтам», – дип, землянкага кереп китә иде. Юлда очраган кешегә ул таш ыргыта иде. Ул малай унбиш яшендә үлде.

Мин акылы тулы булмаган бер керәшен һәм бер татарны белә идем. Алар турында керәшеннәр: «Бу гади кешеләр түгел, Пәриле кешеләр», – диләр иде. Керәшеннәр, хаста ир кеше үзенең авыруын тоймыйча, гел кызлар турында сөйләшә икән, аның янында Пәри кызы тора, диләр. Андый кеше изге тәрене үпми. Аңар тәрене көчләп кенә үптереп була. Әгәр дә хатын-кыз йә кыз бала, авырып китеп, гел егетләр турында сөйләшсә, аларны Пәри җегете белән саташкан, диләр. Бер хатын-кызның миңа сөйләвенчә, бер керәшен кызы ярты ел буе Пәри егете белән җенси элемтәдә булган. Кыз үзен бик тыйнак тоткан, иптәшләре белән уйнарга урамга да чыкмаган. Үзенең эшләрен эшләгәндә, пәри егете килгәнен сизсә, кинәт барын ташлап, пич башына менеп китә торган булган. Анда сөйгәнен күреп белгәч, төшеп, яңадан эшләренә тотына икән. Туганнары аның шундый гадәтеннән оялып, бу турыда берәүгә дә сөйләмәгәннәр. Менә әнисе, укымышлы керәшен хатыны киңәше белән, бу турыда священникка әйткән. Ә ул кызга дога укып, кач кигертергә кушкан. Әнисе, священник сүзен тыңлап, кызына кач кигерткәч, кызы аны салып атып бәргән. Әнисе аңа качны яңадан кигерткән дә салдыртмаган. Пәри кыз янына килеп

йөрүеннән туктаган, кыз яңадан савыккан. Соңыннан кыздан Пәри егете матур идеме, дип сораганнар. Кыз аныклап әйтә алмаган, гадәти яшь егет иде, дигән. Керәшеннәр ышануынча, андый хәлләр егетләр белән дә була икән.

Керәшеннәр Пәри йөкле хатыннарның бәбиен туганчы ук урлый ала, дип ышаналар. Шунлыктан керәшен хатыннары авырлы вакытта Пәриләрдән бик куркалар. Алар йортта үзләре генә калмаска тырышалар. Йоклаганда яннарына Пәри килмәскә баш асларына пычак салалар. Авырлы хатынга йортта ирсез үзе генә йокларга туры килсә, Пәри аны ире белән йоклый, дип белсен өчен ул баш астына иренең бүреген салып ята.

Яңа туган баланы керәшеннәр өйдә үзен генә калдырмыйлар, югыйсә аны Пәри урлап, аның урынына, инде сөйләнгән малай кебек, үз баласын калдырып китүе бар. Бала кайда гына (бишектә яисә башка урында), нинди вакытта йокласа да аның мендәре астына керәшеннәр пычак сала. Баланың баш астындагы пычак аны Пәриләр йогынтысыннан саклый. Әгәр бала әнисе белән йоклаганда читкәрәк китсә йә идәнгә төшсә, керәшеннәр аны пәри төртеп төшергән, дип әйтәләр. Әнисе, уянып, баласын тапкач: «Әле ярый вакытында уянып өлгердем, Пәри алып китәсе икән...» – ди.

Пәриләрнең шундый эшләре турында ишетеп үскән керәшен татарлары барысы да Пәриләрдән куркалар. Юлда йә урамда ялга утырырга туры килсә, торып киткәндә керәшеннәр Пәри кагылмасын өчен, утырган урыннарына төкерәләр. Мин бервакыт энем белән урманга бардым. Анда без бер җирдә утырдык та торып китә башладык. Энем миннән алдарак торды да җиргә төкерергә тотынды. Ә мин (ул вакытта школада укучы) тордым да төкермичә читкә киттем. Энем моны күреп курыкты һәм миңа: «Урыныңа ник төкермисең! Бар, төкер, югыйсә сиңа Пәри кагылыр!» – диде. Мин аны тыңламадым, аңар Пәриләрнең христианнарны җиңәргә кодрәте җитмәвен аңлатырга тырыштым.

Йомгаклап, тагын керәшеннәрдән ишеткән бер сәер хәлне сөйлим. Унҗиде яшьлек кыз туганнары белән мунчага барган. Чабынгач, ял итәргә мунча алдына чыккан. Аннан аны кызыктырып, алдап, Пәри егетләре авыл артындагы әвеннәр янына ияртеп алып киткән. Туганнары, мунчадан чыгып кызны күрмәгәч, бик куркышканнар, авыл тирәсендә эзләргә киткәннәр. Кызны әвеннәр янында, төнлә әтәчләр кычкыра башлагач кына тапканнар. «Син нишләп әвеннәр янына киттең?» – дип сорагач, ул: «Мине Пәриләр алып китте, мин алар белән туйда булдым, тапмаган булсагыз, мин дә Пәригә кияүгә китәсе идем», – дигән. Ул чакта кыз үзе дә Пәригә әйләнгән булыр иде.

Сөйләнгән хәл кыш көне, нардуан вакытында булган. Керәшеннәр әйтүенчә, нардуан вакытында Пәриләр бәйләнгән чылбырларыннан ычкыналар да бик күпләп җир өстендә йөриләр. Нардуан беткәч, Пәриләр богау чылбырларын яңадан кияләр. Нардуан вакытында керәшеннәр Пәриләр очравыннан куркалар, бу көннәрдә алар бигрәк тә Албасты белән дә очрашудан куркалар.

АЛБАСТЫ

Албасты Пәриләр затыннан, аларның да иң усалларыннан була. Керәшен татарлары әйтүенчә, ул җиргә нардуан вакытында гына чыга, башка вакытта бик сирәк күренә. Аның тышкы кыяфәте турында керәшеннәр берни дә әйтә алмый. Албастының бик зур, формасыз җисемле икәнен генә беләләр. Ул җирдә йөри, башта

ерактан кешегә эт зурлыгында, якынайгач зураеп, курыккан кеше күзенә богыл күк булып күренә. Аның башы, гәүдәсе, сурәте нинди – берәү дә әйтә алмый. Зур богыл кебек булуы гына албастының тышкы килбәтен тасвирлый. Албасты күбесенчә күперләр, урам һәм юл чатлары тирәсендә күренә. Шуңа күрә керәшеннәр нардуан вакытында ул урыннарда йөрергә курка. Алар Албасты бәйләнеп басар, диләр. Албастының исеме дә аның кешеләрне «басарга» яратуына ишарә – «алны басу» фигыленнән алынган. Албасты һәрвакыт кешегә каршы килә, аягыннан ега да бөтен авырлыгы белән авып, чалкан яткан кешенең алгы санын баса.

Албастыга очраудан сакланыр өчен керәшеннәр, нардуан кичләрендә урамга ялгыз чыгарга туры килгәндә, кулларына утлы чыра алалар. Алар: «Албасты, янган чыраны күрү белән очраган кеше чырасы белән өтәр, дип уйлар», – диләр. Шулай итеп, Албасты куркуыннан каядыр югала.

Бер керәшен хатыны үзенең Албасты белән очрашуы турында болай сөйләде: «Безнең бик яхшы атыбыз бар иде. Бервакыт кичкә каршы ул капкадан чыгып кырга чапты. Мин аның артыннан киттем. Мин атны тоткан арада кич булды, караңгы төште – мин курка башладым... Шул арада мин кемнеңдер ерактан өчләп җиккән ат белән якынлашып килгәнен күрдем. Мин эчемнән кырда ялгыз булмавыма сөенеп, аларга каршы бара башладым. Якыная башлагач, каршыма ут йомгагы тәгәри сыман күренде дә, кинәт бик зураеп, богыл хәтле булды. Шунда мин аның Албасты икәнен аңладым, бик курыктым, кычкырып җылый-җылый, чукына-чукына өйгә чаптым. Чукынгач, Албасты миңа якын килергә кыймады, минем яннан җил кебек дулап узып китте. Мин Албастыдан куркуымнан ике атна авырып яттым».

Тагын бер керәшен миңа, беркөнне кич белән ишегалдына чыгып утыргач, Албасты күргәнен сөйләде. Ай яктысында вак кар явып торган. Искәрмәгәндә аның абзар ягына күзе төшкән дә анда ниндидер зур нәрсә торганын күргән. Башта бик шикләнмәсә дә, зур нәрсә хәрәкәткә килгәч, курку, өйгә кереп качкан. Өйдә бераз тынычлангач, ул күренгән нәрсәнең карда калган эзен карарга ишегалдына чыккан. Аның эзләре кеше эзенә охшап, зурлыгы аршын ярым тирәсе булган. Бу эзләрне абзар капкасы янында күренгән Албасты калдырган икән. Керәшеннәр, нардуан вакытында кырга чыгып, быелгы елның икмәккә нинди уңышлар китерәсен белергә тырышалар. Кыр юлына чыккач, алар сөйләшмичә тынлык саклыйлар, авыл янындагы җиде юл чатына киләләр дә (керәшеннәр аңлавынча, җиде юл чаты нәкъ авыл кырыенда була) дикъкатьләп тыңлыйлар... Әгәр дә ерактан гөрелдәп килгән тавыш ишетелсә, икмәк яхшы уңа, әгәр атта чабып барган тавыш яисә чана шыгырдавы, эт өргәне ишетелсә, зур уңыш булуы бик шикле. Керәшеннәр әйтүенчә, багу иткәндә ишетелгән атлы кеше чапкан тавышлар Албастыдан килә. Шуңа күрә тавышлар якыная башлау белән керәшеннәр ашыгып өйләренә кайтып китәләр. Әгәр дә атлы кеше чапкан тавышлар якынайганда урыннарында калсалар, Албасты бик тиз килеп, аларны «баса» башлый... Кешенең йоклаганда кемдер «баскан» шикелле буылып килүен дә керәшеннәр Албасты эше, дип аңлаталар. Керәшеннәр әйтүенчә, йоклаганда кешенең иркен сулышы кысылу да Албасты «басуы» нәтиҗәсе.

Николай ПЕТРОВ-TEKIN
тәрҗемәсе. ■

«ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ» БИТЛӘРЕННӘН

Иске Кулаткы районы флагы

ИСКЕ КУЛАТКЫ

Ульянов өлкәсенең көньягында урнашкан. 1943 елга кадәр – Урта Идел, 1943 нең 19 гыйнварыннан Ульянов өлкәсенә керә. Мәйданы – 1178 $км^2$. Үзәге – шәһәр тибындагы Иске Кулаткы посёлогы (Ульянов шәһәреннән 230 км көньяк-көнбатыштарак). Халкы – 17505 (2002), ш.и. татарлар – 16342 (1979 да – 20954, 1989 да – 18270) кеше. И.К.р. терр-ясендә татарлар 17 йөз ахыры – 18 йөз башында күренә башлый. Темников, Сембер, Казаннан күчеп килгән морзаларга һәм йомышлы татарларга монда Пётр I указы б-н җирләр бирелә. 1917 дә И.К.р. терр-ясендә 71 мәчет, 45 мәктәп һәм мәдрәсә (иң атаклысы Зимницы авылындагы Хансөяровлар мәдрәсәсе), 6 земство мәктәбе эшли. Хәзерге вакытта районның 18 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. 5 татар үзешчән коллективы: халык драма театры, «Гөлшаян» төркеме, «Лира» вокаль төркеме, «Йолдызчык» балалар бию коллективы, Г.Н.Алтынбаева җитәкчелегендә бию коллективы эшли. Район китапханәләре татар телендә вакытлы матбугат алдыра, аларда «Кулаткым минем, туган ягым, синдәй гүзәл бармы тагын?» дигән китап күргәзмәләре даими үткәрелә. 1996 дан «Яңа дулкын» җирле телеканалы эшли. Татар халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында 19 клуб учреждениесе, балалар сәнгать мәктәбе, Х.А.Әбләзев исем, тарих-туган якны өйрәнү музее эшли. Районда татар халкының тарихы һәм мәдәнияте б-н бәйле чаралар: «Сабантуй» һәм «Нәүрүз»

Иске Кулаткы районы гербы

бәйрәмнәре, «Туган ягым – мәхәббәтем минем» фестивале, «Түгәрәк уен» Бөтенроссия фольклор коллективлары фестивале үткәрелә. 2005 тән «Хансөяров укулары» фәнни-практик конференциясе (суфи, шәех Х.Хансөяров истәлегенә) уздырыла. 25 мәчет, ш.и. 5 се – район үзәгендә. Сов. Союзы Геройлары: М.И.Липов, Н.Н.Нугаев, В.С.Хәбиев, З.С.Хөсәенов, Соц. Хезмәт Герое Т.К.Рәшитова, дәүләт эшлеклесе Т.А.Әбдерәзәков, икътисадчы К.М.Азизов, техник фән. д-ры Э.Ә.Ганиев, җырчы Р.З.Ильясов*, биол. фән. д-ры Р.Х.Насыйров, тарих фән. д-рлары Р.Т.Әмирханов, Ф.А.Рәшитов, М.З.Тутаев, икътисад фән. д-ры А.В.Улюкаев, социолог Н.С.Фәтхуллин, пед. фән. д-ры Я.И.Ханбиков, психол. фән. д-ры Р.М.Шамионовларның тормышы һәм эшчәнлекләре И.К.р. б-н бәйле.

*Җырчы, Татарстанның халык артисты Мөнир Әхәт улы Якупов та шушы төбәктән – Иске Атлаш авылыннан.

Иске Кулаткы районының иске гербы

Татар энциклопедиясе сүзлеге. II том. – Казан, 2010. – Б.592.

Илдар Гыйльметдинов:

«Булачак һәр педагогны әүвәл педколледжда укытыр идем...»

Әңгәмәдәш – Ләбиб Лерон

– Сез – илкүләм танылган шәхес, җәмәгать эшлеклесе, депутат, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе. Заманында Казан педагогика институтын тәмамлагансыз, армия сафларында хезмәт иткәнсез, консерватория каршындагы музыка мәктәбендә физикадан дәрес биргәнсез, берара мәктәп директоры да булып эшләп алгансыз. Кама Тамагы һәм Актаныш районнарында комсомолның икенче һәм беренче секретаре вазифасын башкаруыгыздан да хәбәрдармын. Аннары башкалабыз Казанда актив эшчәнлек алып бардыгыз, яшь буынны тәрбияләүдә үзегездән шактый саллы өлеш керттегез. Һәм әле дә аларга хәлкадәри булышырга тырышасыз...

Шушы кадәр күпкырлы, бай биографиягә ия шәхес буларак, әйтегез әле, тормышыгызда мәшһүребез Тукайның (иҗаты турында сүз бара, әлбәттә) йогынтысы булдымы, гомумән, татар әдәбияты, аның классик әдипләре хакында ни әйтер идегез?

– Әнием Фәния татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Актаныш районының Түбән Гәрәй авылы кызы. Бабам Малик мәктәп директоры булып эшләгән. Кызганыч, ул эшләгән авыл хәзер юк инде, Түбән Кама сусаклагычы төзелгәч, су астында калды. Әниемнең абыйсы Рифкатъ тә укытучы иде. Әтием Ирек, аның апасы Мәрзия һәм җизнәсе дә гомер буе балаларга аң-гыйлем бирде. Кыскасы, укытучылар даирәсендә үсү, тәрбияләнү сәбәпле миңа таләп кечкенәдән гаять зур иде. Аеруча татар теле һәм әдәбияты дәресен «биш»ле билгесе алу өчен генә түгел, чынлап та яратып, күңел биреп укый идем. Авыл һәм мәктәп китапханәсендәге һәр китапны, әдипләребезнең яңа чыккан әсәрләрен барысын да укып бардым. Аеруча «Казан утлары»н ярата идем, чөнки әсәр китап булып басылганчы шактый вакыт уза, ә аның журналда басылачак дәвамын түземсезлек белән көтеп аласың... Татар әдипләренә хөрмәт, Тукай әкиятләренә, шигъриятенә мәхәббәт тә кечкенәдән тәрбияләнде. Бер рекламада бала анасына: «Әни,

безнең өйгә бүтән Су анасы кермәсме соң?» – дип сорый. Мин гаҗәпкә калдым: Су анасы Тукай тарафыннан тискәре герой итеп тәкъдим ителмәгән, ә карак малай артыннан үз тарагын гына сорап барган. Шуның асылын белмәү сәбәпле, безнең халык Су анасын тискәре образ буларак кабул итә.

Безнең мәктәпкә әдипләр еш килде, хәтта төркемләп тә кайталар иде. Әтием, мәктәп директоры булгач, мөхтәрәм әдипләрне ашарга, төн кунарга безгә чакырды. Бер бөек әдибебезнең (исеме хәтердә калмаган) таягын калдырып китүе хәтердә. Ул таяк озак еллар безнең өйдә кадерләп саклады. Туфан ага Миңнуллин исә әтинең якын дусты булды. Заманында алар Кама Тамагы районының Карамалы мәктәбендә бергә укыган.

Бездә укытучылар бик гыйлемле булды. Хәзер рус-татар телен бәрештерергә тырышалар, аларны каршы куялар. Мин әйтәм: «Сез телне сәгатьләп санамагыз! Күп әйбер укытучының үз фәнен яратуыннан һәм балаларга аны ничек итеп җиткерүеннән, аларда нинди мотивация тудыруыннан тора». Безнең шундый укытучылар бар иде: фәнне нибары унбиш минут аңлаталар да, калган утыз минутны укучылар белән

дөнья, тәрбияви темалар турында сөйләшәләр. Шул унбиш минут эчендә яхшы итеп төшендерәләр иде ки, син яңа теманы теләп үзләштерәсең һәм өйгә кайткач яңадан, кызыксынып, дәреслекне һәм башка өстәмә әдәбиятны ачып укыйсың. Укытучы икенче дәрестә минут эчендә синең белү-белмәвеңне ачыкларга өлгерә. Менә безне шундый укытучылар укытты. Бу укытучыларның күбесе педучилище тәмамлаган. Шуңа күрә мин мәктәпкә киләчәк һәр педагогны Арча яки Минзәлә педколледжында укытыр идем. Кызганыч, 1990 нчы еллардан укытучыга булган игътибар кимеде. Баллары җитмәү аркасында, башка уку йортларына кабул ителмәү сәбәпле генә дә педагогика яки татар теле, әдәбияты бүлегенә укырга керүчеләр бихисап. Ничек итеп без, укытучыларыбыз йомшак булу сәбәпле, мәктәптә тел, әдәбиятны ярата алырлык балалар әзерли алыйк? Совет чорында иң гыйлемле, акыллы балалар гына югары уку йортларына укырга керә иде. Институт тәмамлап авылга кайтсаң син зур, дәрәҗәле кеше идең, ә университетта укып йөрү Аллаһы Тәгаләнең бер бүләге булды. Югары уку йортына керә алучылар класстан берничә генә бала иде, ә бүген исә бюджет урыннарына гына да 55%ы укырга керә. Баланың сәләт-теләгенә игътибар итмичә, аны соңгы сарык-бозауны сатып булса да югары уку йортына кертү, ә белеме җитмәгәннәренең педагогика институтын сайлавы һәм укытучы булып китүләре гадәти күренеш булды. Мәктәпләребезгә шундый йомшак, сәләтсез укытучыларның килүе, әлбәттә, татар теленә һәм әдәбиятына булган мәхәббәтне сүрелдерде. Аңлашыла ки, балада фәнгә, туган телгә булган мәхәббәт иң беренче чиратта укытучыдан, аның эшли белү сәләтеннән тора.

– Арча педколледжы диюегездә хаклык гаять зур, чөнки Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек бөек шәхесләребез дә шушы югары уку йортын тәмамлаган.

– Минем әнием дә Минзәлә педучилищесында белем алган. Аларны бу уку йортында фән укытырга гына түгел, ә тәрбияви мәсьәлә, класстан тыш чараларны оештырырга да өйрәткәннәр. Училищеларда яхшы музыка тәрбиясе бирелгән. Мәктәп тәрбияви мәсьәләдән читләште, дип сөйләргә яратабыз. Югыйсә, һәрбер фән аркылы тәрбия эше башкарылырга тиеш. Кызганыч, балага фән нигезләрен төшендерә һәм бер үк вакытта тәрбия дә бирә торган укытучыларыбызның саны кимеде. Бу турыдан-туры телебез, әдәбиятыбыз язмышына да кагыла.

Телне саклауның яңа юлларын эзләргә кирәк. Мин Казан дәүләт педагогика университетын кире кайтарыр идем. Ул КФУ кысаларына кереп юкка чыкты. Укытучыларны тәрбияләү үзе бер аерым юнәлеш. Аларны кызыксындыру өчен аерым стипендияләр булдыру шарт. Телне өйрәтүне балалар бакчасыннан башларга тиешбез. Кече яшьтә баланың өч телне үзләштерергә мөмкинчелеге бар. Кызганыч, әлегә без бу юнәлештә аз кыймылдыйбыз, яңа методика һәм программалар кирәк.

Федераль автономиянең төрле проектлары бар. «Куян кучтәначе», «Әбием әкиятләре» һ.б. Без укыту әсбапларын уйнау формасында тәкъдим итәбез. Бала уйнап, әкият һәм музыка тыңлап тәрбияләнергә тиеш. Шул ук вакытта телне дә үзләштерүе, дөньяны да танып белүе шарт. Кызганыч, шушы методикалар белән эшли ала торган педагогларның саны аз.

– Әтиегез – Кама Тамагыннан, әниегез исә – Актаныш якларыннан. Кем әйтмешли, ике төбәк – ике холык. Мәсәлән, Актаныш – җырга-моңга,

ВОЛГА

Этно Дар
Этнический фестиваль
молодых мастеров Поволжья

«Куян күчтәнәче» проектының күркәм нәтиҗәсе

Балада фәнгә, туган телгә булган мәхәббәт иң беренче чиратта укытучыдан, аның эшли белү сәләтеннән тора.

язучылыкка аеруча һәвәс як. Туфан Миңнуллин кебек атаклы драматургны, Ибраһим Гази кебек олпат әдипне биргән Кама Тамагы ягына исә үтә җитдилек, җиргә ябышып (туры мәгънәсендә) эшләү, ил-халык өчен тирән борчылу сыйфатлары хас кебек. Бу ике төбәкнең холык-сыйфаты сездә чагыламы?

– Туфан Миңнуллин Кама Тамагының якташлар җәмгыятен җитәкләде. Ул: «Мәктәпнең, көчле укытучыларның булуы күп нәрсәгә йогынты ясады, анда хәтта механизаторлар да сүгенә белми. Гади кешеләре дә мәктәп аркылы тәрбияләнеп чыга», – дип сөйли иде. Әлбәттә, Актаныш ягында һәр механизатор яки сыер савучы сәхнәгә чыга икән, матур итеп җырлаячак яки бииячәк. Аны иртәгә үк Казандагы берәр фестивальгә җибәрергә була һәм ул анда соңгы урында калачак түгел. Бер авылда концерт оештыралар икән, күрше авылдан яки хуҗалыктан яхшырак булсын, дип тырышалар.

– Без дә заманында гармуннар белән Байсарга йөри идек. Смотр конкурслары, халык театрлары гөрләп тора иде.

– Актаныштаспектакльне шулкадәр яхшы сәхнәләштерәләр иде, әйтерсең, уйнаучыны махсус курста укыган артист диярсең, ә үзе гап-гади тракторчы яки сыер савучы. Мәдәни, рухи тормыш белән җитәкчеләрнең барысы да диярлек кызыксына иде...

– Газинур Фарукшин – заманында шофёр булып, җырлап, Мөхәммәт Мәһдиевне шаккатырган шәхес.

– Агыйдел турында бик күп җырлар бар. Баксаң, Агыйдел Татарстанның Актаныш районында гына ага. Ни өчен Актаныштагына аккан Агыйдел турында җырлар шулкадәр күп? Җырларның авторлары да безнең композитор һәм шагыйрьләребез. Актаныш талантлы төбәк булганга, иҗат әһелләре дә күп килә иде. Сара Садыйкова, Мостафа Ногман кебек шәхесләребез атналар буе Актаныш авылларында, Агыйдел буйларында иҗат итте, җитәкчеләр дә аларга хәерхаһлы иде.

– «Беренче мәхәббәт» җыры да Актаныш төбәге белән бәйле: Әхмәт Рәшит сүзләре, Сара апа Садыйкова көе.

Илдар әфәнде, Сез гомер буе яшьләр арасында кайнаган, алар язмышын кай-

гыртып яшәгән кеше. Киләчәк яшьләрен – милләтебезварисларын, аларның язмышын, тормышын, көн-күрмешләрен сез ничек күзаллыйсыз?

– Татарстандагы хәзерге яшьләр оешмалары безнең катнашта барлыкка килде. «Сәләт», Студентлар лигасы, КВН хәрәкәте һәм башка патриотик юнәлештәге берләшмәләр, шөкер, бүген дә эшләп килә. «Идел» яшьләр үзәгендә читтә яшәүче татарлар белән зур эшләр башкарыла, чаралар шактый оештырыла. Күптән түгел генә татар яшьләре көннәре тәмамланды, хәзер исә 180 балалык «Туган тел» лагеры үз эшен башлап җибәрәчәк. Әлбәттә, Татарстаннан читтә туган телне саклау кыен. Милли мәктәп тә юк, татар теле укытылмый, укытучылар җитми. Дистә ел элек ата-аналар үз балалары белән татарча сөйләшкән икән, хәзер исә әби-бабай гына сөйләшә. Тора-бара әби-бабай да сөйләшмәячәк.

Элегрәк без «Туган тел» лагерьларына балаларны җыя алмый идек, хәзер исә конкурс. Беренчедән, лагерьның урыны әйбәт, безнең программабыз кызык, тулы. Икенчедән, бала татар телен бөтенләй белмәгән очракта да, өйрәнергә теләк белдертәбез, туган җиренә кайтканнан соң ул үзе кызыксына башлый.

Мин хәзер дә яшьләр оешмалары советы рәисе булып торам. Бөтен яшьләр оешмаларының эшчәнлеген координацияләп, аларга ярдәм итәбез. Яшьләрнең торак шартларын яхшырту программасына да яңа җан бирергә торабыз.

– Татар иле – безнең мирас, дибез. Мирасны барлауда, аны халыкка кайтаруда сез җитәкләгән Татар федераль милли-мәдәни автономия дә зур эшләр башкара дип беләм. Эшчәнлегегезгә беркадәр нәтиҗә-бәя биреп үтсәгез иде.

– Татар федераль милли-мәдәни автономия 31 региональ милли-мәдәни автономияне, 3 җирле мәдәни автономияне берләштерә. Якын арада тагын берничә регион үзенең канунлаштырган татар оешмасын булдырачак. Җирле милли-мәдәни автономияләр турындагы федераль канунның булуы безгә урыннарда шушы оешмаларга дәүләт тарафыннан игътибарны һәм ярдәмне күбрәк бирергә ярдәм итә. Автономияләр махсус прогрмма, укыту-методик әсбаплары булдыру, төрле чаралар уздыру, грантларда катнашу хокукына ия. Хәтта укыту үзәкләре, мәктәпләр дә ачарга мөмкинлек бирелгән. Без бу мөмкинлекне әле үзебез дә тулысынча файдаланып бетермибез. Төбәктәге татарлар өчен әһәмиятле мәсьәләләрне закон нигезендә оешкан автономия тирәсенә берләшеп хәл итәргә кирәк. Төбәкләрдәге таркаулыгыбыз, анда берничә оешманың булуы, аларның бер-берсе белән каршылыкта яшәп, уртак фикергә килеп эшләмәве – безнең җитешсезлек иде. Төбәкләрдә дәүләт ярдәменнән башка бернәрсә эшләп булмый. Дөрес, татар оешмалары күп булсын, һәр оешмага эш җитә... Ләкин телне, мәдәниятне саклаудагы программаларны бердәм булганда гына гамәлгә ашырырга мөмкин. Мәктәпне, укыту үзәкләрен, атнасына өч тапкыр туган тел дәресләрен булдыру өчен күп тырышырга, шактый тир түгәрә кирәк. Бу бергәләп эшләгәндә генә мөмкин. Шул ук вакытта мәктәп директоры һәм укытучылар да гыйлемле, зыялы шәхесләр булырга тиеш.

Ни өчен Ульяновск өлкәсендәге Мәләкәс шәһәре ата-аналары балаларын татар мәктәбенә бирергә чират тора? Чөнки директоры, укытучылары сәләтле, анда яхшы белем һәм тәрбия бирәләр. Балалар барысы да атнага 3 сәгать татар теле һәм әдәбиятын укый. Туган телне беләләр, татарча җырлыйлар һәм бииләр, тәрбияви

Төбәктәге татарлар өчен әһәмиятле мәсьәләләрне закон нигезендә оешкан автономия тирәсенә берләшеп хәл итәргә кирәк.

чаралар татарча оештырыла. Биредә хәтта урыс балалары да белем ала. Татар мәктәпләрен бетереп, математика, физикадан бердәм дәүләт имтиханнарыннан саллы балл җыючылар бар.

Кайбер аксакал бабайларыбыз мәктәп кирәк, дип кычкырып, татар мәктәпләрен ачтыра. Әмма андый уку йортлары бер-ике ел да эшли алмый, күрсәткечләре түбән, яхшы белгечләр эшләми. Нәтиҗәдә, ата-аналар балаларын алып китә дә, киресенчә, җәмгыятьтә тискәре мөнәсәбәт кенә тудырыла. Ә татар милли мәктәбе башка уку йортларыннан берничә баскыч югары булырга, анда зыялы һәм затлы мөгаллимнәр гыйлем һәм тәрбия бирергә тиеш.

Без күп эшне Мәскәүгә сылтарга яратабыз. Бер олы әдибебез миңа ачуланып сорау бирә: «Мәктәпләрдә Татарстан тарихы дәресләрен кертмәү өчен зур эш бара. Ни эшләп сез моңа каршы гамәл кылмыйсыз, кануннарны карамыйсыз?!» Мин әйтәм: «Абзый, җирле тарих дәресләрен мәктәпләргә кертмәү турында канун юк. Мәктәп программасыннан бер сәгать тарихка яки башка фәнгә бирелә икән, аңа беркем дә каршы килә алмый. Мәктәпнең моңа кануни яктан мөмкинлеге бар». Моны ата-ана, мәктәп җитәкчеләре еллык уку программасын төзегәндә карый, мәгариф идарәсе тарафыннан раслаталар. Бары үзебездән тора, үзебез булдырмыйбыз, ә Мәскәүгә сылтап калдырабыз.

Автономиянең төп өч эш юнәлеше бар: татар телен, гореф-гадәтләрне һәм мәдәниятне саклау. Без сәяси оешма түгел, дәүләт бюджетында да утырмыйбыз. Хәйриячеләр табабыз, федераль, республика грантларында катнашабыз, хәтта үземнең акчамны да чыгарып бирәм... Төп бурычыбыз шушы өч мәсьәләне хәл итүдә төбәкләргә ярдәм кылу, аларны бер канат астына туплау, өйрәтү, яшь балалар белән төрле чаралар оештыру, аларның мәнфәгатен яклау.

Мәскәүдәге милли мәсьәләләр буенча агентлык каршындагы совет составында, Президент каршындагы милли мәсьәләләр буенча совет әгъзасы буларак та, курыкмыйча, кирәк вакытта үз сүзебезне әйтәбез. Ләкин кайвакыт: «Менә бу очракта син үз фикереңне әйтмәдең!» – дип дәгъва белдерәләр. Мин әйтәм: «Һәрбер совет саен сикереп торып сөйләү мәгънәсезлек булыр иде», – дим. Мәсәлән, патриотик тәрбия турында сөйләшкәндә, мин сикереп торып: «Туктагыз әле, менә Кырым татарларын җәберлиләр бит әле», – дип әйтү бик үк дөрес булмас иде. Аның башка вакыты, үзгә темасы бар. Кайберәүләр, син болай эшләргә тиеш идең, диләр. Мин аларга: «Егетләр, без бит җәмәгать оешмасы, мин халыкка ярдәм итәм. Әгәр дә сезнең мөмкинлегегез бар икән, үзегез фондлар оештырыгыз, рәхим итеп эшләгез. Беркем дә сезгә каршы булмаячак. Әгәр дә ярдәм итәргә теләгегез, матди мөмкинлегегез бар икән, без эшләгән чараларны тагын да камилләштерергә телисез икән, рәхим итегез, әйдәгез, бергәләп, кулга-кул тотынып эшлибез», – дим. Ә инде читтән торып акыл өйрәтүдән мәгънә юк. Без дәүләт оешмасы булсак, алар: «Мин салым түлим, минем салымны дөрес файдаланмыйсың?!» – дип, дәгъва белдерә алырлар иде. Акыллы, матур, кызыклы тәкъдимнәр бар икән, без бергә эшләргә әзер.

– *Урыс даирәсендә, башка халыклар*

арасында эш алып барган кеше буларак, Татар милләтенең, татар халкының киләчәген ничек фаразлыйсыз? Атаклы якташың Туфан Миңнуллинны гомере буе борчыган сорау: бу ыгы-зыгылы дөньяда татар һәм аның теле яшәячәкме? Әллә... көннәрдән беркөнне җир йөзеннән себерелеп бетәчәкбезме?

– Нинди мөмкинлегебез бар, шуны эшләргә тырышабыз. Татар үзәкләре дә милли тормышны саклауда зур ярдәм күрсәтә. Ульяновскида, Новосибирскида шундый үзәкләр бар, Йошкар-Олада да оешып килә. Татарлар күпләп яшәгән һәр төбәктә шундый үзәк ачылып, анда милли тормыш ел әйләнәсендә кайнап торырга тиеш. Телне саклау юнәлешендә яңа методикалар, проектлар, кызыклы мультфильмнар булдырырга кирәк. Мин хәтта «Дисней» мультфильмнарын татарчага тәрҗемә итеп булмасмы икән, дип йөрдем. Әмма аларның Россия территориясендә фәкать урыс телендә генә булырга тиеш, дигән килешүләре бар.

Республикабыз эчендә дә телне саклау буенча зур проблемалар бар. Методиканы үзгәртергә, телне өйрәнүне балалар бакчаларына күчерергә, яхшы укытучыларны, тәрбиячеләрне әзерләргә кирәк. Шәхси балалар бакчаларына да ихтыяҗ зур. Революциягә кадәр татар байлары акчасын мәгарифкә, мәктәп-мәдрәсәгә биргән. Аннан зур галимнәр чыккан. Кызганыч, хәзерге байлардан җыр-бию, күңел ачудан кала, тел, мәгарифне саклау өчен бер тиен акча да алу авыр. Яһүдләр мәктәбенә эләгер өчен чират. Ә ни өчен әле безнең татар байлары шундый балалар бакчасы, мәктәпләр ачмаска тиеш? Ачыла калса, шәхси булуга карамастан, дәүләт үзе дә аларга ярдәм итә. Хезмәт хакы, методик әсбап, дәреслекләрне бирә. Байларыбыз җыен юк-бар белән шөгыльләнгәнче, мәгарифкә, телгә йөз белән борылса, күркәм гамәл кылыр иде. Бу аларның бизнесына да яхшы реклама һәм пиар булачак. Ә җыр, бию, Сабан туе – алары да кирәк. Укытучы, методика, акыллы байларыбыз була икән, милләтебез сакланачак. ■

ХӘМИТ ЗӨБӘЕР КОШАЙ

(1897-1984)

Фәридә Гаффарова*

Милләттәшләребез арасында төрек халкының мәгарифен, мәдәниятен дөньякүләм фәнни аренага чыгарырдай зур ачышлар ясаган һәм шуның белән Төркия мәдәнияты тарихында тирән эз калдырган олы галимнәр бар. Шуларның берсе – үзенең фәнни хезмәтләре, археология өлкәсендәге ачышлары белән дөньякүләм танылу алган Хәмит Зөбәер Кошай.

Ул балачактан ук Төркиядә яшәгән, шунда укыган, үскән һәм аның милли аңы да, башка эмигрант милләттәшләребездән аермалы буларак, төрекчелек рухында формалашкан. Ләкин озак еллар буе С.Максуди, Й.Акчура, З.Вәлиди, Г.Исхакый кебек милләтпәрвәрләр белән якыннан аралашып яшәгән, эшләгән Хәмит Зөбәер татар әдәбияты, тарихы, мәдәнияты белән дә тирәнтен кызыксынган, белгән. Аның «Казан», «Төрек культур араштырмалары» һәм башка журналларда чыккан күп санлы мәкаләләре шуны раслыйлар.

Габделхәмит Зөбәер 1897 елда Минзәлә өязе Теләнче Тамак авылында туган. Башта ул атасының туганы – шул яклардагы мәшһүр Габделҗәббар хәзрәт мәдрәсәсендә укый. Аның анасының сеңлесе Ризаэддин Фәхреддиндә кияүдә була. Атасы, укуын дәвам итәр өчен, Хәмитне Бохара мәдрәсәсендә укучы абыйсы янына җибәрергә теләсә дә, 9 яшьлек Хәмит Р.Фәхреддин булышлыгы белән Истанбулга укырга җибәрелә һәм ул Галатасарайда урнаша.

Х.Зөбәер 1912 елда укуын уңышлы тәмамлап, лицей сыйныфына укырга керә. Балкан сугышы башлану сәбәпле укулар тукталып тора һәм Хәмит яралы сугышчыларны дәвалый торган госпитальдә хезмәт итә. 1914 елдан инде ул Салоникадагы Мидхәт паша мәктәбендә укый башлый. Бераздан ул югары белемне Венгриядә алмакчы булып, Австрия консуллыгына мөрәҗәгать итә, тик китмичә кала. Истанбулда ике ел укыганнан соң ул мөгаллимлек дипломы ала һәм Кадикөй

*Фәридә Гаффарова (1951-2006) – тарих фәннәре кандидаты.

Төрек Теле Эзләнүләр Җәмгыяте (1932 елның 12 июлендә Ататөрек тарафыннан оештырыла, хәзер – Төрек теле җәмгыяте) Үзәк идарә шурасының Ататөрек җитәкчелегендә узган җыелышта (сулдан уңга): Хәсән Али Йүҗәл, Җәлал Сахир Эрозан, Әхмәт Җәват Әмрә, Рәшит Галип, Мостафа Кемал Ататөрек (иң уртада), Афәт Инан, Рушән Әшраф Үнайдын, Ибраһим Нәҗми Дилмән, Хәмит Зөбәер Кошай. 4 гыйнвар, 1933 ел

бистәсендә мәктәптә физкультура укытучысы булып эшли башлый.

Ниһаять, Х.Зөбәер үз теләгенә ирешә – 1917 елда ул Венгриягә китә, Будапештта университет тәмамлый һәм 1925 елда, инде докторлык дәрәҗәсе алып, Төркиягә кайта. Истанбул университетларының берәрсендә укытырга теләсә дә, урын булмау сәбәпле, анда эшкә урнаша алмый. Шул ук елны Х.Зөбәер – мәгариф министрлыгы карамагындагы китапханәләр буенча инспектор булып эшли башлый һәм 3 айдан соң инде ул Харс, Ашари атика китапханәләренең бүлек мөдире була, ә бераздан соң музейлар департаменты мөдире итеп күчерелә. Х.Зөбәер – Әнкара этнография музеена нигез салучы галим, бераз вакыт аның мөдире дә булып тора. Соңрак ул Борынгы кулъязмалар музееның һәм Төркиядәге барлык музейларның генераль директоры була һәм шул урында 1929 елдан 1949 елга кадәр эшли. Аннары ул Әнкара этнография музеена директор итеп куела һәм шунда 1962 елга кадәр эшләп, пенсиягә чыга. 1964-69 елларда Х.Зөбәер иске язмалар һәм музейлар генераль департаментлыгында инспектор булып эшли һәм 1969 елда инде бөтенләйгә пенсиягә китә.

Филология фәннәре докторы Хәмит Зөбәер, 30нчы еллар башында фамилияләр турында закон чыкканнан соң, үзенә фамилия итеп Манас дастанында телгә алынган, төньяк төрекләреннән булган Кошай исемен ала һәм Хәмит Зөбәер Кошай була.

Ул инглизчә, алманча, мадъярча яхшы белгән һәм шул телләрдә дөньяның күп илләрендә уздырылган төрле фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясаган. Доктор Хәмит Зөбәер Кошай археология, этнография һәм фольклор буенча дөньякүләм танылган белгечләрдән саналган. 1935 елда Алажахоюндагы археологик казу эшләрен яңача методлар белән алып бара һәм шунда ясаган яңа ачышлары белән ул археолог буларак дөньякүләм танылу ала.Үзенең археологик ачышлары, табышлары белән ул Төркия тарихына гына яңалык кертеп калмый, дөнья археология һәм тарих фәненә дә үзгәрешләр кертә. Ул Венгрия, Польша, Эстония, Финляндия, Германия, Америка, Англия, Франция, Швеция, Швейцария, Югославия, Болгария, Ру-

мыния, Ливан һәм Мисырда уздырылган төрле халыкара конференцияләрдә, конгрессларда катнаша, үзенең ачышлары турында чыгышлар ясый. Аның чыгышлары, ясаган докладлары исә борынгы Госманлы дәүләтен, Грецияне өйрәнү өчен чит ил галимнәренә беренчел чыганак булып тора.

Х.Зөбәер Кошай тирән белемле археолог, этнограф галим булу өстенә искиткеч оештыру сәләтенә дә ия булган. Ул – төрек Тарих җәмгыятен оештыручыларның берсе. Шулай ук ул Истанбулдагы Ая Суфия мәчетен музей итеп оештыруга да зур көч куйган галим.

Мәдәниятләр бишеге булган Анатолиягә казу эшләре алып бару өчен килгән күп санлы чит ил галимнәре – археологлар, антропологлар, этнографлар, тюркологлар, сәнгатьчеләр, казу эшләрен алып баручы төркемнәр, тикшеренүчеләр ярдәм һәм киңәш сорап гел аңа мөрәҗәгать иткәннәр. Ул аларга Төркиядә казу эшләре алып бару өчен һәртөрле ярдәм күрсәтеп килгән, торабара бу профессиональ хезмәттәшлек дуслыкка әверелгән. Ә алар, үз чиратларында, фәнни тикшеренүләренең нәтиҗәсе булган китапларын галимгә бүләк итеп җибәргәннәр. Әлеге хезмәтләрнең барысының да кереш сүзе исә доктор Хәмит Зөбәер Кошайга фәнни тикшеренүләр, ягъни казу эшләре алып баруда кылган ярдәме һәм киңәшләре өчен рәхмәт хисләрен җиткерүдән башлана. Шулай итеп, Германия, Англия, Италия, Венгрия галимнәре аның археология өлкәсендә зур белгеч булуын таныйлар. Еллар узгач, Х.З.Кошайның дөньяның бик күп танылган галимнәренең автографлы китапларыннан, фундаменталь хезмәтләреннән, гомере буе җыйган иске кулъязмалардан, иске китаплардан торган гаҗәеп бай китапханәсе барлыкка килгән һәм аның китапханәсе Төркиядә иң бай шәхси китапханәләрдән саналган. Дөнья галимнәре һәм аларның эшләре, фикерләре белән танышу аның үзенә дә тарих, этнография, халык авыз иҗаты, археология өлкәсендә дөньякүләм танылган белгеч булып формалашуга ярдәм иткән.

Х.Зөбәер Кошай, төрек халкына аның мәдәниятен, фәнен үстерүгә хезмәт итсә дә, үзенең татар милләтеннән булганын беркайчан да онытмаган. Ул гомере буенча «Төрек юрду» журналында татар халкының әдәбиятына, тарихына, этнографиясенә багышланган мәкаләләрен бастырып барган. Шулар арсында аның 1954 елның апрель, 1957 елның май саннарында үзе аралашып яшәгән, хөрмәт иткән Закир Кадыйри һәм Сания Гыйффәтләргә багышланган некролог-мәкаләләре чыккан. 1977 елда «Тарих корумы» бюллетенендә (ЬХ1-162, 365 – 4006) «Йосыф Акчура» дигән мәкаләсе басылган. Г.Исхакый чыгарган «Яңа милли юл» журналында да, 50 нче елларда чыккан «Азат ватан» журналында да, татар эшкуары Ә.Мәңгәр ярдәме белән 70 нче елларда 10 ел дәвамында чыгып барган «Казан» журналында да бу танылган галимнең татар әдәбиятына, аның күренекле вәкилләренә багышланган һәм татар халкы тарихына караган мәкаләләре еш басылган. Кыскасы, Х.Зөбәер, балачагында ук туган җиреннән аерылса да, ата-анасы биргән тәрбия, мәшһүр Ризаэтдин Фәхреддин белән аралашу, ул биргән киңәшнәсихәтләр аның күңеленә гомере буена җитәрлек итеп салынган булган, күрәсең. Шунлыктандыр да инде, үзен гомере буе Төрек мәгарифен, мәдәниятен, фәнен үстерүгә, аны дөньяга танытуга хезмәткә багышлаган Х.Зөбәер Кошай, барыбер, татар халкы язмышы, аның киләчәге өчен борчылып яшәгән. Төркиягә күчеп килгән беренче дулкынның балаларын, оныкларын төрекләшүдән саклау максатыннан чыгып ул аларга үзләренең ата-бабаларының туган җирләре, туган илләре турында сөйләү, аңлату өчен һәр

мөмкинлектән файдаланырга тырышкан.

Хәмит Зөбәер Кошай Төркиядә татар эмигрантларын бергә туплап, оештырып яшәүче С.Максуди, Ә.Тимер Г.Баттал, К.Локман, Н.Арсланбәк, С.Чыгтай һәм башкалар белән аралашкан. Әлеге шәхесләр белән аны «Казан» журналын чыгаруга багышланган хезмәттәшлек якынлаштырган.

Галим, шулай ук, Г.Исхакый, Г.Баттал, С.Максудиларны искә алу конференцияләрендә дә аларның эшчәнлекләренә төпле анализ биргән чыгышлар ясаган. Мәсәлән, С.Максуди үлеменең 20 еллыгына багышланган фәнни конференциядә (1977 ел) ул С.Максудиның сәяси, фәнни эшчәнлегенә югары бәя биреп, аның фикерләре белән эшчәнлеге туры килгән, ягъни ул үзе ышанган һәм шул вакытта үзе реаль санаган фикерләренә таянып эш иткән, дигән. 1919 елда Франциягә Версаль конференциясенә килгән С.Максуди берара сәясәт белән шөгыльләнгән. Әмма бераздан Совет властенең Россиядә ныгуын, илдәге оппозициянең көчсезлеген, милли хәрәкәтнең таркалуын һәм юкка чыгуын күргән С.Максуди милли эшләрне яңача башлау кирәклеген аңлаган. Ә моның өчен, Х.Зөбәер Кошай фикеренчә, милли көрәш юлларын ачыкларга, төрки дөнья белән мәдәни бердәмлеккә ирешү өчен бердәм концепция төзергә, ә моңа бары тик киләчәк буыннарны фәнни хезмәтләр аша хәзерләп кенә ирешеп булачак, дигән нәтиҗәгә килгән һәм С.Максуди 1925 елдан фәнгә кереп киткән. Ул Германия, Франция китапханәләрендә төрки халыклар тарихын өйрәнгән, Сорбоннада төрки халыклар тарихы кафедрасы профессоры булган һәм һәм шул фән буенча лекцияләр курсы алып барган. Фикердәшләре Г.Исхакый, Ф.Туктаровлар башта аны сәясәттән читләшә, дип гаепләсәләр дә, соңыннан аның гыйльми эшчәнлегенә зур бәя биргәннәр.

Х.Зөбәер Кошай С.Максудиның үлеменең бер еллыгына багышланган конференциядә укыган «С.Максудиның хезмәтләре һәм милләт аңлатмасы» дигән докладында аның «Милләт тойгысының социологик әсаслары» исемле хезмәтенә тирән анализ ясый. Аның бу чыгышы – олуг милләтпәрвәрнең – С.Максудиның соңгы хезмәтенә бирелгән беренче олы бәя була.

Хәмит Зөбәер Кошай 1984 елда 87 яшендә вафат була.

Төркиядә төрек халкының мәдәниятендә тирән эз калдырган бу олы галимне зурлап искә алалар. Аның хезмәтләре бүген дә дөнья археологиясе тарихында дәреслек һәм беренчел чыганак булып хезмәт итәләр, алар югары уку йортларында тарих, этнография, археология факультетларының уку программаларына кертелгәннәр.

1985 елда Истанбулда үлеменең бер еллыгы уңае белән Х.Зөбәер Кошайны искә алу конференциясе уздырыла һәм конференция материаллары буенча «Төрек культур араштырмалары» журналы үзенең бер санын (1986 ел, февраль) аңа багышлап чыгара. Журналда төрек галимнәренең, Европаның танылган археологларының аның фән өлкәсендәге хезмәтләренә олы бәя биргән һәм дөнья фәнендәге урынын билгеләгән мәкаләләре басылган, дөньякүләм танылган галимнәрнең төрле елларда аңа язган хатлары урнаштырылган.

Шулай итеп, XX гасыр башында Р.Фәхреддин тарафыннан Төркиягә белем алырга дип җибәрелгән 9 яшьлек Хәмит Зөбәер Кошай гомере буена төрек халкына хезмәт итеп һәм үзенең хезмәтләре белән Төркия мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган, археологик ачышлары белән дөнья археологиясе фәненә үзгәрешләр керткән мәшһүр галимгә әйләнә. ■

МИЛЛӘТНЕ КАЙГЫРТУЧЫ БАСМА

Әгъзам Фәйзрахманов

Вакыт тиз үтә. «Безнең мирас» журналы (мин биредә «Мирас» һәм «Чын мирас» исеме белән дөнья күргәннәрен дә күз уңында тотам) чыга башлауга да 25 ел вакыт үтеп киткән икән инде. Әле кайчан гына журналның беренче саннарын укып, бик шатланган идек. Узган гасырның туксанынчы еллары башында, Татарстан үз дәүләтчелеген төзү өчен кискен көрәш алып барган көннәрдә оешкан һәм халкыбызның узаңы уянуының, үсүенең матур мисалы буларак, көтмәгәндә-уйламаганда калкып чыккан журнал тиз арада киң җәмагатьчелеккә танылып өлгерде.

Ул ныклы традицияләре, инде калыпланган юнәлешләре, тотрыклы коллективлары булган дистәләрчә газета-журналлар арасында үз урынын тапты, юнәлешләрен булдырып, кыйбласын танытып кына калмады, бәлки кабатланмас йөзе, үзенчәлекле көрәшче булуы белән дә үзен өлкән кардәшләре арасында уңай яктан күрсәтеп өлгерде. Дөрес, журнал эшчәнлегенең беренче чорында аерым материалларга, тарихыбызның кайбер вакыйгаларына бәя бирүгә карата төрле фикерләр яңгырады, тәнкыйть сүзләре дә әйтелде. Хәер, бу шулай булырга тиештер дә инде. Бар кеше дә бер үк төрле уйлый алмый бит, фикер каршылыклары булу – табигый хәл.

Шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр, журнал милли

мәдәниятнең чын патриотлары булган кайбер галимнәр һәм зыялы эшмәкәрләр белән эре сәнәгать җитәкчеләренең уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә туды. Соңрак, дәүләт органнарында эшләүче кайбер зыялыларның ярдәме белән хөкүмәт канаты астына кергәч, аның сулышы тагын да киңәеп китте.

Әлбәттә, дөнья бер урында гына тормый, даими үзгәрештә ул. Хакимияткә дә яңа кешеләр килә. Билгеле, аларның матбугатка да үз карашы бар. Журналның исеме дә үзгәрде. Башта ул «Мирас» дип чыкса, аннары «Чын мирас»ка әйләнде. Хәзер исә «Безнең мирас» исеме белән дөнья күрә. Минемчә, бу исемнәрнең берсе дә начар түгел. Шулай да «Безнең мирас» журналның юнәлешен төгәлрәк аңлата кебек. Укучыларда гаҗәпсенү дә уятмый, төрле сораулар да тудырмый. Хәтерлим әле, журнал «Чын мирас» исеме белән чыкканда, бу басманың даими хәбәрчесе буларак, кайберәүләр миннән: «Мирасның ялганы да буламыни?» – дип сорый иде. Гадәттә, андый вакытта: «Һәр нәрсәнең чыны да, ялганы да буладыр инде ул», – дип җаваплый идем. Бәлки, хаклы да булмаганмындыр.

Әмма журнал шушы чирек гасыр дәвамында халыкка, милләтебезгә хезмәт итте. Юк, ул бервакытта да татар милләтен башкалардан өстен куярга тырышмады, татар халкының бүтән милләтләр, шул исәптән руслар белән дә, тигез хокуклы булуы өчен көрәште. Бу максат бүген дә үзгәрмәде.

Моңарчы архивларда тузан җыеп яткан тарихи-мәдәни, гыйльми мирас җәүһәрләрен халкыбызга кире кайтарып, журнал аларны фәнни әйләнешкә кертә. Дөньяның иң танылган ундүрт теленең берсендә сөйләшүче уңган халкыбызның бай мәдәни хәзинәсе яңа байлыклар хисабына тагын да ишәя бара. Шул ук ва-



Ф.Мусин һәм Х.Җәләй. 1992 ел, 30 сентябрь.
Зөфәр Бәширов фотосы

кытта «Безнең мирас» гуманитар фәннәр тармакларының барысы белән дә актив һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек итүче гыйльми журнал да әле. «Безнең мирас» фәнни-популяр басма булудан тыш, әдәби-нәфис журнал вазифаларын да үти. Республикабызның иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләр һәм матур әдәбият әсәрләре дә аның битләрендә даими рәвештә басылып килә.

Бу мәкаләне әзерләгәндә журналның төрле елларда чыккан саннарын актарып утырдым. Авторлар составы үзгәрә төшсә дә, ул һаман да төп игътибарын халыкка хезмәт итүгә юнәлтә. Татар халкының милли азатлык хәрәкәтенә, аның лидерларына багышланган сәхифәләр дә еш очрый. Минем үземә дә журнал өчен алар турында берничә язма әзерләргә туры килде. Хәтерлим әле, 1996 елның урталарында Марат Мөлеков «Мирас» журналы өчен Татар иҗтимагый үзәге эшчәнлеге турында мәкалә әзерләвемне сорады. Милли хәрәкәттә бик актив катнашмасам да, ризалаштым. 1996 елның 12 нче санында «Татар халкының милли азатлык хәрәкәте» дигән рубрика астында «Яшәү мәгънәсе» исемле язмам басылып та чыкты.

Мәкаләнең башында шундый юллар бар иде: «*Татарның милли хәрәкәте барлыкка килүгә шактый озакка сузылган торгынлык елларыннан соң, үзгәртеп кору, демократия җилләре исә башлау этәргеч бирде.Ник дигәндә, үз фикереңне курыкмыйча әйтергә, кайбер планнарыңны гамәлгә ашыруга мөмкинлек туды. Шунлыктан, Татар иҗтимагый үзәгенең формалашуы да табигый күренеш. Татар теле, мәдәнияте, гореф-гадәтләребез югалу дәрәҗәсенә җиткән иде. Халкыбызның язмышы бик күпләрне борчыды. Татарның тарихына игътибар итсәң, ул һәрвакыт бәйсезлек өчен көрәшкән. Крестьян восстаниеләрен, революцияләрне искә төшерегез. Аларда татар сан ягыннан да, активлык ягыннан да башкалардан ким булмады. Бөек Ватан сугышы башлангач, татар халкы туган илен саклау өчен немец-фашистларга каршы бердәм күтәрелде. Батырлыгы, тәвәккәллеге, чыдамлыгы белән аерылып торды. Нинди генә авыр хәлләргә калса да, татар һәрвакыт ирекккә омтылды*».

Үзәкне оештыручыларның берсе, аның беренче президенты Марат Мөлеков Татар иҗтимагый үзәге оешкан чорны болай тасвирлый: «*Үзгәртеп кору дигән сүзләр ишетелә башлагач, халык батырая төште. Мин ул вакытта Казан дәүләт университетында укыта идем. Студентлар, аспирантлар, элекке укучыларым еш кына минем янга килеп киңәшә башлады. Тик кенә утырмаска, нәрсә дә булса эшләргә кирәклеген искәрттеләр. Шәхсән үзем Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына барып, андагы галимнәр белән фикерләштем. Бу институтта минем дусларым күп. Кичекмәстән зыялыларны җыярга, мәсьәләне уртага салып, ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк, дигән карарга килдек. Һәм шулай эшләнде дә*».

Татарстанның вице-президенты В.Лихачев «Мирас» бәйрәмендә. 1992 ел, 30 сентябрь.
Зөфәр Бәширов фотосы

Милләт өчен янып-көеп йөрүче зыялыларыбыз зур тырышлык куйса да, ТИҮне оештыру, эшчәнлеген җайга салу авыр булды. Оешкан чорда Татар иҗтимагый үзәге лидерларына КПСС өлкә комитеты, хәтта Үзәк комитет та тынгы бирмәде. Һәр адымнарын күзәтеп тордылар. Марат Мөлековның әйтүенә караганда, аны көнаралаш үзләренә чакыртканнар. КПСС Үзәк комитетының дәүләт-хокук бүлеге мөдире Я.А.Михайлов, Үзәк комитет инструкторы А.Ф.Садовников һәм башка түрәләр Татарстанны автономияле республикадан союздаш дәрәҗәсенә күтәрергә иртә әле, вакыт җитмәгән, дип тынычландырырга тырышкан. Куркытып та караганнар. Шулай да М.Мөлеков түзгән, сайлаган юлыннан тайпылмаган. «Мирас»та басылган мәкаләне дә Марат бик ошаткан иде. Мәкалә дөнья күрүгә, ул минем янга кереп, рәхмәтләрен әйтеп чыкты. Озаклап сөйләшеп, чәй эчеп утырдык.

Журнал тарихы турында уйлаганда аның даими үсештә, хәрәкәттә булганда гына фәнни фикернең алга китәчәген яхшы аңлап, төрле карашлар, концепцияләр, бәхәсләр чагылган үзенчәлекле хезмәтләргә дә даими урын бирүенә төшенәсең. Журнал инде кайбер формалашкан фәнни концепцияләрнең ныклыгын бәхәс тудыру аша сынап карауны да мәгъкульКүрә. Шул сәбәпле, аның битләрендә республикабыздагы төрле иҗтимагый-сәяси фикерләрнең чагылуы да бик табигый.

Халкыбызның кабатланмас шәхесләре турында язмалар һәр санда диярлек урын ала. Андый материаллар кызыксынып укыла. Күренекле шәхесләр турында мин үзем дә журналдаберничә очерк бастырдым. «Хакыйкать юлында» дип исемләнгән очерк республика халкына яхшы таныш шәхес Фәүзия Бәйрәмова турында иде («Мирас», 2001 ел, 4 нче сан). Җөмһүриятебез суве-

ренлыгына, дәүләтчелегебезне торгызуга багышланган җыелыш-митингларда, төрле дәрәҗәдәге корылтайларда Фәүзия даими чыгыш ясый. Татарстан халык депутаты вазифаларын башкарганда, мөгаен, ул бер генә сессиядә дә чыгыш ясамый калмагандыр. Аларның күпчелеге үзен татар дип санаган кешеләр күңеленә барып җитеп, нерв җепселләреннән дә нечкә кылларын тибрәндереп узгандыр, дип уйлыйм.

Ф.Бәйрәмова фикерен халыкка җиткерү өчен матбугат чараларыннан, шул исәптән, «Мирас» журналыннан да мөмкин кадәр киңрәк файдаланырга тырыша. Җитәкчеләргә охшау-охшамавын бик үк уйлап тормыйча, фикерен бизәкле кәгазьләргә төрмичә, кистереп, ачыктан-ачык бәреп әйтә. Матбугат та Фәүзиягә бик игътибарлы. Аның чыгышларыннан өземтәләр төрле газета-журнал битләренә килеп эләгә, аларга «аңлатмалар» бирелә. Татарлар гына түгел, республикада яшәүче төрле милләт вәкилләре Бәйрәмованың һәр адымын күзәтеп торырга, әйткән сүзләренә үз бизмәннәреннән чыгып бәя бирергә күнегеп китте. Ләкин бизмәннәр кешенең акылына, фикер сөрешенә, әхлакый сыйфатларына, теоретик әзерлегенә карап төрлечә була икән шул. Мөгаен, шуңадыр, Фәүзия ханымга карата фикерләр дә бик каршылыклы. Берәүләр аны күкләргә чөеп мактый, үзләренә мәгълүм булган барлык эпитетларны барлык тулылыгы белән куллана. Милли хәрәкәт лидерларының берсе Бөтендөнья татарларының корылтаенда ясаган чыгышында хәтта: «Фәүзия – татар

Ирек мәйданында. Тальянда Р.Вәлиев, әләм белән М.Тукаев. 1991 ел

Ирек мәйданында. 1991 ел

халкының Жанна д'Аркы» дип тә ычкындырды. Шовинистлар исә, ялын, шәхси тормышын онытып, татар дип җан атып йөргән Фәүзия Бәйрәмованы милли низаг тудыруга омтылышта гаепли. Хакимият башында утыручылар аны өнәп бетермәүләрен һәрвакыт сиздереп тора.

«Безнең мирас» шәхесләргә объектив бәя бирергә тырыша. Мин моны беренче чиратта редакция коллективының таләпчәнлегеннән һәм авторлар составының яхшы әзерлекле булуыннан, дип саныйм. Быелның алтынчы санында галимнәрдән Әзһәр Мөхәммәдиев, Хатыйп Миңнегулов, Әнвәр Шәрипов, Тәэминә Биктимерова, Әнвәр Әхсәнов, Ләлә Мортазина, Җәвад Алмаз кебек галимнәрнең язмалары, Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб) поэмасы, З. Ишаев хикәясе, язучы Рашат Низами мәкаләсе һәм күп кенә башка материаллар урын алган.

Журналның тематикасын ачыклау өчен шушы ук сандагы рубрикаларга игътибар итик: «Дөньяда сүзем калыр», «Тарихи мирас», «Татар гаме», «Педагогик мирас», «Дини мирас», «Әдәби мирас», «Сәнгати мирас», «Очты дөнья читлегеннән», «Хәтер сандыгы», «Тел күрке – сүз», «100 ел элек», «Шаян мирас». Күрәсез, рубрикалар төрле тармакларга кагыла. «Безнең мирас» язмыш ихтыяры белән җир шарының төрле почмакларына сибелеп яшәргә мәҗбүр ителгән милләттәшләребезне туплау буенча да нәтиҗәле эш алып бара. Аларның язмышына, тормышкөнкүрешенә багышланган язмалар, әдәби әсәрләр даими рәвештә дөнья күреп килә.

25 яшьлеген билгеләп үтүче журнал, башын горур тотып, бер гасырга якын тарихы булган басмалар белән тигез сафта атлый, киләчәккә зур өмет һәм ышаныч белән карый. ■

М.Мөлеков, М. Госманов һәм Ф.Сафиуллин. 1992 ел, 30 сентябрь.
Зөфәр Бәширов фотосы

МИРАСЫБЫЗНЫҢ КОЛАЧЫ КИҢ

Миркасыйм Госманов

«Мирас» журналының чыга башлавы иске хакыйкатьне тагын бер кат раслады: үзең турында үзең уйламасаң, синең хакта бүтәннәр кайгыртмый икән. Күз алдында таркалып һәм таралып баручы СССРдагы халыкларның (әлбәттә, җөмләдән татарларның да) үз мәдәни һәм рухи язмышларын «кызылавыз» большевикларга «ышанып тапшырулары» тирән ялгышу нәтиҗәсе икәнлеге хәзер тулысынча расланды. Урыс халкы, урыс теле, «бөек урыс цивилизациясе» исеменнән лаф орган, урыслаштыру юлы белән барлык халыкларга «бәхет өләшү»не идеал иткән большевиклар колониаль хәлдәге «вак» халыкларның гына түгел, хәтта урысларның үзләрен дә мәдәни, рухи һәм, иң мөһиме, әдәп-әхлак, гадел фикер йөртү ягыннан төбе ямалуы мөмкин түгел «ярык-тагарак» янына «утырткан» булып чыкты. (Үз миссиясен башкалар өстеннән хөкем йөртүдә, аларга өлеш-сәдака бүлеп утыруда күргән халыкны бәхетлеләрдән санап булмый...)

Шуңа күрә без, әгәр үз милли мәдәниятебезне, үз телебезне, рухи мирасыбызны саклап калырга, аларны савыктырырга, яңадан җанландырырга телибез икән, ул чакта без кемнеңдер вәгъдәләренә, бигрәк тә рәсми оешмаларның, шунда туенып ятучы чинауник-түрәләрнең тәмле телләренә ышанмыйча, барысын да үз кулыбызга алырга, ихтыяҗларыбыз хакында үзебез кайгыртырга тиешбез.

Тормышның табигый процессында тудырылган милли мәдәниятләр, рухи байлыклар бары аларны барлыкка китергән халыклар карамагында гына гомерле була. Шуңа күрә мин иң зур теләк итеп, нияте белән рәсми булмаган «Мирас» фонды каршында чыга башлаган «Мирас» журналына гайре рәсмилек статусын саклау бурычын атар идем. Халык үзе күпкатлы, «эчле-тышлы» булган шикелле, аның рухи дөньясы, мәдәнияте, мирасы да гаять катлаулы, әллә ничә тышлы, кат-кат астарлы. Мондый бай хәзинәне бары чын төрлелек, бары хакыйкый плюрализм гына иңли ала. Ә рәсмилек исә, аяныч тарихыбыз артыгы белән

раслаганча, бары бер-ике юнәлешне генә чынбарлыкның тар сыйнфыйлык, максатчан идеялек ише «өлешләрен» генә үзенә сыйдыра һәм күтәрә ала. Рәсмилек ул табигате белән шундый язмышка «хөкем ителгән».

Шул ук вакытта «Гайре-рәсмилек» дигән шигар-лозунг астында яңа журнал аерым бер төркемнәрнең монополиясенә әверелүдән сак булырга тиеш. Тар төркемчелек (фирка-партия ише тар оешканлык) ул да асылда рәсмилек медаленең икенче ягы булудан ары китми. Шуңа күрә, мин «Мирас»ның туып килүче Фәннәр академиясе, университет, педагогик һәм башка институтлар хезмәткәрләренең, шулай ук киң җәмәгатьчелекнең актив катнашында чыга торган үзенчә бер мөстәкыйль, димәк, киң колачлы, хөр фикерле журнал булуын теләр идем. Бары шулай булганда гына ул үзенә озын гомер һәм бай эчтәлек тәэмин итәчәк. Киресенчә булганда, ул бик тиз тараячак, саегачак һәм пыскып сүнәчәк... фикердә, анда хөрлек булмыйча торып, сәясәттә ирекләккә, икътисадта мөстәкыйльлеккә ирешеп булмый.

Журналның төп эчтәлеген, әлбәттә, иң элек язма мирасыбыз истәлекләре алырга тиеш. Бу – бәхәссез. Шулай ук анда «Халык иҗаты ядкарьләре» дигән бүлекнең булуы да акланган. Күптомлы «Татар халык авыз иҗаты» сериясенә кермәгән фольклор әсәрләре дә анда киңрәк урын алсын иде. Моңарчы төп версияләре билгеле булган җырбәетләр, әкият-риваятьләр һ.б. халык авыз иҗаты әсәрләренең вариантлары басылу да мирасыбызның колачын ачыклауга хезмәт итәр иде.

Әлбәттә, мадди мәдәниятебез, бигрәк тә нәфис һәм гамәли сәнгатебез истәлекләрен барлау, теркәү, гыйльми тасвирлау һәм пропагандалауны да төп бурыч иткән махсус бүлекне дә даими күрәсе килә.

Материал җыелуга карап, чит илләрдә яшәгән һәм яшәүче кардәшләребез хакында да фактик материалларны бирә бару журналның гуманистик юнәлешен көчәйтергә хезмәт итәр иде.

Шулай ук «Мирас» журналында «Фактлар һәм шәхесләр» дигән махсус бүлек ачылсын иде. Анда моңарчы төгәл яктыртылмаган аерым вакыйгалар, эшчәнлекләре ачылып җитмәгән шәхесләр хакында эреле-ваклы фактик мәгълүматлардан торган (информация чыганаклары төгәл күрсәтелгән) кечкенә-кечкенә язмалар басылсын иде.

Зур мәсьәләләр буенча полемикалар, принципиаль фикер алышулар, минемчә, «Бәхәсләр» бүлегендә урнашырга тиешләр. Тик монда гомум теоретик сүз боткасына юл куелмасын, бәлки чын-чынлап бәхәсле фактлар гәүдәләнсен иде.

«Мирас»ның сынау максаты белән чыгарылган беренче санынннан (1/91) күренгәнчә, фидакарь эшкә алынган редакция хезмәткәрләре алдында мадди кыенлыклар басып торуын да онытмыйк... Хәятебезнең барлык даирәләрендә диярлек девальвация һәм регресс – рухи һәм җисмән таркалу хөкем сөргән заманда мондый кыенлыклар белән көрәшү җиңел булмас, әлбәттә. Шулай да җиңел юл эзләүнең никадәр хәтәр һәм ахыр чиктә мәгънәсез булуын 70 еллык тарихыбызның бүгенге нәтиҗәләре артыгы белән расласа кирәк...

Җыеп әйткәндә, яңа журнал алдында мин өч төрле мөһим һәм гаять авыр бурыч торуын күрәм:

1) гамәлдә мөстәкыйльлек һәм фикердә хөрлеккә омтылу;

2) эчтәлектә киңлек, ягъни чын рухи байлыкка таяну;

3) эштә сыйфатка, димәк, тынгысыз хезмәткә алыну.

«Мирас», №1, 1992.
Баш редакторы –Флүн Мусин.

Сүз һәм сурәт

«Бу данлыклы шәхес белән без иркенләп гәпләштек». 1956 ел

Наил Дунаев

«Мәскәү театр мәктәбенә имтихан бирергә килгән абитуриентлар. Яшь чаклар – гүзәл чаклар! ХәмзәАрсланов белән мин, уртабызда – танылган драматург Гамир Насрый. Бу данлыклы шәхес белән без иркенләп гәпләштек».

***

«Беренче тапкыр Ленинградка кузгалу, яшьлек дәрте ташып торган романтика чоры. Султан уңга: Татьяна Дунаева (минем сөекле

«Беренче тапкыр Ленинградка кузгалу, яшьлек дәрте ташып торган романтика чоры». 1960 еллар

хатыным, ягъни мәсәлән), мин бахырыгыз, Ринат Таҗетдинов, Ә.Дәминова, Нәҗибә Ихсанова, Рифкать Бикчәнтәев».

«Әзәрбайҗан театр җәмәгатьчелеге белән». 1974 ел

«Нәкый ага Исәнбәт хозурында» 1980 ел

***

«Әзәрбайҗан театр җәмәгатьчелеге белән Татарстан театр әһелләренең борынгы Баку шәһәрендә 26 Баку комиссарына куелган һәйкәл янында бергә очрашкан чагы.»

***

«Һиҗрәт» (Качаклар) спектакленнән бик канәгать калган, әатлык хисләре кичергән автор Нәкый ага Исәнбәт үзенең өенә чәй мәҗлесенә чакырган иде. Рәсемдә (сулдан уңга): Рәшит Шамкаев, Ринат Таҗетдинов, Нәкый Исәнбәт, Наил Дунаев, Дилүс Касыймов».

***

«Данлыклы «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә без өч бертуганны уйнадык: Закир – Равил Шәрәфиев, Фәтхи – Сәлим Мифтахов, Алтынбай – мин бахырыгыз Наил Дунаев. Аллага шөкер, өчебез дә исән-сау!»

«Аллага шөкер, өчебез дә исән-сау!» 1978 ел

«Карт ролендә – Әзһәр Шакиров, Күрше ролен мин башкардым». 1989 ел

***

«Бичура» (әсәр авторы – Мансур Гыйләҗев) – Фәрит Бикчәнтәевнең диплом спектакле. Яшь режиссёрга, театрга һәм драматургка зур уңыш китерде ул. Без анда бик дулкынланып уйнадык. Аксак ролендә – Әзһәр Шакиров, Күрше ролен мин башкардым».

***

«21 ел буена сәхнәдән төшми уйналган «Гөргери кияүләре». Кәтернә – Фирдәвес Хәйруллина, Гөргери – Наил Дунаев».

«Гөргери кияүләре» 1995 ел, 25 май.

«Мәхтүм Колый һәйкәле янында истәлеккә фотога төштек». 1993 ел

«Ниһаять, Ашхабадка да барып җиттек. Җирле татарлар Нәүрүз фестиваленә килгән Татарстан артистларын олылап кунакка чакырды. Мәхтүм Колый һәйкәле янында истәлеккә фотога төштек».

***

«Безгә – театрның өлкән артистларына Туфан Миңнуллинның «Галиябану, сылуым иркәм» спектаклендә уйнау насыйп булды. Фирдәвес Әхтәмова – Фидая, мин Туран ролендә».

Фирдәвес Әхтәмова – Фидая, мин Туран ролендә». 2005 ел

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Күңел кемне сөйсә, омтылыр аңар,
Якын кебек булыр, ерак аралар.

Илбикнең Уйгырмышка соравы

Илбик әйтте: – Иң төп сүздән элгәре,
Соравым бар – шуңа җавап бир әле.

Беләсең, никадәр мөһим эш сәлам,
Кем намуслырак, шул сәламли тәүләп.

Мине күргәч, шундук сәлам бирмәдең,
Сәламдә өстенлек алыйм, димәдең.

Уйгырмышның җавабы

Җаваплап, Уйгырмыш әйтте: – Әс-сәлам!
Ник әйтмәдем – аны мин яхшы беләм.

Сәлам ул сәламәт булуны теләү,
Вә сәлам бирүче бирәдер бүләк.

Сәлам биреп, кеше исәнлек ала,
Һәм үзенең җаны да исән вә аман.

Бу бабта хәтергә шундый сүз килде:
—Ишет моны син дә, күңле төз, инде:

«Сәламләүче бирә иминлек – сәлам,
Ә сәлам алучы иминлек ала.

Сәлам ул – кешеләр шәрреннән[1] саклау,
Һәм сәлам алучы шәррдән саклана».

Кечене сакларга тиеш олылар,
Кечеләр сакласа, хәл бүтән була.

Илбик саклый мине кеше шәрреннән,
Мин өмет итәмен аның хәйренә.

Мин кече, миннән шәрр тиясе түгел,
Илбик олы – менә минем сүз төбем.

Илбик кулы барча халык өстендә,
Илбик олы – илат аның хөкмендә.

Димәк, сәламләми халык илбикне.
Менә шул мәгънәне сиңа белгерттем.

Менә үзең тәүләп, «хезмәтемә» дип,
Үзең чакырдың ич, хәлемне белеп.

Мин өнәмәдем һәм сүзең тотмадым –
Дөнья тозагына башым тыкмадым.

Хәзер тәклифеңне ташлагачтын, мин
Күрешергә генә каршыңа килдем.

Бүгенгәчә синнән имәнеп тордым,
Яхшы булды, менә син сәлам бирдең.

«Тагын элеккене кабатламагай», –
Дип, берәз шикләнеп килдем мин, агай.

Хәзер ниятең дә төгәл билгеле,
Димәк, синнән тия бары игелек.

Илбикнең җавабы

Илбик әйтте: – Бийгә бик начар эш бу –
Үз телеңнән әйткән сүзеңнән кайту.

Кечене сакларга тиеш олылар,
Кечеләр сакласа хәл бүтән була.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1]Шәрр – «явыз ният, явыз уй, каст» (бу сүз дини стильдә татар телендә дә киң кулланыла).

Аңа – озын кулга – тимәсен хөрмәт,
Әгәр үз сүзенә йөрсә киреләп.

Шул зат баш булмасын илгә-көнгә һич,
Кем телендә алдак, күңлеңдә үч.

Ул ничек бий булсын, халыкка – олуг,
Теле ялган булса, ә күңле коры.

Мәкальдә миннән дә шәбрәк әйтелгән:
«Сүздән кайткан мәлдә кот кача» дигән.

Иң явыз кеше ул – ялганчы бәндә,
Явызның явызы – вәгъдәсезләрдә.

Ни яхшы әйткән бер туры сүзле ир
(Туры сүзлеләргә, Алла, ярдәм бир):

«Бий әйтсә, булмасын сүзнең ялганы,
Сүзенә тормаса, ир димә аны».

Ир-егетләр кайтса әйткән сүзеннән,
Димәк, алар – начар хатынга тиңнәр.

Җаваплап, Уйгырмыш әйтте: – Илбик, сез
Бу кылыкларыгыз белән изгесез.

Биләмәләрегез артсын Ходайдан,
Изгелекләрегез булсын зиадә.

Халыкның асылыдыр илбик үзе,
Үзе кебек асыл булсын бий сүзе.

Иң явыз кеше ул – ялганчы бәндә,
Явызның явызы – вәгъдәсезләрдә.

Белеклеләр хәбәр бирәләр болай:
«Изге булса илбик, халык булыр бай».

Ни ди, ишет, ак-чал башлы агалар,
Дөнья күргән шактый яшьле агалар:

— Иге эшләр кыл, и дөнья тотучы,
Шуннан очып килер сиңа кот кошы.

Бий булып та изге атың юк икән,
Кот кошы үпкәләп очып китүчән.

Яманлык кылма һич, и, кулы көчле,
Гел изгелеккә бор,сүзне һәм эшне.

Олуглык-бийлегең киткән чакта да,
Калган изгелегең хәтердә кала.

Бүген изгелек кыл – күтәр ил йөген,
Шиксез кайтыр соңрак ул изгелегең.

Терелек көннәрең охшаш җилләргә,
Килә дә китә – кот кошы җилбәзәк.

Илбикның җавабы

Илбик әйтте:— Тыңла, и, әһле-гыйлем,
Белем капкачын ач, шулдыр теләгем.

**Еш кына бер кемсә биргән киңәшне
Бирәлми җыелып килгән мең кеше.**

Шуңабик җентекләп сорыймын тотып –
Мин гыйлемгә ачмын, ә син исә тук.

Миңа бир иң кирәк гыйльмеңнең барсын,
Таки игелеккә кулларым барсын.

Тамак, нәфес чире күп кешеләрдә,
Тугрылык һәм рәхим аз очрый, мәгәр.

Бий кеше булдыра – кемгә ни кирәк,
Тик үз күңелеңдә табалмый терәк.

Сәрай әһле башлы, хадим күп төрле,
Киңәшерлек түгел, хәким, һич бере.

Минем хәлне бәян иткән шигырь бар,
Укып кара шуны, биреп игътибар:

«Кеше дип исәптә торучы сансыз,
Кешегә ярдәмгә килер соң кайсы?»

Еш кына бер кемсә биргән киңәшне
Бирәлми җыелып килгән мең кеше.

И, Уйгырмыш дустым, бердәнбер шундый
Кешеләрнең берсе менә син булдың.

Исемең яраша кылмыш эшеңә,
Ходай үзе рәхмәт яудырсын сиңа.

Өлеш чыгар миңа Ходай биргәннән,
Чәчәк атсын күңел, үлсен нәфес-тән.

Уйгырмышның җавабы

Һәм Уйгырмыш җавап бирде: – И, бийем,
Син тышыма карап мактыйсың мине.

Эчемдәген белсәң, егет, әгәр дә,
Куар иде, бәлки, каһәрләп.

Мин заһит исемен күтәреп йөрим.
Бу ат-исем авыр гыйбадәт йөгем.

Мине күтәрә тик заһит исеме,
Минем өчен бикле нәфес ишеге.

Кибетне бизәдең, ди, күркәм итеп,
Сатуның шәплеген белдерми бу, тик.

Кешенең тышына, илбик, карама,
Аның эчендәген байкап бак аңа.

Ни матур булса да кайчак бер кавын,
Һәм төсе алса да күзеңнең явын,

И, боланым, ул һич татлы булмаса,
Аны ыргыталар ләбаса!

Ни ди, ишет, әнә уяу бер зирәк:
«Тышыңны сырлама, эчеңне бизәт».

Эчтәлеге илә кыйммәт һәрнәрсә,
Эчтәлексез тышның калмас мәгънәсе.

Илбикнең җавабы

Җаваплады Илбик: – И, нурлы күзем,
Эчең дә, тышың да тиң матур синең.

Дөньяны ташладың – йөгең кимеде,
Ә мин авыр йөктән абынам инде.

Бу дөнья эшләре мине биләде,
Тагать-гыйбадәткә вакыт тимәде.

Үгет-нәсихәт бир, тыңлыйм хәзер мин,
Котайтсын сүзләрең, йолыйм үземне.

Уйгырмышның җавабы

Җәвапта Уйгырмыш әйтте: – И, бийем,
Изгелек-савапка син эштә тиен.

«Ходай колларының иң явызы мин»,
Дип уйлама тагы, и, белеме киң.

Бик беләсең килсә, Ходаемның бер
Иң явыз бәндәсе, бәлки, ул миндер.

Булыр микән минем сүземнән ярдәм?
Мөгаен, мин түгел иң изгеләрдән.

Болай, мин, әлбәттә, өмет өзмимен,
Кылмышымны Ходай ярлыкар, димен.

Ни ди, ишет, әнә языклы коллар –
Ничек гафу сорап гозер кылырлар.

«Языклы, җәфалы, түбән колыңмын,
Багып күрсәң, гөнаһ илә тулы мин.

Сыгыныр Тәңрем юк синнән тыш һичбер,
Күңелемә кот бир, гөнаһны кичер».

Җавап бирде илбик: – И, уяу изге,
Тыйнаклыгың сине тагын да бизи.

Үзеңне яман дип исәпли алсаң,
Халык сине изге дип әйтә башлар.

Күңлемне пакьләдең, үзең пакьләндең,
Миңа бер үгет бир – коткар гафләтдин.

И, изге фигыльле һәм саф күңелле!
Үгет бир – күрсәт бер рәхимлегеңне.

Сиңа Тәңре биргән барча арулык,
Изгелек юлын ач миңа, акыллы.

Изге кеше, сиңа акыл бирелгән,
Әҗерен Хак бирер, шиксез, җәренгә[2].

Уйгырмыш Көнтугды илбиккә үгет бирә

Җәваплап Уйгырмыш әйтте: – И, илбик,
Теләгеңә Тәңре кул бирсен инде.

Бу фани дөньябыз – кыпчак чүплеге,
Күп бийне картайтты – картаймый үзе.

Сансыз синдәй бийне озатты инде,
Әзерлән, сиңа да күз атты инде.

Син аңар чынлап баглама күңел:
Вафасыз ул төптән – син аннан түңел.

Нигә сиңа миннән үгет, тәүсыя?
Замана әхвәле бер үгет сиңа.

Синнән элек дөнья тоткан батырлар —
Кайда алар? Бар да китеп бардылар.

Кая киттеалар – уйла шул ягын,
Сиңа да юллану көннәре якын.

Үзеңне яман дип исәпли алсаң,
Халык сине изге дип әйтә башлар.

Бүген сиңа тиде бу бийлек коры,
Тик озакка түгел – бик белеп йөре.

Нәрсә анда файда бирсә аларга,
Сиңа да нәкъ шуны кирәк карарга.

Һәм алар үлгәндә нык үкенделәр,
Ерак тор шул хәлдән, саваплар телә.

Ни шәп әйткән берәү – белекле кеше
(Белекленең сүзе – якут һәм энҗе):

«Үлекне күргән зат калмастыр тере[3],
Үлемгә әзерлән һәм булма эре.

И, холкы үлеме каршында гафил,
Кичәр бу тереклек – үзең уйла, бел».

И, гафил йөрүче бер нәфес колы,
Үлем ерак дисәң, каршыңда булыр.

Үткән көннәреңне исеңә төшер:
Уйлап караганда, гүя бер төштер.

Әгәр кылган булсаң үзең игелек,
Урын әзерләнгән сиңа мәңгелек.

Зая кылдың исә син гомереңне,
Төннәрен йоклама һәм үкен инде!

Яңа гомер теләп, кайтаралмассың,
Егетмен, дип тагы әйтә алмассың.

Бу ирешкән хәлең булмасын зая,
Хәзер ахирәткә әзерлән, кая.

И, илбик, багып күр ки, синнән элек
Атаң бит төзеде күренекле билек.

Сәрайлы, казналы, гаскәрле булып,
Яшәде ул бераз тантана кылып.

Үлем аны тотты, кабергә илтте,
Йолалмады аны даны-күәте.

Дәвамы бар ■

---

[2] Җәрен монда «киләчәк» мәгънәсендә кулланылган.
[3] Бу җөмлә бик үк аңлашылмый. Гомумән, «һәрнәрсә, һәркем үлә» мәгънәсендә.

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ



Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Романга бәян тәкъдим итәм. Бу ни соң – яңа жанрмы? Билгеле, мондый жанр була алмый. Шулай да, тормышта төрле хәлләр очраштырып торуын искә алсаң, язганымның «Гасырдан озынрак сузылган көн» дигән романга өстәлгән повесть икәнлеге аңлашылыр. Хәер, ул өстәлгән дә түгел, ә баштагы варианттан төшеп калган өзек кенә; идеологик басым чорында, барысын күреп-белеп торган цензорлар һәм «өстәгеләр» фикере әсәр язмышын административ тәртиптә хәл иткән заманнарда – бу текстның ничек, ни өчен «кыскартылуы» турында сөйләп тормыйм. Китабың чыксын дисәң, көчле давыл вакытында укучы ярларына таба кузгалган корабка артык йөк төямәс өчен, ни барына шөкер итәргә туры килә иде.
«Җырланып бетмәгән җыр»ны очлап бетерү бик сирәк очракта насыйп була. Әмма бу юлы нәкъ менә шундый мөмкинлек туды. Ниһаять, иске «яңа» романымның әлеге өлешен тәкъдим итәм. Әйтергә кирәк, бу бәянда Чыңгызхан турында күчмә халыкларның телдән-телгә йөргән бер риваяте, – чынбарлыкка дәгъва итмәсә дә, тарихи хәтерне яңарта торган миф файдаланылды.

Чыңгыз АЙТМАТОВ

Бу якларда поездлар кояш чыгышыннан кояш батышына һәм кояш батышыннан кояш чыгышына таба йөри иде...

Салкын Сарүзәк киңлекләреннән җилләр бертуктаусыз күтәреп торган ак томанны аралап баручы поездларның машинистларына кар-буранлы ул февраль төннәрендә, даладагы кар көртләре арасыннан кечкенә Буранлы станциясен күрмичә узып китмәс өчен, шактый нык тирләргә туры килә. Күбекләнеп торган җил-давыл белән уралган поездлар, тынычсыз йокы вакытында сискәнә-сискәнә күргән төш сыман, караңгылык эченнән килеп чыгалар да алдагы төн карасына таба тәгәрәүләрен беләләр...

Мондый төннәрдә дөнья яңадан яратылган сыман; сулышлары капкан Сарүзәк далалары исә, дөм-караңгылык белән көрәшкән яктылыкка башларын күтәреп карау белән, янә ак давылга әйләнеп калучы дәрьяны хәтерләтә...

Менә шул бөек бушлык уртасында һәр төнне, таңга кадәр сүнмичә, кечкенә

станциянең бер кечкенә тәрәзәсе яктырып тора – әйтерсең лә анда, шул тәрәзәчек артында, нindидер җан иясе ачыргаланып бәргәләнә, әйтерсең лә анда, үз-үзенә урын таба алмыйча, кемдер рәхимсез чир белән көрәшә яки аяусыз йокысызлыктан интегә. Ул, станция янында гына, Әбүталип Куттыбаев гаиләсе яшәгән барак тәрәзәсе иде. Әйе, алар – хатыны белән балалары – төнгелеккә дә ут сүндерми аны көтәләр, ә Зарипа төн уртасында лампа филтәсенең янган өлешен берничә мәртәбә кискәләп ала. Яңадан дөрләп киткән ут яктысында, теләсә-теләмәсә дә, пар эт балалары кебек йоклап яткан улларына – кара чәчле ике ташбашка моңаеп карап тора. Салкыннан аның әчке күлмәк кенә кигән тәне калтырый, күшеккән кулларын күкрәк турысына кушырып, бер төенгә йомгакланып, ул аларга янә бер күз ташлый да коты алына: төшләренә аталары керер дә, алар, кулларын җәеп, елый-елый, көлә-көлә, узыша-узыша бөтен көчләренә аңа таба йөгерерләр, әмма барыбер ул күздән югалганчы барып җитә алмаслар да күз яшьләренә манчылып уянырлар дип куркуга төшә... Кара-каршы килүче составларны үткәреп җибәрә торган бу кечкенә станциядә ярты гына минутка булса да туктап ала торган теләсә кайсы узгынчы поезддан аталарын өндә дә көтә бит алар. Тормозларын шыгырдатып поезд туктау белән, малайлар, аңа ташланырга әзер торган кебек, тәрәзә буеннан нечкә муеннарын сузалар. Әмма көннәр дә, поездлар да уза тора, аталары һаман күренми, аның турында ник бер хәбәр ишетелсен, әйтерсең лә ул таулардан кинәт ишелеп төшкән галәмәт зур кар көрте астында калган, аның белән кайчан-кайда ни булганын һичкем белми иде.

Ул төннәрдә тагын бер тәрәзәдә – тик ул кара тимердән коелган нык рәшәткә белән капланган һәм Җирнең икенче читендә урнашкан Алматы тикшерү изоляторының ярымподвалыннан мәхбүс күзләре белән карап тора – шулай ук таңга кадәр ут сүнми. Менә инде бер ай булгандыр, Әбүталип Куттыбаев түшәмдәге тәүлекләр буена сукырайтып янган көчле «Ильич лампасы»ннан интегә. Ул аңа күктән төшкән ләгънәт иде булса кирәк. Кая барырга белмичә, бораулап, ит пычагы кебек тураклап торучы электр яктысыннан сызлый башлаган күзләрен ничек сакларга икән дип, бер мизгелгә булса да онытылып, ни сәбәпле монда китереп ябулары турында уйлаудан туктап һәм аңардан ни-нәрсә таләп итүләрен белергә теләвен басып торыр өчен, хәсрәтле башын коткару әмәлен таба алмый ул. Төн җиткәч, күлмәге белән шул кайгылы башын каплап, мәче косыгы төсенә буялган стенага таба борылуы гына була, ишек күзеннән карап торучы назир-надзиратель шунда ук камерага ыргылып керә, аны тар сәкедән бәреп төшерә дә типкәләргә керешә: «Стенага борылып ятма, кабахәт! Башыңны каплама, хәшәрәт! Власов ялчысы, бәдбәхет!» Үзенең власовчы түгеллеген әйтеп, ул күпме генә тәкърарласа да, моңа һичберсенең исе китми иде.

Шуннан соң Әбүталип, рәхимсез электр утына йөзен яңадан куеп, ялкынсынган, сызлаган күзләрен учлары белән каплап, гомумән, күзләре генә түгел, баш миенең дә тереклек итүдән тукталуына, һичбер яктылык төшми торган, кабердәге сыман караңгылыкта калуына сусап-изаланып ята. Менә шул көн җитсә, инде ичмасам, бер назирның, бер тикшерүченең дә аны түзә алмаслык җәза – ут яктысы белән, йокыдан мәхрүм итү һәм кыйнаулар белән газапларга хәленнән килмәс иде.

Назирлар чиратлашып алышына тора, әмма барысы да бер иш булып, каты бәгырьле иделәр, – аларның берсе дә мәрхәмәт күрсәтмәде, тоткынның стенага борылып басуын яки ятуын күрмәмешкә салышмады, киресенчә, шуны көтеп кенә торалар һәм һәркайсы, ярсып, сүгенә-сүгенә кыйнарга керешә иде. Әбүталип Куттыбаев төрмә назирының вазифасы һәм бурычлары нидән гыйбарәт икәнлеген чамаласа да, кайчак, өметсезлектән ачыргаланып, үзеннән үзе сорый: «Нишләп мондый соң

алар? Карап торуга, адәм балалары кебек бит. Шулкадәр явызлыкны үзеңдә ничек асрап йөртергә мөмкин?! Минем аларның берсенә дә һичнинди зыяным тигәне юк лабаса. Моңарчы алар мине белмиләр иде, мин – аларны, әмма кан үче алган сыман кыйныйлар, мыскыл итәләр. Нигә шулай? Кайдан килә икән мондый бәндәләр? Ничек шундый булып җитешәләр алар? Ни өчен мине газаплыйлар? Ничекләр түзәргә, ничек акылдан язмаска да ничек башыңны стенага бәреп ярмаска?! Бүтән котылу юлы юк ич».

Бер тапкыр ул барыбер түзмәде. Әйтерсең лә эчендә ак яшен камчысы шартлап алды. Үзен типкәләргә керешкән назирга ничек барып ябышканын аңламый да калды. Алар, ярсып йолкыша-сугыша, идән буйлап тәгәрәделәр. «Мин сине фронтта күптән инде тилергән эт кебек атып үтергән булыр идем!» – дип, назир гимнастеркасының якасын шытырдатып умыра-умыра, катып калган бармаклары белән аның бугазын кысып гыжылдады Әбүталип. Әгәр коридордан тагын ике сакчы кереп өлгермәсә, моның ни белән бетәсе билгесез иде.

Әбүталип икенче көнне генә үз аңына кайтты. Иң элек бөтен тәне авыртуын тойды, аннары томан арасыннан түшәмдәге мәңге сүнми торган лампа уты бәреп чыкты. Ниһаять, өстендә нидер сихерләп маташучы фельдшерга күзе төште.

– Ят, миленький, син инде хәзер теге дөньяга китә алмыйсың, – дип, аның яраланган маңгаена бинт кисәкләре куя-куя, әкрен генә эндәште фельдшер. – Әйдә бүтән болай җүләрләнмә. Сине әле дә, сакчыларга һөҗүм иткәнең өчен, сытып, эт урынына чыгарып ташлый алган булырлар, һәм синең өчен һичкем җавап бирмәс иде. Тансыкбаевка рәхмәт укы, – аңа синең үләксәң түгел, ә үзең кирәк, тере килеш. Аңладыңмы?

Әбүталип эндәшмәде. Аның белән алга таба ни булачак, язмышы кайсы якка борыла – бу мизгелләрдә аңа барыбер иде. Күңеленең – газаплануны, хәтта тәненең авыртуны тою сәләте дә тиз генә кайтмады.

Ул көннәрдә вакыт-вакыт аның аңы томаланып алгалады, – хәер, чынбарлыкны аермыйча, ярымөндә, ярымтөштә яшәү аны саклаучы, коткаручы бер халәт булгандыр әле. Шундый мәлләрдә Әбүталип үзенә юнәлтелгән уттан да качарга, котылырга теләмәде, киресенчә, аны акылдан шаштыручы, котылгысыз җәзага дучар иткән яктылыкка таба омтылды, аңа, берөзлексез сукырайтып торучы утның көчен җиңәр өчен, үзен ирексезләп, әлеге авырту, ярсыту чыганагына якыная-якыная да җисемен тоймыйча эреп югаладыр һәм төпсез бушлыкта очып йөридер кебек тоела иде.

Ләкин шул чакта да изаланып беткән аңындагы үткәндә калганнар белән бәйләп торучы бер ефәк җеп өзелми, аны йөрәгеннән суырып тарта, аз гына вакытка да ычкындырып тормый... Ул – иксез-чиксез сагыш, гаиләсе, балалары өчен туктаусыз курку иде.

Сарүзәктә калганнар турында уйлап, түзә алмаслык газап эчендә янган Әбүталип үз-үзен хөкем итәргә, гаебен аңларга, нигә аны чынлап та җәзаларга тиешләр, дигән сорауга җавап табарга тырышты. Ләкин җавап таба алмады. Чолганышта калырга туры килгән башка меңнәр кебек үк, әсирлеккә төшкәне, немец тоткынлыгында булуы өчен, дисәң генә инде. Тик, шул иске җәрәхәтне кузгатып, күпме интектерергә була? Сугыш инде артта калды. Барысы өчен дә артыгы белән түләнгән – кан белән дә, лагерьлар белән дә. Сугышта булганнарның күбесенә кабергә кереп ятар вакыт җитеп килә, ә чиксез хакимияткә ия зат әле һаман аларны эзәрлекли, һаман тынычлыкта калдырмый. Бу хәлләрне ничек аңлыйсы? Җавап таба алмагач, Әбүталип, үзе белән аянычлы аңлашылмаучылык кына килеп чыккандыр, бүген булмаса иртәгә шул ачыкланыр, дигән өмет белән яши, әгәр шулай булып чыкса, Әбүталип

Куттыбаев шунда ук бөтен-бөтен үпкәләрен онытыр иде; тизрәк азат итсеннәр дә тизрәк өйгә җибәрсеннәр генә, ул анда, Сарүзәктә, Буранлы станциясендә, аны көтеп арыган балакайлары Эрмек белән Даул, карлы далада сабыйларын яралы канаты астында, ярсып типкән йөрәгенә кысып саклаучы, күз яшьләре һәм иксез-чиксез ялварулары белән язмышны үзләренең гөнаһсыз икәнлегенә ышандырырга тырышучы, иренә котылу насыйп булсын өчен, Алладан мәрхәмәт сораучы хатыны Зарипа янына йөгереп, юк, очыплар кайтыр иде.

Хәсрәтеннән үкереп еламас өчен, акылыннан тәмам язмас өчен, тынычлык эзләп, Әбүталип үзен-үзе алдамакчы була: менә ул хыялга бирелә – бер гаебен дә раслый алмаулары аркасында, акланып, кинәт өенә кайтып керүен күз алдына китерә. Имештер, ул, юл уңае туры килеп, өенә кадәр утыртып кайткан товар вагонының баскычыннан сикереп төшә дә өенә йөгерә. Имеш, хатыны белән балалары аңа каршы чабалар... Әмма мондый минутлар тиз уза, һәм ул, махмырдан соң айнып киткән кебек, кабат күңел төшенкелегенә бирелә, шул чакта аңа, үзе язып алган «Сарүзәктә җәзалап үтерү» риваятендәгедәй, бер гөнаһсызга асып җаны кыелган ата-ананың газапланулары, аларның яңа туган сабый белән бәхилләшүләре мәңге дәвам итә торган, хәзер инде аның үзенә дә кагылучы хәл булып тоела. Ул да аерылу җәзасына дучар ителде ләбаса. Ә бит балаларны ата-анадан бары тик үлем генә аерып алырга мөмкин, бүтән һичкемнең, һичнәрсәнең моңа хакы юк...

Әбүталип шундый сагышлы минутларда үз-үзеннән оялып, әкрен генә елый, нык яңакларын ташка сибәләп яуган яңгыр сыман чылатып аккан күз яшьләрен ничек тыярга белми. Хәтта сугышта да ул болай ук газап чикмәгән иде бит, ул чакта, «кайгым юк буранда, атым юк урамда» дигәндәй, үзалдына гамьсез генә яши төсле иде, ә хәзер, бер карасаң, гап-гади күренештә – балаларда – тормышның иң бөек мәгънәсе тупланган, һәм һәрбер очракта, һәркем өчен нәсел дәвамы булудан да зуррак бәхет юклыгына, шуңардан мәхрүм калу исә фаҗига икәнлегенә инана бара... Инде ул югалтыр алдыннан фани дөньяның никадәр мәгънәгә ия булып алдыңа килеп басуына, иң соңгы сәгатьтә, йөрәкне талаган ут балкышыннан котылып, мәңгелек караңгылыкка кереп чумар алдыннан, бөтен тормышына йомгак ясар вакыт килеп җиткәненә ышанды. Әйе, яшәүнең төп йомгагы – балалар икән. Ихтимал, табигатьтә ул шулай корылгандыр да – ата-ананың тормышы үзләренең дәвамын үстерүгә сарыф ителә. Ата-анадан балаларын аерып алу – җинаять, кешене бу дөньядагы төп бурычын үтәү мөмкинлегеннән мәхрүм итү, аның тормышын буш башакка әйләндереп калдыру дигән сүз. Менә шулай аңы ачылган чакларда, кайчан да бер мөмкин булыр кебек тоелган көрешү мәлләрен ап-ачык диярлек күз алдына китергәч, күңелең нечкәреп, төшенкелеккә бирелми калуың бик кыен шул; өметенең тормышка ашмасын Әбүталип, әлбәттә, аңлый һәм шуңа күрә чарасызлык корбанына әверелә иде. Көн узган саен, сагыш аның күңелен тирәнрәк били, аяусызрак кимерә барды һәм, ихтыяр көчен суырып, тәмам хәлсезләндерде. Өметсезлек текә тау битендәге юеш кар сыман туплана, аның менә һич тә көтмәгәндә ишелеп төшүе якынлаша сыман иде...

МГБ (Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы) тикшерүчесе Тансыкбаевка шул гына кирәк тә: ул, нәкъ менә эзлекле һәм максатчан рәвештә, мәкерле ниятенең барып чыгуына омтылды – элеккеге хәрби әсир Әбүталип Куттыбаевның, Югославия һәм Англия разведкалары белән бәйләнештә булып, Казагыстанның ераграк төбәкләрендәге җирле халык арасында корткычлык фикерләрен таратуы турында, иблис кебек, үзе уйлап чыгарганнан соң, өстәге башлыкларының хуплавына таянып, «үрә башлаган» бик хәтәр «эш» иде бу. Аның гомуми кысасы бик гади,

Тансыкбаевның чиктән тыш сәяси уяулыгын һәм хакимияткә хезмәт итәргә ашкынып торуын расларга тиешле үрмәкүч тозагы корып куелды инде. Әбүталип – менә дигән корбан. Билгеле, алда әле кайбер нечкәлекләрне ачыклау, бәяләү – үзенә күрә тикшерү эше тора, тик моңарчы Куттыбаевның җинаятен үзе тулысынча тануы кирәк. Әлеге «эш» Тансыкбаев өчен аның тормышындагы зур уңыш булса, Әбүталип Куттыбаевны ул өметсезлек чоңгылына батырырга көтеп тора иде, чөнки мондый капкыннан котылу юлы юк. Бу – тулысынча алдан хәл итеп куелган очрак, мондый гаепләүне тагу ул заманда үзе үк инде җинаятьне берсүзсез исбатлау дип санала иде.

Шуңа күрә Тансыкбаевка әлеге мәкерле эше ничек барып чыгар дип борчылмаска да була. Ул кышны, ниһаять, кем әйтмешли, аның кар ера-ера карьерага бару сукмагы алдан ук көрәп куелган иде. Хезмәтендә вак кына хата киту аркасында, ул берничә елга майор дәрәҗәсендә тоткарланып калды. Ә хәзер, күрәсезме, күтелмәгәндә яңа мөмкинлек ачылырга тора. Үзәктән читтә Әбүталип Куттыбаев эшенә охшаган нәрсәдер табуы бер дә еш була торган хәл түгел. Менә бит, уңса да уңар икән майор!

Әйе, 1953 елның карлы-буранлы февраль көннәрендә дөнья барышы Тансыкбаевка мәрхәмәт күрсәтте: әйтергә мөмкин, ил тарихы аның мәнфәгатьләренә хезмәт итәр өчен генә яшәгән кебек иде. Аңлаудан бигрәк, сиземләү аша, ул бу тарихта үз хезмәтенең әһәмиятен беренче дәрәҗәле итеп куеп, гел генә көчәйтеп торучы, шуның белән аның үзен дә торган саен ныграк күтәрә баручы изге көчне тойды, шуңа күрә яңа «эш»кә тагын да дәртләнебрәк алынды һәм чиксез рух күтәренкелеге кичерде. Хәзер көзгегә карасa да, ул гаҗәпкә кала – аның керфек какмый торган лачын күзләре күптән болай яшь булып балкымыйлар иде бит. Менә ул иңнәрен турайтып, канәгать төс белән, борын астыннан гына саф русча җырлап җибәрә: «Мы рождены, чтоб сказку сделать былью...» Аның ни-нәрсәгә өметләнеп яши башлаганын белеп-хуплап торучы хатыны шулай ук кәефле генә күренә һәм, җае чыккан саен: «Ярар, тиздән без дә үзебезгә тиешлене алырбыз әле», – дип куйгалый иде. Өлкән класста укучы уллары, комсомол активисты, ул да, кайвакыт атасын тыңламаган чаклары булса да, мондый форсатны күргәч, чын күңелдән сораша, әледән-әле: «Эти, подполковник йолдызлары белән котлыйсы көн еракмы әле?» – дип, атасының күңелен күреп тора. Тансыкбаевка турыдан-туры кагылмаса да, мондый ашкынуның үз сәбәпләре бар иде...

Эш шунда ки, чагыштырмача күптән түгел, ярты еллап кына элегрәк булыр, Алматыда ябык процесс уздырдылар: хәрби трибунал казакъ буржуаз милләтчеләренең бер төркемен хөкемгә тартты. Хезмәт халкының бу явыз дошманнары аяусыз рәвештә һәм мәңгелеккә юк ителде. Икесе, казакъ телендә язган, яңа чынбарлыкны инкяр итеп, каһәр суккан патриархаль-феодаль үткәннәрне идеаллаштырган фәнни хезмәтләре өчен, иң югары җәзага – атып үтерелүгә лаек дип табылды, Фәннәр академиясенә караган Тел һәм әдәбият институтының ике хезмәткәре егерме бишәр ел каторга алды... Калганнары, дөрес, унар ел белән генә котылды... Шулай да иң мөһиме: әлеге процесс белән бәйләп, буржуз милләтчеләрне фаш итүдә һәм аларның тамырларын рәхимсез рәвештә куптарып ташлауда турыдан-туры катнашкан махсус хезмәткәрләргә үзәктән зур дәүләт бүләкләре кайтты. Ул бүләкләрне яшереп кенә бирделәр-бирүен, әмма, аңа карап, бәяләре кимемәде. Кушылганны үрнәк төстә үтәгән өчен погоннарга вакытыннан алда йолдызлар тагу, орденнар һәм медальләр өләшү, зур акчалар белән бүләкләү, боерык белән рәхмәт белдерү һәм башкача игътибар күрсәтү органнарда хезмәт итүчеләрнең тормышын бик бизәде, минсиңайтим! Аеруча тырышлык күрсәткәннәргә яңа фатир ачкычларын бирү дә бик ярап куйды.

Боларның һәммәсе аларның тавышын көрәйтте, аяк асларындагы туфракны ныгытты, итек үкчәләре дә ышанычлырак шакылдый башлады.

Тансыкбаев, үзе әлеге дәрәҗәләргә ирешкән һәм бүләк алганнар төркеменә кермәсә дә, хезмәттәшләренең тантана итүендә актив катнашты. Һәр кичне диярлек, хатыны Айкумис белән, алар чираттагы яңа дәрәҗә, орден, фатир алуларны «юу» мәҗлесенә юл тоттылар. Бәйрәм табыннары Яңа ел алдыннан ук бер-бер артлы башланып китеп, бик матур, онытылмаслык булып уза иделәр. Салкын, начар яктыртылган Алматы урамнарыннан, өшеп, җиңелчә калтыранып кергән кунаклар, әнә бусагадан узуга ук, яңа фатирларында көтеп торган хуҗаларның якты чыраен күреп, күңел җылысын тоеп кинәнәләр. Ишек төбендә каршылаучы йөзләрнең, күзләрнең шулкадәр җанлануын, бер горурлык хисе белән ничек балкуын күрсәгез иде! Чыннан да, болар – сайлап алынган, бәхет тәмен яңабаштан татучы бу кемсәләрнең күңел һәм корсак бәйрәме булып чыкты. Ул чакта, әле сугыш елларының күптән түгелге хәерчелеге һәм ачлыгы онытылып җитмәгәндә, илнең моның кебек читтәге төбәкләрендә яңа, нәзакатьле уңайлыклардан, канәгатьлек хисеннән башлар әйләнерлек иде. Биредә, провинциядә, кыйммәтле коньяклар, бәллүр кандилләр һәм затлы савыт-саба әле яңа гына модага кереп бара. Түшәмнәрдән трофей люстраларның күзне һәм җанны иркәләүче көмеш яктысы сирпелә, яңа явып киткән кар кебек ап-ак эскәтер ябылган өстәлләрдә немецтан алып кайтылган сервизлар җем-җем итә, боларның барысы да кәефне күтәрергә, хуҗаларга тирән хөрмәт күрсәтергә этәрә, һәм бу халәт килгән кунакларның да күңелен биләп ала: әйтерсең лә тормышның иң югары мәгънәсе шул люстраларда, сервизларда гына, әйтерсең лә дөньяда игътибарга лаеклы бүтән берни дә була алмый.

Ишекне ачу белән, аш пешерү бүлмәсеннән таныш исләр килеп бәрелә, анда, башка ризыклар белән бергә, иң кирәкле, иң затлы тәгам – бабайларның күчмә тормышыннан килүче, яңа диварларда да ерактa калган дала хуш исләрен хикмәтле рәвештә аңкытып торучы, йомшак, яшь ат ите пешә. Җыелганнарның барысы да, уртак аш табынының тәмен алдан сизеп, селәгәйләрен агыза һәм урындыкларга әдәпле генә утырыша башлый. Шул ук вакытта табынның мәгънәсе ашауда гына түгел икәнлеге аңлашыла, чөнки, туйгач та, кеше, эченнән генә, өстәл янындагы сүзләрдән – котлаулар һәм изге теләкләр әйтешүдән бигрәк, алдындагы ризыкның күплегеннән, муллыгыннан газаплана башлый, ә бит бу йолада бетмәс-төкәнмәс татлы хыялларның тормышка ашуына сөенеч йомарланып ята, һәм шушы хикмәтле хис тирә-юнеңдәге бар нәрсәне сыйдыра һәм үзенә сеңдерә бара. Хәтта көнчелек тә, вакытлыча гына, көнчелек үк түгел, ә кече күңеллелеккә, үзара дустанә мөнәсәбәткә охшап ала, икейөзлеклек исә кыска вакытка гына булса да риясызлыкка әверелә кебек. Катнашучылардан һәркайсы, гаҗәеп рәвештә мактаулы якка үзгәреп, башкалар белән, үз ихтыярларыннан тыш, игълан ителмәгән ярышка кушыла да мөмкин кадәр акыллырак, ә иң мөһиме – матуррак итеп сөйләргә тырыша. Аһ, бу һич кабатланмас, үзенчә мавыктыргыч бер тамаша иде! Табын хуҗасы, драма театрында тәхеткә менүче корольне уйнаган артист сыман, шулкадәр кукыраеп утыра, аннары, бәлки, үз гомерендә беренче тапкырдыр, шулкадәр тәэсирле итеп нотык сөйләргә алына.

Дәвамы бар ■

САБИРҖАН АГАЙ:

1906 сәнәдә булган ачлыкны тасвир кыйлган роман

Касыйм Бикколый

1906 ел Россиядә ачлык булган кеби «Иске Т.» карьясендә (авылында) дә иген асла булмадыкындан халык ифрат фәкыйрь, гаять ач иде. Ул елда карья халкы тәмам гаҗиз булды. Ашарга икмәк юк, хайваннарга азык юк, көз сачеп калдырырга орлык юк. Гәрчә хөкүмәт тарафыннан орлык бирелсә дә, тәмам җитәрлек бирелми. Шул сәбәптән күп кеше сыерын, яки артыграк каралтысын сатып, орлык алып сачмәктәләр иде.



«Иванов Идел (Волга) буенда саллар, баржалар йөртеп кәсеп кыйлдыкындан аңа һәрвакыт кеше кирәк булып тора...»

«Иске Т.» карьясендә алтмыш бишләргә җиткән бик булдыклы гаять гакыллы Сабирҗан исемле карт бар иде. Бу кеше гомерендә берничә кәррәләр мондый ачлыкларны күреп көрәшеп, ачлык илә тартышып, үзен, җәмәгатьләрен бу афәттән коткармыш иде. Бу сәнәдә Сабирҗан агай иген булмадыкны белгәч үк июль числасында, үзенең әүвәл яшь вакытларында күп хезмәтләр кыйлган хуҗасы Ивановка киткән иде. Иванов Идел (Волга) буенда саллар, баржалар йөртеп кәсеп кыйлдыкындан аңа һәрвакыт

кеше кирәк булып тора. Безнең Сабирҗан агай күп заманнар аңарга хезмәт иткән, яшь вакытларында сал илә ничә кәррәләр Әстерханга да төшкән иде. «Бинабәрин бу ел да бер хезмәт табып бирер әле, таныш кеше буш җибәрмәс», – дия. Идел буена барып, Ивановны күреп, яхшырак, җиңелрәк хезмәткә яллауны үтенде. Ләкин Иванов Сабирҗан агайның яшь чагында армый-талмый иткән хезмәтләрен һичбер уена китерми салкын гына рәвештә:

– Син бит, Вәлиев, хәзер бик картайгансың инде. Беләсең бит, монда хезмәт бик каты, яшь кешеләр дә бик газап илә генә хезмәт итәләр, – дия бераз тәкәллефләнгәч: –Яхшы инде, син әүвәлдән күргән кеше, буш җибәреп булмас, менә шунда баржалар тирәсендә генә хезмәт итәрсең, баржадагы иске арканнарны алып, турап сүтәрсең, һәркөн Иделнең аргы ягына чыгып, безнең баржалар тора торган җиргә фонарь кабызырсың, – дия, аена җиде сум хак куеп, баржа өстенә җәй өчен тактадан гына ясалган өйдә урын күрсәтте.

Андагы приказчик Сабирҗан агайга бер каек һәм башка лязим булган нәрсәләрне күрсәтеп, фонарь кабызуның тәртипләрен өйрәтте. Җәйнең көне су өстендә җылы, саф, матур. Сабирҗан агай июль, август числаларын бик рәхәт, тыныч хезмәт кыйлды. Бу ике айда өйдә калган угылы Җиһаншага: «Ничек тә имана җирләрен сачә күр», – дия, ун сум акча да җибәрде. Менә бервакыт җәйнең матур көннәре үтеп, сентябрь ахырлары җитеп, суык ягмурлар була башлады. Сабирҗан агай көн буе суык ягмур астында баржа тирәләрендә төрле хезмәтләрдә булып, икендеалды җитү илә берүзе каекка утырып, Иделнең аргы тарафына китә: бу вакытлар ямгурлы салкын җил илә Идел өстендә куәтле дулкын булдыкыннан каекны ишү, тугры алып бару бик авыр була, суык ямгур да өскә явып тора. Бу көннәр Сабирҗан агай өчен түзә алмаслык дәрәҗәдә кыен булдыктан, өенә кайтып китмәкче булса да, приказчик: «Хәзер Иванов өйдә юк, ул кайтмыйча бер хезмәтчегә дә расчёт биреп булмый, ничек булса да үктәбер кергәнче түзәрсең, – дигәч, чарасыз хезмәтендә дәвам кыйла иде. Берзаман үктәбер дә килеп җитте. Яз көн сайраша-сайраша көн яктан көтү-көтү булып килгән матур-матур кошлар, җиребездә кунак булып та яратмаган төсле, тезелешеп-тезелешеп кире көн якка китә башладылар. Һәр көн «кыйык-кыйык» дия кычкыра-кычкыра сызылып киткән киек казларның моңлы тавышын алтмыш бишкә җитмеш Сабирҗан агайны да өенә бик сагындырмыш, өендә калган угылы-кызларын, хосусан ачлыкта калмыш ике кечек баласын исенә төшереп, бик хафаландырмыш иде. Һәркөн приказчиктан: «Бай кайтмадымы, миңа акча кирәк иде, беләсең бит, бу ел ачлык, минем җәмәгатьләр ач тора торганнардыр, китәр идем инде», – дия сораса да, приказчик кайсы көнне: «Юк, тиздән кайтыр инде», – дия, вә кайсы көндә: «Бетмәс синең җәмәгатьләрең! Синең өчен байны чакырып кайтарыр хәлем юк», – дия җавап бирә иде.

Үктәбернең уннары үтте, көннәр һаман бозыла тора, бәгъзе көннәрдә яфрак-яфрак салкын, юеш карлар да ява. Безнең Сабирҗан агай көне буе, бу салкын көннәрдә эшләп, өсте-башы тәмам чыланып, кичен аны киптерергә җәйге тактадан гына ясалмыш өендә мич тә булмадыктан, бөтен тәне юеш кием илә өшеп, калтырап чыга иде. Шулай итеп, үзенә салкын тиеп бизгәк авыруына мөбталя булды. Көн дә бер-ике кәррә бизгәк тотып өши, калтырый, төнлә башы авыртып тәмам һушсыз булып ята иде. Мескен Сабирҗан агайның хәл-әхвален сораган кеше юк, моның хәлсезлегенә дә һичкем шәфкать итми. Приказчик иртүк керә дә, фонарьларны сүндерергә куша: «Аны эшләмәгәнсең, моны эшләмәгәнсең», – дип юк гаепләр табып сүгенеп йөри. Әмма уңган карт һич сер бирми, үзенең хезмәтендә асла кимчелек итми эшли иде. Чөнки бер көнгә эштән калса да, штраф та фәлән дия хакын басып каласылары Сабирҗан агайга күптән мәгълүм иде. Берзаман үктәбернең егермесе булды. При-

казчик иртә сәгать тугызларда Сабирҗан агай янына кереп, кенәгәсен суырып алды да, ачып караганнан соң башын боргалап: «Фонарь, аркан, ишкәк», – дия сөйләнеп, кызыл карандаш илә кенәгәгә сызгалап:

– Хәзер конторга бар, бай кайтты, расчёт алырсың, – диде.

Әмма Сабирҗан агайны бу көн авыру бик баскан, тәмам хәлсезләндергән иде. Мең бәла илә генә башын күтәреп, өстенә юеш бишмәтен киеп, акрын гына контор алдына барды. Анда күп хезмәткәрләр кенәгәләрен кулларына тотып, бүрекләрен тышта калдырып, яланбаш конторга керәләр дә, аз бер вакыттан соң, кайсы сүгенә-сүгенә чыга, кайсы: «Талыйсыз, күзегезгә керсен», – дия каргап, үртәлеп чыга иде. Бервакыт: «Вәлиев!» – дия Сабирҗан агайны да дәшеп алдылар. Сабирҗан агайга өч ай ярым хезмәт кыйлдыкы өчен мәҗмугы егерме дүрт сум илле тиен акча тиячәк улса да: «Бер ишкәк сынган икән – егерме биш тиен, фонарь капкачын төшергән – утыз биш тиен, аркан югалган – кырык тиен, янә кичә хезмәткә чыкмагансың – илле тиен», – дия бер сум илле тиен акчасын алып калып, әүвәлдә алганнарыннан калган җиде сум акча илә паспортын бирделәр. Сабирҗан агай бу нәрсәләрдән асла хәбәрем юк дисә дә: «Күп сөйләп торма монда. Шулай язылган, жалуниянңе алдың, моннан сыз тизрәк», – дия төрткәләп җибәрделәр. Сабирҗан агай йөткерә-йөткерә контордан чыкты да ерак бара алмады, бизгәге килеп, хәлсездән гаҗиз булып җиргә егылды. Берәр сәгать җирдә өшеп, калтырап яткач, приказчик килеп, аягы илә бәргәләп: «Тор, тор», – дия кычкырса да, Сабирҗан агай, торырлык хәле булмадыктан, бөкләнеп, аңгыраеп ята иде. Приказчик, моның хәле авыр икәнен белеп, ат илә якында булган урыс авылына больницага җибәрде.

II

Декабрь числасы керде. Көннәр ифрат суык. Һәркөн давыл да буран. Авыл халкында бу ел ягарга салам да юк, аз-маз акча илә алган утынны аз гына ягып, үлмәслек кенә итеп җылынып торалар иде. Крестьяннар өчен ашарга Управа тарафыннан бирелсә дә, авылларына китереп бирмиләр. Идел буенда булган пристаньнан яки вокзаллардан барып алырга кирәк. Бәгъзе авылларга пристань җитмеш-сиксәнчакрым ерак булдыкыннан, алар өчен мондый ерак җирдән азык ташуы бик читен иде. Халыкның үзе ач булдыкы кеби, хайваннары да ач иде. Ашамаган ат илә бер-ике көнлек юлдан иген ташый-ташый каюсы кулын өшетте, каюсы аягын, борынын, колагын өшетте. Хасилачлыктан хисапсыз җәза вә михнәтләр күрәләр иде. Бичара фәкыйрь ач халык алтмыш-җитмеш чакрым җирдән мең мәшәкать илә кормовой азык алып кайталар да аны үзара бүлеп, рәхәтләнеп кенә ашый алмыйлар, ул арыш әллә ничә куллардан үтәдер. Иң әүвәл пристаньнан үлчәп биргәндә дә халыкны үлчәү янына җибәрмиләр. Анда куелган кеше үзе теләгәнчә үлчәп бирә дә, йөкнең өстен ябарга да ирек бирми куа башлый, аз гына каршы сөйләсәң, стражник шундук тора. Хәзер килеп бүре үтерә торган камчы илә суга да башлый. Шәһәрдән алып кайткан арышны авылга җиткәч тә сельский староста каршы алып, җәмәгать амбарына бушатырга куша. Анда авылның картлары, куштаннары җыелып, бичара фәкыйрь мужикларның катып, йөз чакрымга якын җирне тездән кардан сөйрәтеп кайткан игеннәрне теләсәләр ничек үлчәп, егерме биш потны егерме дүрт потка калдырып, гөнаһсыз мужикны: «Син бер потны урлагансың, хыянәт кыйлып югалткансың», – дия өстенә бер сум язып, хезмәт хакын бирми калалар, үлчәүдән кысып, хыянәт итеп калган игенне авылның куштаннары үзара бүлеп ашыйлар. Авылда мондый хыянәтләрнең хисабы юк, аның барын да күреп тә, язып та бетерү мөмкин түгелдер.

Бу хыянәтләр бар да фәкыйрь мужиклар, тол хатыннар, юаш кешеләр башына

«Бичара фәкыйрь ач халык алтмыш-җитмеш чакрым җирдән мең мәшәкать илә кормовой азык алып кайталар да аны үзара бүлеп, рәхәтләнеп кенә ашый алмыйлар, ул арыш әллә ничә куллардан үтәдер...»

булалар, безем «Иске Т.» карьясендә дә картлар, куштаннар җыелып, Управа тарафыннан бирелмеш арышны бүлә башладылар. Җан башына утыз кадак арыш килсә дә: «Һәркемгә бүлә башлагач, аны чыгарыр хәл юк», – дия, авылның картлары җан башына бер кадак ким бирүне мәгъкулькүрделәр. «Чөнки аның түгелмәге-чәчелмәге бар», – дия сигез җанга алучының арыш сала торган башына сигез кадак гер куялар иде. Ләкин бу гер хаталык илә бер дә алынмый, ике җанга алучыларга да шөйлә сигез кадак ким бирелә бара. Фәкать тешлерәк кешегә туры килгәндә: «Һай, хата булган икән, онытылган», – дия сигез кадаклы герне алалар да, фәкыйрь вә юаш кешегә үлчәгәндә ике генә җанга булса да, янә сигез кадак «хаталык» илә куелып кала иде. Бичара юаш кешенең күбесе моны белми, белсә дә: «Йөзтүбән килсеннәр», – дия дәшмиләр иде. Безем Сабирҗан агайның ач балалары да, карга балалары кеби авызларын ачып, кормовой килгәнен көтеп торырга мәҗбүрләр иде.

III

Кечерәк кенә бер өйнең түрендә сәке өстенә алама тышлы түшәк җәеп, башына кызыл тышлы кечерәк мендәр салган, өстенә бик иске генә юрган ябынган ак сакаллы бер авыру карт сөйләнеп ятадыр:

– Хәлимә, кызым, самавырны куя башла инде, абыеңнар да кайтырлар. Беркөн бу вакытта кайтканнар иде бит. Ах... аһһ... ух, кызым, әнкәң өйдә юкмыни, Алла, Алла... ух, йөрәгем, аһ, эчем, – дия дә, башын түбән таба тотып, – аһ, аз гына җылы шулпа булса, шәт... – дия идәнгә куйган кечерәк савытка төкереп янә урынына ава – бу исә айдан артык больницада ятмыш безем Сабирҗан агай иде.

Сабирҗан агайны приказчик больницага җибәргәч, докторлар карадыктан соң,

сәламәтләнерлек түгел дия, дару гына биреп җибәрмәкче булсалар да, үзенең үтенүе буенча алып калып, бер айдан артык дәваладылар, ләкин файда булырлык булмагач, өенә җибәрмешләр иде.

Өйнең уң тарафында такталар илә ясаган бүлмә булып, бүлмәнең ишегенә алача чаршау корылган иде. Шул бүлмәдән ундүрт-унбиш яшьлек ак чырайлы, кара кашлы, кара күзле, өстенә искерәк күлмәк кигән бер кыз чыкты да мичнең бер тарафына ясалган куыштан чыра алып, калай самавырга су салып, ут кабызып куйды.

Берәр минутлардан соң ишектән өстенә искерәк бишмәт кигән, ертык шәл ябынган, бишмәт чабуының астына горда кеби каты, кап-кара ярты икмәк кыстырган Сабирҗан агайның хатыны Сылубикә абыстай килеп керде дә, самавырга күзе төшеп:

– И-и, кызым, самавырны куйдыңмыни, бик яхшы, күп кеше кайта башлады инде, абыеңнар да кайтырлар, – дия, икмәкне югары киштәгә куеп, Сабирҗан агайның янына барып утырды.

Аның аяк очына утырган бере сигез, бере алты яшьләрдә булган балалар икмәкне күрү иләаналарына карап, кулларын икмәккә таба сузып: «Әни, ипи...» – дия кычкырырга тотындылар.

Сылубикә:

– Сабыр итегез, балалар, сабыр итегез, хәзер (Җиһанша) кайтыр, чәй эчәрбез, шунда ашарсыз. Аллаһ теләсә, инде числа башы да озак түгел, менә арыш бүләләр, туйганчы ашарсыз, – диде.

Ул елларда хөкүмәт тарафыннан бирелгән кормовойны «первый числада» бүлдекләреннән, һәрбер бала-чага, хәтта һич дөнья күрмәгән карт-карчыклар да «декабрь, гыйнвар» дия числаларны санап, «первый числа»ны бәйрәм көткән кеби көтеп торалар иде.

Сабирҗан агай, җаныннан артык күргән балаларының ачлыктан еглашып кычкырыштыклары күзен ачып карады да, башын күтәреп:

– Аһ... Сылубикә, кая бардың? Җиһаншалар кайтмыйлармы? – диде.

Сылубикә:

– Күрше Гөлҗамалларга кердем, бурычка бер икмәк сорадым да, үзләренә дә юк икән, алар да арыш кайтканны көтәләр, алабута илә кушып салалар икән, көчкә ярты икмәк алдым. Хәзер Җиһанша кайтса, бернәрсә дә юк ашарга, туңып кайтыр, мескен, беркөн орлык алырга барганда да ягмурда туңып үлә язган иде. Бу көн бигрәк суык, күршедән кергәнче дә үлә яздым, ничек кенә кайтырлар инде, ичмаса чикмәне дә юк. И бу фәкыйрьлек авыр ла, илаһи, үзең ярдәм бир, – дия Сабирҗан агайның янына барып, башын тотып. – Бу көн башың суына төшкән, хәлең ничек, бераз икмәк капмыйсыңмы, су кирәкмиме? – дия янына утырды.

Сабирҗан агай күзләрен ачып, зур-зур итеп тутырып карады да, бер сүз әйтмәкче булып:

– Аһ, уһ... и кайнар... – дия кулын селтәде. – Юк, бетте хәл, – дия янә юрганын ябынып ятты.

Ул арада ишектән өстенә искерәк кара бишмәт киеп, билен буган, муенына иске шарф ураган, башы-аягы карга буялган, мыегына тәмам боз каткан, гаять туңган бер егет кайтып керде дә:

– Алла, туңдым... үлә яздым, – дия, кулыннан бияләйләрен чыгарып идәнгә ташлап, аякларын берсен берсенә бәреп, мич янына таба барып, кулларын мичкә куеп: – Әти нишләп ята, бик начарланмадымы? – дия сорашырга тотынды.

Сабирҗан агай моның тавышын ишетеп, юрганын күтәреп:

– Ах, уһ... Җиһанша, синме, угылым, сау кайттыңмы, атың бик җөдәмәдеме? Аһ,

хәлем агыр, агыр, уф... Бар да шул ачлык, ачлык галәмәте, – дия күзләрен йомып янә урынына ятты.

Җиһанша атасының ачлыктан вә хәлсезлектән саргаеп киткән йөзенә карап, күзләреннән яшь агызып:

– Шөкер, әткәй, кайттык, ләкин юл бик авыр булды, шәһәрдән чыкканлы бирлебер ултырмай җәяүкайттым, кичә көн буе буран булды, салкын җил, атлар да хәл юк, харап булдык, – диде.

Хәлимә җәймәләр җәеп, самавырны китереп куйды, һәр каюсы чәй янына утырып, күршедән алып кергән кара икмәкне кисеп ашый башладылар. Җиһанша көннең суыклыгыннан, буран вә көннең авырлыгыннан зарландыкында, Сылубикә абыстай да угланнарының ачлыктан еглашдыкларыннан, икмәк юклыктан зарлана иде. Һәм үзләре алып кайткан арышны үзләренә бүләргә ихтыяр бирми, җәмәгать амбарына салып, аннан куштаннар үтә генә алырга булдыкыннан, куштаннар истәгән кешеләренә биреп, истәмәгән кешеләренә бирмәскә ихтыярлы булдыкларыннан күп кешенең, хосусан үзләренең җитмешкә якынламыш аталарына да «работниктан» чыкмаган дия, кормовой бирми җәбер күрдекләрен сөйләшеп чәй эчәләр иде.

Безем татарлар: «Берәү үлми, берәү көн күрми», – диләр. Бер кешенең башына төшкән бәла вә хәсрәт икенче берәүгә бик зур шатлык вә файда буладыр. Мондый ачлык еллар фәкыйрь халык өчен нә кадәр авыр, хәсрәт булса да, куштаннарга моннан асла зарар юк, бәлки алар бик күп файдалар итеп калалар. Чөнки ярлы кешегә кая барса да бурычка бирүче юк, ярдәм вә шәфкать юк. Ачлыктан үлем хәленә килгәч, чарасыз, җаны кеби күргән атын, сыерын сата башлый, моның илә генә җиткезеп булмагач, үзенең тереклегенә, дөньяда торуына сәбәпче булган актык җирен сатарга тотына. Мондый елларны дүрт күз илә көтеп торучы, халык кырылып бетсә дә үз тамагын туйдыруны, корсагын күпертүне, кеше җилкәсен кимерүне теләп торучылар бичара фәкыйрь халыкның унбиш-егерме сумлык җирләрен биш-алты сумга алып, үзләренең Мәскәүдән бурычка алган черек такта чәйләрен ике-өч хакка сатып, бурычка өләшергә тотыналар. Мондый кеше талаучы байгуралар куштаннарны көйләп, фәкыйрьләрне алдап, бер сумны өч сумга әйләндереп, фәкыйрь мескеннәрнең өстендәге киемнәренә кадәр суеп алып, биш сумга җирләрен алып та, егерме сумга үзләренә сатып, хасил кулларыннан килгәнчә алдап, талап, тереләй тунап, хәрам вә хәләлне тикшерми, кеше хакын җыеп байыйлар да, һич оялмый: «Без суфилык илә баедык, без мөрид, бездә фатыйха бар, ишан хәзрәт һаман безгә дога кыйлып тора, без хәер-дога аркасында баедык», – дия мактанырга тотыналар.

Бервакытлар болар инсафсызлыкның чигенә җитеп, хәтта хөкүмәткә дә юл бирми, фәкыйрь халыкның иманасын,түләү салырлык та җирен калдырмый юк бәһасенә алып бетерәләр иде. Ләкин хөкүмәт боларның комсызлыкларын сизеп, иманасы салынмаган җирләрне сатмаганга хисап кыйлдыкыннан, хәзер байгуралар җир ала башласалар, әүвәл иманасын түләп, хөкүмәттән бәхиллек алалар... Шулай итеп карьяләрдә бер ел ачлык булса, мескен фәкыйрьләргә дүрт-биш елга җирләре сатылып, алдагы еллар өчен янә фәкыйрьләнеп куялар. Шуның өчен бер ел иген булмаса, дүрт-биш елга кадәр халык җан алалмый торадыр. Бинабәрин Россиядә фәкыйрьлек елдан-ел арта барадыр. Моның өчен күп кайгырган кеше юк. Байгуралар булса, халыкның фәкыйрьлегеннән файда күргәнгә күрә, ачлык елларны теләп кенә торып, фәкыйрь халык мохтаҗ булып каршыларына килгәндә кытыр-кытыр көлеп кенә торалар. Муллалар, хәзрәтләр булса, халыктан бигрәк үзләрен кайгырттыкларыннан, халык кайгысы – соңыннан гына. Хосусан ишан хәзрәтләре: «Дөнья малы – дуңгыз каны, бу дөньяда файда юк, бигрәк ахирәт өчен тырышыңыз, дөнья үтәр дә

«Сабирҗан агайның да йорты иң читтә, тау башында, олуг юлның читендә генә, бик тәбәнәк, салам башлы, кечек тәрәзәле...»

китәр, сезгә ахирәттә күз күрмәгән, колак ишетмәгән дәүләтләр бар», – дия халыкның фәкыйрьләнүенә, көн би көн мохтаҗ вә хур булып калуларына гына хезмәт итәләр. Алар игътикадынча, тиз-тиз үләргә дә, оҗмахка кереп, хур кызларын бүләргә...

Көннәр һаман үтеп тора, ачлык та көннән-көн арта бара, халык сәгать би сәгать йөдәмәктә, ачыкмакта, аптырамакта, суыктан, азыксызлыктан гаҗиз булмакта иде. Ачлык арткан саен халыкның куәтләре китеп, йөзләре саргаеп, кул-аяк тетрәү, әгъза калтырау, күз тону, йөрәк сикерүләр була башлады. Менә бервакыт халык арасында төрле-төрле авырулар заһир булды. Ирен, авыз шешү, аяк авырту, зәңгелә авырулары була башлады. Һәрвакыт халыкны тикшереп торучы земский начальниклар, халык арасында мондый авыруларны күргәч, авылларга докторлар җибәрделәр. Табибларның тәфтише илә бу авырулар ачлыктан, һич ит вә кайнар аш капмаудан идеке мәгълүм булды. Бинабәрин шәфкать «Красный Крест» җәмгыяте күп авылларга столоваялар (ашханәләр) ачачак булып агентлар (вәкилләр) җибәрделәр. Бу агентлар бәгъзе авылга йөз кешелек, каюсына йөздән артык вә ике йөз кешелек ашханәләр ачып, җан башына биш тиен расхуд илә көн дә бер кайнар аш ашатуны халыкка игълан кыйлдылар. Җәмгыять тарафыннан фәкыйрьләр ашатыр өчен җибәрелмеш акчаны тотар өчен столоваяларга хуҗалык итәргә һәм шунда хезмәт итәргә эшчеләр, кешеләр кирәк булды. Әлбәттә, авылларда иң инабәтле кешеләр – имам вә хәзрәтләрдер. Шуның өчен дә: «Алтын тотарга без мөстәхикъ», – дия, хәзрәтләр ашханә идарәсен үз кулларына алдылар. Ай саен капчык-капчык ярма, йөк-йөк ит, май, күп акча китерәләр дә озын куллы хәзрәтләргә тапшыралар.

Йөзе кара булсын дөньядыр бу... Гомерләрендә аркылыны буйга алып салмаган, үз ашын да кешедән пешертеп, мужикларның түрендә түшәк-ястык өстенә утырып, май-каймакларның да тәмлесен генә ашап, алтын-көмеш, мәрҗән баулар гына бәйләп йөргән ак куллары илә тәрбиядә торучы остазбикәләр «Салибе Әхмәр» ашханәләренә аш пешерүче, хөрмәтле муллалар кашавар булуны илтизам кыйл-

дылар. Бу ашханәләрдә ашарга кемнәр мөстәхикъ вә кемнәр тиеш түгел идеке дә хәзрәтләргә тапшырдыкыннан, бичара ач мужиклар хәзрәт янына йөгереп: «Зинһар, дамелла, мине дә язсана, минем балаларымны да мәхрүм калдырмасана, ачлыктан үләбез, һич кайнар аш капканыбыз юк, Алла хакына безне дә ашханәгә кабул итә күр», – дия ялына вә ялвара башладылар. Муллалар да мондый форсатны ганимәт күреп: «Мужикны очраганда кара», – дия. «Дөнья шулай бит ул, муллаларга да ялынырга калдыра, бай вакытыгызда үз муллагызны танымый, ят муллаларны ашка дәшеп, нәзер-ниязларыгыз булса, читкә илтеп бирәсез. Син әле фитырда бирмәгән идең бугай?! Яхшы, карап карарбыз, менә тәфтиш итәрмен, ничек булыр», – дия, бик суфи сымак башны аска бөгеп, борын үтә генә бик тәкәллефләнеп, озын мәгънәле кыска гына сүзләр илә мужикларга максудларын аңлата башладылар.Бичара ач халык кая барсын, ул бу көн мулла вә куштаннарның тасдыйгына (удостоверениеләренә) калган, ничек тә фәкыйрьлеген исбат итеп, ашханәгә язылырга кирәк. Моның өчен мулланың хәтерен табу лязем. Шуның өчен һәркөн мулланың ишек төбендә кызыл тышлы түшәк салган чана тора. Актык тавыкны, каз-үрдәкне суеп булса да абыстай илә мулланы алып китеп ашаталар, Коръән укытып, изүдән иске тәңкәләрне кисеп сәдака бирәләр, фатиха алалар иде. Ни кыйлмак кирәк, ач кешегә көн дә бер аш кабуы да бик зур дәүләт.

Һәр ни халык ашханәгә язылды. Мулланың кухнясында казан-казан өйрә пешә, фәкыйрь халык, хатын-кыз бала-чагаларны күтәреп, кашык тотып, тездән карга буталып ашханәгә йөри башладылар. Мулланың таналары, үгез вә сарыклары да симез күренеп, кыйммәт хак илә ашханәгә сатылып суелды. Амбар тулы ит, ярма, май. Кухняда он, тоз мул, күп-күп икмәк туралып, идән ипи валчыгы илә тула, түгелә, чәчелә, – ләкин болар бер дә зайг булмый, хәзрәтнең чебеш вә тавыклары шундук йөриләр. Сыер вә бозауның да авызы камырлы. Түгелгән, чәчелгәннәрне ашый-ялый, туя-симерә, һәр нә – бөркет... Нишләмәк кирәк, аяк астына тузылгач, себереп чыгарыр хәл юк, исраф хәрам ич... «Берәү үлми, берәү көн күрми», – дидек. Халык ач булса-булсын – муллаларның үзләре генә түгел, сыер вә бозаулары да тук, кош-кортлары да симез. «Красный Крест» җәмгыяте бай, акча һаман килеп тора. Хәзрәтләр яшел тышлы дәфтәргә расходны яза баралар, хисапка да бик остарып киттеләр, агентларга отчетны биреп торалар. Никадәр азык, никадәр акча тузса да аяучы юк, һич бетми, һаман килә дә килә. Нә кадәр һимммәтледер бу «Красный Крест» җәмгыяте...

Әүвәлдә: «Ысулы җәдид илә укыту хәрәм, анларның кара такталары бик хәвефле... Алла сакласын, аның эчендә тавык аягы бар, имеш. Аларның мөгаллимнәре «Красный Крест»тан жалунья алалар, безем мөселманга жалунья алу асла дөрес түгел, харап, харап, аннан ерак булырга кирәк, сакланырга тиеш, аны кабул итәргә ярамас», – диюче карт хәзрәтләр, һәр көн өйрә ашатканда «Красный Крест» җәмгыятенә озын гомер, бөек дәүләт теләп хәер-дога кыйлалар. Хәтта күселәр кеби «Красный Крест»ның читен кимерергә риза булдылар. Һич гаеп юк, дөньядыр бу...

Безем «Иске Т.» карьясендә дә шундый ашханәләр ачылды. Анда ашаучы күп халык арасында Сабирҗан агайның да ике кечек баласы илә Сылубикә абыстай бар иде. Авылларда фәкыйрь халыклар мәсҗедтән ерак, карьянең читенә – ындырлар янына, кыш көне тау-тау кар өелә торган җирдә улдыкларыннан, Сабирҗан агайның да йорты иң читтә, тау башында, олуг юлның читендә генә, бик тәбәнәк, салам башлы, кечек тәрәзәле, йорт тирәсенә кура гына тоткан булып, салкын ачы буран бөтен кырдагы карларны боларның ишегалдына китереп өйгән, өй тирәсенә Каф таулары кеби сырлап-сырлап кар тавы ясаган иде. Мескинә Сылубикә абыстай һәркөн шул кар тавы арасыннан угланнарның кечерәген күтәреп, зурысын җитәкләп, ачы суык

буранлы көннәрдә тишек оек илә бер-ике йөз сажин кадәр җиргә – мулла йортына өйрә ашарга бармакта иде. Хәлсез кешегә балалар илә тиз генә йөрер хәл юк. Хосусән кечек баланың авыруы сәбәпле, күп вакыт урамда өшеп, туңып, хәл җыеп торырга туры килә иде. Шулай итеп Сылубикә абыстайның бер угылына бик каты салкын тиеп авырып, аяктан егылып калды. Соңрак Сылубикә абыстай үзе дә күп кешене ега торган аяк авыруы, зәңгеләавыруына мөбталя булып, ашханәгә дә йөри алмаслык булып егылып ята башлады. Әүвәлдә Сабирҗан агайның авыруы илә дә тәмам гаҗиз булганнар иде: хәзер бер йортта өч авыру булды. Сабирҗан агайның җаныннан якын күргән кечек угылы берәр җомга бик каты косып, йөткереп, аяк шешеп газапланып яткач, вафат булды. Моның бөйлә ачлыктан төрле авыруларга мөбталя булып, газапланып үлдекеннән Сабирҗан агай бик әсәрләнеп, гаять кайгырып, үзенең әлеге авырулары өстенә янә йөрәк авыруы да хасил булып, ахыр сулышка килде.

IV

Гыйнварның егерме җиденче көне гаять суык-салкын, бик каты җил вә буран иде. Сабирҗан агайның өендә Сылубикә абыстай акрынлык илә генә йөри башласа да, иренең бик агыр хәлгә килдекеннән, моның өстенә күз нуры булган баласының да ачлык бәласе илә вафат булдыкыннан ифрат хәсрәтләнеп, тәмам урталай бөкрәйгән, бик хәлсезләнгән, ачлык илә йөзе саргайган; түр башына мендәр салып, ахыр сулышларга килгән картының баш тугрысында, калайлаган чәйнек илә су тотып, еглаган кеби күңелсез генә утырмакта иде. Сабирҗан агайның аяк очында кызы Хәлимә илә кечек угылы аталарының күкрәге күтәрелеп, күзләрен йомып, озын-озын гына бик агырлык илә суладыкына гаҗәпләнеп карап торалар иде.

Берәр дәкыйка узгач, ишек ачылып, ишектән аркасына капчык илә арыш күтәргән Җиһанша килеп керде дә, арышны мич башына куеп:

– Уф, Алла! Көтә-көтә тәмам гаҗиз булдым, бирмиләр дә бирмиләр, байлар да куштаннар алып бетермичә безнең кебекләргә чират юк, йөзләре кара булсын инде... Сельский вахтердыр – бар да исерек. Арыш саталар да эчәләр. Бер сүз әйтер хәл юк – сүгенәләр. Әле кесәмдә ун тиен акчам бар иде, шуны старостага биреп, көчкә үлчәтеп алдым. Биш-алты кадак ким дә бирделәр ахры, йөзләре кара булсын инде, – дия атасы янына барып утырды.

Җиһаншаның тавышына Сабирҗан агай йокыдан уянган кеше кеби күзләрен ачып, гаять әсәрле карау илә аяк очына утырган кечек балага күзләрен тутырып-тутырып карагач, берәр сүз әйтмәкче булып аңгыранса да, теле бәйләнеп әйтә алмый, кулы илә ишарәт итеп су сорадыкыны аңлатты. Сылубикә аз гына су салган иде, авыруның күзләре агарып калайланып, күкрәге күтәрелеп, кайгылы вә хәсрәтле булган иң соңгы сулышларын сулый башлап, дөнья илә сәламләшүләрен, балаларыннан кыяматкә кадәр аерылачагын аңлата торган нәфесләрен ала башлады.

Сылубикә абыстай бу хәлне күреп, куркынычлы тавыш илә:

– Җиһанша! Атаң үлә! Тиз мулла абзаңны алып кил, тиз, тиз... – дия кычкырды.

Җиһанша бүреген чөйдән алды да, башына кимичә үк ишектән чыгып йөгерә башлады. Сылубикә абыстай аяк өстенә торып:

– И Алла, и бәхетсез башым, и бу ачлык, и бу фәкыйрьлек... Кемнәрнең башына җитмәде, Ходаем... Үләргә булган икән, туйганчы икмәк тә ашый алмады, итле шулпа дия ничә көн тилмерде мескен... И Алла, үкенечтә үләдер лә бичара. Шул угланнар өчен ачлыктан, суыклыктан авырды. (Авыруга карап.) И Алла, ахыр сулышка җитте, үлә икән, үлә! Балалар ятим кала икән, и Ходаем, уф, уһ, уһ! – дия кычкырып егларга тотынды.

«Явыз ачлык Сабирҗан агайның балаларын атадан ятим калдырдыкы кеби, көн дә бер чынаяк булса да сөт кабуларыннан да мәхрүм калдырды...»

Бу хәлдән Хәлимә илә кечек бала да куркып еглашырга тотындылар...

Аз бервакыттан соң ишектән Җиһанша кереп:

– Әни, китегез, мулла абзый килде, – диде.

Сылубикә, Хәлимә кечек угланны алып бүлмәгә киттеләр, мулла утырыр өчен авыру янына бер мендәр салып калдырдылар.

Ишектән башына керләнеп беткән, саргайган ак чалма, өстенә кызыл тышлы, ак сарык тиресеннән ясалган искерәк толып кигән, кулына озын яшел таяк тоткан мулла, аягындагы ак киез калушлары илә шакыр-шокыр килеп керде дә, мәгълүм мендәргә утырып:

– Сабирҗан агай, Сабирҗан агай, иман ит, Алла, Алла, – дия тәлкыйнь итеп ясин укырга тотынды.

Ләкин күп укый алмады, Сабирҗан агай балаларны ачлыкта ятим калдырып, дөньядан кул селтәде – үлде, җан бирде. Мулла укудан тукталып:

– Аһ... Алланың рәхмәтендә улсын, яхшы кеше иде, үлде, – дия түр башында элеп куйган сөлгене алып, мәетнең битенә ябып куйды.

Җиһанша илә Сылубикә һәр икесе еглаган тавыш белән:

– Үлдемени, и Алла, и Алла! – дия кычкырыша башладылар.

Мулла:

– Чү, чү, сабыр итеңез, сабыр, сабыр... Еглау ярамас... – Җиһаншага карап. – Йә, атаңны ничек күмәсең, нәрсәсе бар фидиягә, Коръәнгә ни бирәсең, үлгән артыннан үлеп булмас. Бар, мәзинне дәшеп кил, фидиягә ни алыр – сөйләшербез, кабер дә казырга кирәк булыр. Инде монда син хуҗа булдың, атаңны рәнҗетмәскә тырыш, аның бу көн ахыр туе, – диде.

Хәлимә мәзинне дәшәргә чыгып китте. Мәетне яхшылап сузып салдылар. Сылубикә битен тотып кына муллага карап:

– Зинһар инде, мулла абзый, ризалык илә генә күмә күр. Бернәрсә дә юк бит, беләсез, өстенә өләшергә дә урак алмакчы булабыз, – диде.

Мулла каш вә күзләрен чытып:

– Шулай инде, бу ел юклыгы мәгълүм... Әмма атагызны да буш чыгарырга ярамый. Ул инде хәзер сездән сәдака, ихсан гына көтә, ул сезнең кулга калган, сез инде юктан кызганмагыз – көн дә, көн дә үлмәс. Ни булса да бирегез, туны, толыбы бардыр... – диде.

Җиһанша башын аска салып «уф!...» дия, озын гына сулап алды:

– Мулла абзый, туны булса да, бик начар. Ул да хәзер үзебездә түгел. Садыйк абзыйлардан бер пот он алган идек тә, шунда куйдык. Менә, риза булсаң, хәзер кормовойга алган ике пот ярым арышыбыз бар, шуны бирербез, – дидекендә ишектән сәләмә толыплар кигән мәзин килеп кереп, идәнгә тезләнеп утырды.

Мулла мәзингә карап:

– Менә, мәзин, Сабирҗан агай вафат, – дигәч, мәзин бик сузып кына, аяган, кайгырган булып:

– И-и... вафатмыни? – дия «калә иннә лиллаһи ... илх » әйтеп, дога кыйла башлады.

Мулла:

– Ул инде, Алланың рәхмәтендә булсын, үлде, ясин, фидиягә ни алырсың? Буенда мәрхүм яшь кеше түгел иде, җитмешкә якынлаган булыр. Җитмештә булса, хуш... Уникене ташласак, илле җиде каламыни... Ә юк, илле сигез кала торгандыр. Шулай, шулай, илле сигез кала. Ягъни мәсәлән, Сабирҗан агайның илле сигез ел калмыш намаз, руза һәм бирмәгән фитыр, гошерләренең, фидиясенең искатын, ягъни шуның гөнаһысын мәзин син күтәрерсеңме? – дидекендә, мәзин:

– Яхшы, хәзрәт, ярый, безне бәхилләтсәләр, күтәрербез инде, – диде.

Мулла Җиһаншага карап:

– Йә, кая тиз бул, ни бирәсең фидиягә, атаң яшь кеше түгел бит, җитмеш еллык калган намазларга... Тиз бул, тиз, мәзинне ризаландыр, – дигәч, Җиһанша ихлас күңел илә:

– Ышансагыз, хәзрәт, бернәрсәбез дә юк хәзер бирергә. Менә бер дисәтинә уҗымыбыз бар. Шуннан алты сажин уҗым бирербез, Алла боерса, мәзин бабай үзе эстәгән җиреннән урып алыр, – дигәч, мулла:

– Ул гына бик аз була бит, хәзер бернәрсә дә булмагач, һич булмаганда, ястыкфәлән юкмы? – дидекендә, Сылубикә абыстай бүлмәдән чыгып:

– Әнә, башындагы кызыл тышлы мендәрне дә бирербез. Яхшы мамык мендәр иде, – диде.

Мулла, мәзингә карап:

– Ярармы, мәзин, шуңа риза буламсың? – дип сорады.

Мәзин авырсынып кына:

– Нишләмә келисең, булмагач, аз булса да риза инде, – диде.

Мулла:

– Соң миңа нәрсә бирәсез, мине бит мәхрүм калдырырга ярамый. Без инде шунда да алмагач, ач үликмени... һичбер сәдака юк, ихсан юк, дәшү юк, ашату юк, бер бөртек гошер бирмәдегез! – дия гайрәтләнеп киткәч, Җиһанша:

– Хәзрәт, үзең беләсең бит, бу ел нәрсәдән гошер бирик, һичнәрсә булмады ич, булса бирер идек, – диде.

Мулла:

– Бирсәгез, табар идегез лә, бирмисез. Миңа бит подакаулап бәрәңге, табаклап он яки питрач булса да ярый. Мондый елларда мин үзем дә күп сорамыйм, – дидекендә, Җиһанша башын күтәреп:

– Хәзрәт, без бит питрач кебиләрне сукыр карчыкларга, тол хатыннарга бирәбез. Син бит, Аллага шөкер, гарип карчык түгел, икмәк кырындыгына калмагансың, – дигәч, мулланың күзләре кызарып китеп:

– Юкны лыгырдап торма, каршы сөйләп. Атаң мәрхүм дә каршы әйтә торган иде. Күп вакыт фитыр бирмәде. Бир тиз бернәрсә, вә илля үч... – дия башлаган иде, Җиһанша:

– Фитырныбит, мулла абзый, байларга бирергә ярамый. Бирсәң дә, фитырдан китми – яңадан бирелергә тиеш. Ул фәкыйрь-мескеннәр хакы дия, шәкертләр әйтәләр. Без шуның өчен фәкыйрь кардәшләребезгә бирдек, – дигән иде, мулланың күзләре тузып, борыны кызарып:

– Лыгырдап торма, хайван, мин белмиммени кемгә тиеш икәнен! Ахмак, яшь кенә башыгыз илә күп сөйлисез, – дия гайрәт ора башлагач, Сылубикә абыстай:

– Шаулама, Җиһанша, бир мулла абзыйның сораганын, бир, зинһар, әллә кайда каргар-нитәр, харап булырбыз, – диде.

Мулла:

– Каргамый сезне әллә нишләрсең, җитмешкә җиткән атагызга бер Коръән дә чыгартасыгыз килми, ахмак, хайван, яшь башы илә әлләниләр сөйләп тора тагын, тиресдога кыйлсам, җәһәннәм төбенә китәрсең, бир әнә кәҗәгезне, вә илля каргыйм, атагыз да догасыз китәр, сез дә харап булырсыз. Бөтен Коръән чыгарга кәҗә түгел, сыгыр да аз да, ярый инде, юк дисез... Барына канәгать итәргә кирәк, бир кәҗәне, хәер-дога кылам, – дигәч, Сылубикә илә Җиһанша, аптырап калып:

– Ярый алайса, хәзрәт, кәҗә сезгә булыр инде. Хәзер үк илтикме соң? – диделәр.

Мулла:

– Хәзер, хәзер илтәсез. Мин кат-кат йөри алмыйм. Кәҗәне илт тә, кабер казый башларсыз, – диде.

Җиһанша бер җеп илә кәҗәнең муеныннан бәйләп, ишеккә таба сөйрәп килеп:

– Әнә, мәзин бабай, мендәр сиңа – әтинең башында, ал, – дигәч, мәзин кара төлке тоткан кеби куанып, «бисмилла» дия үлекнең башыннан кызыл тышлы мендәрне тартып алып, куенына кыстырды.

Мулла да кәефен бераз төзәтеп, «үлмәгәең, бет!» дигән төсле шат йөз илә:

– Аллаһ әкбәр, хуш, сау буласыз, Алла иманын юлдаш кыйлсын. Тизрәк кабер казырга кирәк, гүр сәдакасына бер тавык илтерсез анда, – дия башын бөгеп ишектән чыкты.

Мәзин дә мендәрне култык астына кыстырып, мулла артыннан китте. Җиһанша кәҗәне сөйрәп, акырта-акырта чыга башлагач, мескен кечек бала кәҗә тавышыннан калтырап китеп, яшьле күзләре илә бер кәҗәгә, бер анасына карап кычкырып егларга тотынды.

Явыз ачлык Сабирҗан агайның балаларын атадан ятим калдырдыкы кеби, көн дә бер чынаяк булса да сөт кабуларыннан да мәхрүм калдырды...

Соң.

Текстны басмага филология фәннәре докторы
***Фәрит Бәшир** (1958-2009) әзерләде.* ■

Нурлы сәхнәдә иҗат нуры

Әхтәм Зарипов

«Безнең мирас» журналы редакциясеннән Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Дания Нурлы (мулла кушкан исеме Фидания Нуруллина) хакында аның юбилее уңаеннан иҗади эшчәнлегенә кагылышлы язма фикеремне сорагач, мин: «Дания турында фикер аның исем-фамилиясенә үк салынган», – дидем, алдан уйлап куйгандай.

– Сез аның белән спектакльләрдә уйнаган артист, тавышын беренче булып эфирда яңгыраткан, үзен телевизион фильм-спектакльләрдә күрсәткән режиссёр буларак, сөекле артисткабызның иҗади үзенчәлекләре турында укучыларыбызга ирештерәсе иде.

– Мин шул «Нурлы» дигән псевдонимга кушылып, «бик дөрес» дип кенә әйтә алам. Нурның яктылыктан икәнен беләбез: ул төрле төсләр көлтәсе (спектр, диләр). Дания нинди генә рольдә уйнаса да – уңай холыклынымы, тискәре холыклы кешенеме – ул чыгуга сәхнәне нур балкыта, актрисаның рухи байлыгыннан аңкыган бу нурлар көлтәсе тамашачыны үзенә җәлеп итә. Дания спектакльдә уйнамый – ул яши. Яшәве белән һәр образын оригиналь холыклы кеше итеп тасвирлауга ирешә.

Яңгыр тамчылары аша узгач, кояш нуры «салават күпере» булып күренүен беләбез. Даниянең сәхнәдән сипкән нуры башкаларда ничек чагылса, миңа да шулай тәэсир итә: яктырта да, җылыта да.

– Бу сезнең аны яратудан гына түгелме?

– Татар Академия театры тамашачылары арасында бу артистның уенына сокланмаганы, хатын-кызларның аңа үрнәк итеп карамаганы, ир-егетләрнең гашыйк булмаганы, ымсынмаганы юктыр... Бигрәк тә, бердәнбер кызы Айсылуның фаҗигале үлемгә дучар булганчы сәхнәдән нур сипкән чакларында.

– Хәзер нур сипмиме?

– Аның хәлендә калган Анадан нур уйнатуын көтү гөнаһ булса да, әйтим: Дания, чын артист булганлыгыннан, көттерми – нурсибәр булып яшәвен дәвам итә. Моңа аның соңгы ике спектакльдәге рольләре генә дә дәлил. Иҗаттан җылылык ала ул, шул аның хәсрәтләрен каплагандай итә, яктырта, нурландыра...

Редактор белән шулай башланып киткән сөйләшү телефонның акчасы беткәнче дәвам итте.

Акча бетте, сүз бетмәде...

...Чорыбызның сәхнә йолдызы булып балкыган бу актрисаның иҗат юлы асфальт түшәлгән туры юл гына түгел.

50 елдан арткан сәхнә тормышында, 50 дән артык роль уйнап, 50 төрле образ тудырып, ул образларның һәркайсы безнең күңелләрдә яши икән – болар актрисаның иҗади үсеш баскычлары дигән сүздер. Баскыч яки күтәрмә...

Ул баскычтагы бер басманы гына куптарып алу да, аны өзекле итә. Чөнки аларның һәркайсы Даниянең осталыктан осталыкка күтәрелү шаһитлары.

Ул уйнаган рольләрнең һәркайсы хәтерләрдә калырлык һәм театр куйган таләпләрне дә, тамашачылар зәвыгын да канәгатьләндергән иҗади хезмәт җимешләре. Аларда Даниянең өмет-хыяллары, кайгы-хәсрәтләре, югалту-табышлары чагылыш тапкан.

Мин Дания башкарган рольләрнең берсен дә «әйбәт яки начар булды», «охшады-охшамады» үлчәме белән үлчәмәс идем. Эшләгән эш, тәкъдим ителеп, кире кагылмаган икән, димәк ул тамашачыга кирәкле үз урынын тапкан. «Эшеңнең кемгәдер кирәкле булуын тоеп иҗат итү – бәхетнең нигезедер», – ди Дания ханым, «Иҗатыңнан үзең канәгатьме?» – дигән сорауга җавап биреп. Мин дә шуңа кушылам.

«Бу спектакльдә Дания уены канәгатьләндермәде» дигән очракны мин хәтерләмим. Чөнки андый хәлнең булганы юк. Киресенчә, үтемсезрәк спектакль үтемле булсын өчен, җай чыгарып, анда Даниягә «роль» тапкан очракларны хәтерлим. (Әзәрбайҗанчадан тәрҗемә – «Айдын» спектаклендәге биюче кыз, «Фатыйма Сабри»дагы Кәнизәк рольләре, мәсәлән, шундыйлардан иде. Ул биегәндә аны күрер өчен сәхнә артына җыела идек.)

Дания ханымны мин аның студент елларыннан, Фидания чагыннан алып беләм.

Ширъяздан ага Сарымсаков Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясен сәхнәләштергәндә, Шәфәкъ роленә училищеның башлангыч курсында гына укып йөргән ике кызны чакыра. Бу факт үзе генә дә театр дөньясында сенсация буларак кабул ителә. Рольгә тилмергән эшсез артисткаларга чәйнәшергә азык була.

«Ничек инде без рольсез йөргәндә, студенткаларга шундый җаваплы роль?» – диләр исемле артисткалар.

Тик приказны үзгәрттерә алмыйлар. Фидания Нуруллина һәм... икенчесенең исемен хәтерләмим – ике-өч репетициядә генә утырды да, югалды ул. (Соңыннан ишетеп белүемчә, каты авырып, психбольницага эләккән, шунда үзен «мин Шәфәкъ» дип саташкан, имеш.) Ә Фидания Нуруллина – «Ай тотылган төндә» спектаклендә Шәфәкъ ролен уйнап, Г.Камал театры сәхнәсенә төшмәслек булып менде. Уйнады, танылды.

Кагыйдә буларак, театрлар традициясендә җаваплы рольләрдә уйнарга ике-өч артист билгеләнә.

Хәтерем ялгышмаса, приказда Фидания Нуруллина Шәфәкъ роленә өченче составта иде. Ә инде тамашачыларга тәкъдим ителә торган программада, фамилиясе беренче куелып, исеме «Дания» иде. Шуннан бирле ул, исеменә дан арты дан өстәп, театрыбызның чираттагы дан иясе буларак танылды. «Фидания»дән «фи» кушымчасы алынса да, фидаилыгы үзенә калды, шул фидаилык актрисаны фидакярьлеккә өндәп, иҗади мохиттә яшәтте һәм... яшәтә, яшәтер. Ул тудырган сәхнә образларына да, аерым-аерым тукталып, аларны сортларга аерып, сыйфат пичәте басарга җыенмыйм. Андый шөгыльне кирәкледән дә санамыйм. (Майга су катнашмаган кебек, сәнгать әсәренә

Беренче роль. «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим) спектаклендә – Шәфәкъ ролендә

пичәт басуның иҗатка катнашы юк.) Теләсә кайсы сәнгать әсәрен тамашачының йотлыгып каравы, яисә тәэсирләнеп тыңлавы – үзе зур бәһа, үзе иң әһәмиятле пичәт.

Урман хуҗалыгында эшләүче «объездщик»ларга агачларның «хәлен» билгели торган тамгалы 2 тимер чүкеч бирелә. (Хәзер ничектер). Кайсы агач үсәргә, кайсы киселергә тиеш икәнен шул чүкеч белән кәүсәгә сугылган тамга-клеймәсе хәл итә.

Кагыйдә буларак, тамгаларның «кисәргә» дигәне авыру кәүсәләргә сугыла. Өй салыр өчен бүрәнәлек агач кирәк булганда, «объездщик»ны җайлап-майлап, клеймәнең нинди сугылырга тиешлеген килешеп кую хәерле. Каравылчы: «Нигә бу үсә торган сәламәт наратны кистегез?» – дип бәйләнә калса, клеймәсенә күрсәтәсең дә – котыласың.

Үзләрен театр белгече дип атаучыларыбыз да, күпчак, шул клеймә сугучыларны хәтерләтә кебек. Тамгалы чүкечләре әзер! Әмма алар «объездщиклар»дан «кисәргә» дигән клеймәләре бөтенләй булмау белән аерылалар. Сәхнәләребезне «вак куаклыклар», чүп агачы – «америка чаганы» басуның бер сәбәбе шунда. Карагай, нарат, имән кебек агачларны куаклыклар каплап, үсәргә ирек бирми. Конвейердан төшкән һәр драма әсәренә «үсәргә» – «куярга» клеймәсе сугылу – корыган агачлар урманын булдырды.

«Агачлар баскан килеш үләләр» дигәндәй, бик күп пьесалар, куелсалар да, тиз онытылалар, «баскан килеш корыганнар» сафын арттыралар. Әлбәттә, вак куаклыклар кирәк урыннар да бардыр. Әйтик, читән үрергә, печән өйгәндә кибән астына салырга. Сүзебезнең мәңге яшел зәйтүн, дәфнә, эвкалипт агачлары турында түгел, ә нарат, имән агачларының да бетеп баруы турында икәнен тамашачы аңлыйдыр. (Драматургларыбызның күзләре үткен, колаклары сак булса да, эчке цензуралары бик уяу).

Дания Нуруллина рухи байлыгы, иҗади тәҗрибәсе өстенә, тирән хистойгылар уятыр перевоплощение – үзгәрү талантына ия артистка. Ул дөнья классикасы әсәрләреннән Медеяне, Гертруданы, Катаринаны («Гамлет» һәм «Укрощение строптивой»),

Вассаны уйнар иде. («Иде» дисәм дә, хәзер дә соң түгел.) Жан Ануйның Жаннасы татар иле, бүгенге татар тамашачысы өчен бик заманча яңгырар иде. Аның милли азатлык өчен үз иманыннан баш тартмый учакта януы, көрәшкә чакырган набат булыр иде. Тик корабльләр өчен сулыкларыбыз сайлыгыннан битәр, лоцманнарыбыз ярдан ерак йөзүдән куркалар шул.

Үзебезнең Сөембикә-ханбикә образы да Академия театры сәхнәсеннән милләтенә мөрәҗәгать итә алмавына гүрендә рәнҗеп ятадыр. Иң элек үзләрен «театр белгече» дип атаучы фән докторларына, ягъни «лоцман – объездщикларга» – драматургларыбызны «уятмаган» өчен, аннары авторлык тезгенен эләктергәннәргә артистларга атап әсәрләр язмаган өчен. Монысы өчен Сөембикә-ханбикә генә түгел – рәнҗер шәхесләребез күп: Батыршадан башлап, Олуг Мөхәммәт, Гази Заһитов, Карбышевларны кертеп; Тукай, Такташ, Хәсән Туфаннарны катнаштырып. Аллага шөкер, тарихи темаларны тирән сөргән авторларыбыз, үсеп, сафка бастылар.

Театрыбызның сәхнәсенә Мөхлисә Буби «менәчәк» икән, дигән хәбәрне ишеткәч, «ниһаять» димәгән милләтпәрвәр кеше калмагандыр. Тик, Мөхлисә ролендә Дания Нурлы уйнаячак, дигән хәбәргә шатланырга өлгермәдек, бердән-бер кызының фаҗигале үлеменнән соң артистка ул рольдән баш тарта икән дигән хәбәр таралып, театр сәнгате белән кызыксынучыларны шөбһәгә салды. Данияне алыштырыр башка артистлар юклыктан түгел, Даниядәгедәй эчке энергияле, тәҗрибәле, хәйләсез, ихлас күңелле артисткаларыбыз юклыктан.

Сүз агышымны бүлеп булса да, мин Даниядә Гөлсем апа Камскаяның чалымнары булуын хәтерләтеп узмак булам. Гөлсем апаның да шәхси тормышы драматик вакыйгаларга мул иде. Ул да авырлыкларны сабырлык белән, башкаларга салынмаска тырышып кичерә иде. Гомере буена акчага тилмереп яшәве дә сер түгел.

Бервакыт театрның сәхнә артында гәпләшеп утырганда, кемдер аннан:

– «Сәгать ничә?» – дип сорый.

Гөлсем апа сәгатенә карый да:

– «11 сум 35 тиен», – ди.

Артистлар көлгәч, хәлне аңлап, үзе дә көлә:

– «Әй-лә, каян акча табу турында баш ватып утыра идем, кибеткә макарун кайткан», – ди.

Кемдер көлгәч (Габдулла ага Фәтхуллин булырга тиеш): – «Көлмә, зәнки», – ди. Бу аның сүгенүне алыштырган фирменный сүзе иде. Абынып егылса да, әйберсен югалтса да «зәнки», диде.

Дания ханымның да үз уйларыннан, үз хәсрәтләреннән арына алмаган чаклары еш була. Шундый вакытларда очратып, «Сәлам, Дания» дигәч: «Әйе шул, репетициягә ашыгуым!» – ди икән, бу аның «фирменный җавабы». Тапшырылган эшнең нәтиҗәсенә ирешкәнче, Даниянең уенда да, телендә дә гел шул булыр иде. (Хәзерге хәлендә ничектер – күптән очратканым юк – телефон аша гына сөйләшәбез.) Яшәү рәвешенең асты өскә килеп, күңеле урыныннан купкан, күзенә ак-кара күренмәгән вакыт булса да, Дания ханым больничный бөркәнеп постельдә ятмый, репетициягә йөри һәм Мөхлисәне «терелтә»: «Үлеп яратты» спектакле (Ркаил Зәйдулла әсәре) тамашачыга үз вакытында, афишада күрсәтелгән көнгә өлгерә. Бу – Даниянең, үзен-үзе җиңеп, батырлык кылуы буларак бәяләнергә лаек эше. Спектакльне тулаем да, аерым артистларның уенын да җылы кабул итәләр. Газета-журналларда, тамашаның теләгән эффектына ирешүендә, баш рольне башкарган Дания Нурлы адресына мәдхияләрнең иң саллысы, иң дәлиллесе урын ала.

«Ташкыннар» (Т.Гыйззәт) спектаклендә – Зәмзәмбану ролендә

Интервьюларда: «Елый-елый карадык», «кызгандырды» диючеләргә күбрәк урын бирелә. Чынлап та, тамашачылар арасында Мөхлисәне кызганучылар күп булды, андыйлар бүген дә күп. Әйбәт фалмы бу? Сораганым булмады: елаучыларны күреп, автор куанамы икән? Әллә уйлана микән? Мөхлисәнең тәкъдим ителгән версиясенең авторы Дания ханым ни уйлый бу хакта?

Бу мәкаләдәге «акыл сатуларым» аларга сораулар булып ирешсә, мин канәгать. Спектакльнең «миссиясе» елатып, кызгандырудамы? Үлеп яратудамы? Әллә кешеләр күңелендә ышаныч, өмет уятып, иманыңа хыянәт итми үлүдәме? Хикмәт үлемдә дә, яратуда да түгел – дөрес яшәүдә булса? Күп сораулар туа. Бусы, әлбәттә, спектакльнең көчлелегеннән...

Ахыры бар ■

Якты күңелле олуг җырчы

Быел 24 июльдә Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Гали Гани улы Ильясовка 80 яшь тулган булыр иде.
Гали ага заманында филармониянең Гоголь урамында урнашкан бинасына еш килә иде, безне җәен бик тәмле, эре алмалар белән сыйлый иде. «Үзем үстергән алмалар, безнең бакчага килегез», – дип, кунакка да чакырып китә иде. Быел аның арабыздан киткәненә дә уналты ел вакыт узган инде...

Әтисе Гани белән әнисе Маһинур икесе дә Татарстанда туган. Алар Приморск өлкәсендәге шахтерлар шәһәре Сучанда очраша һәм шунда гаилә корып җибәрә. 1936 елның җәй аенда уллары Гали туа. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, әтисе кебек шахтер булу максаты белән, Гали дә тау техникумына укырга керә. Биредә ике ел укыгач, Совет Армиясе сафларына алына һәм шунда аның киләчәк язмышы үзгәрә дә куя.

Тын Океанның диңгез авиациясе флотында хезмәт итә ул. Авыз эченнән генә җыр көйләп йөрергә яратучы Галигә беркөнне хәрби концертта катнашырга кушалар. Шул бер чыгыштан соң армия смотрларында еш катнаша ул. Матрос иптәшләре үзара «җырчы Гали» дип йөртә үзен. 1957 елда Хабаровскида узган армия смотрының йомгаклау концертында «Ай серенадасы»н уңышлы башкарып, лауреат исемен ала. Концертны тамаша кылып утырган маршал Р.Малиновский Г.Ильясовның чыгышын ошатып, аңа алтын каләмле ручка һәм карандаш бүләк итә, өенә кайтып килергә дә рөхсәт бирә.

Бу уңышлардан соң музыкаль белем алырга, профессиональ җырчы булырга дип хыяллана башлаган егеткә, Мәскәү консерваториясендә укырга киңәш бирәләр. Шулай итеп, Гали Ильясов 1962 елда Мәскәүгә юл ала. Ләкин кабул итү имтиханнарына өлгерми, аңа үз бәхетен киләсе елда сынап карарга киңәш итәләр. Тик ул вокаль кафедрасы җитәкчесе Г.А.Тицка үзен тыңлап карауларын үтенеп мөрәҗәгать итә. Педагог ерак Хабаровскидан килгән егетнең гозерен кире какмый, «Иртәгә консерваториягә кабул ителгән студентлар белән чыгыш ясарсың, тыңларбыз үзеңне», дип өметләндерә. Икенче көнне бернинди имтиханнарсыз, Галине П.И.Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы музыка училищесының II курсына кабул итәләр. Ул педагог Б.М.Беркович классында белем ала. Студент елла-

«Самими кеше иде, уе гел яхшылыкта гына булды. Нечкә күңелле, бераз беркатлырак та. Аның дуслары күп, дошманнары, мөгаен, бөтенләй дә булмагандыр...»

рында аңа Мәскәү консерваториясендә узган зур тантаналы концертларда чыгыш ясарга насыйп була. 1965 елда училищены уңышлы тәмамлаган Галигә Бөтенсоюз радиосында яки Совет Армиясенең җыр һәм бию ансамблендә эшкә калырга да мөмкин була. Мәскәү Зур театрына да барып карарга киңәш итүчеләр була. Аңа анда: «Сезнең тавыш мөмкинлегегез бик югары, тик буегыз кечкенә булу сәбәпле театрга ала алмыйбыз, әмма киләчәгегез бик өметле, сезне барлык концерт оешмалары, филармонияләр дә биш куллап алачаклар», – диләр.

Күңеле белән Казанга ашкынган булачак җырчы, 1965 елда Казанга килә. Башта Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли, аннан 1990 елга кадәр Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекторий бүлегенең әйдәп баручы солисты була. Билгеле булганча, бирeдә ай саен репертуар яңарып тора: төрле опералардан арияләр һәм романслардан торган академик пландагы концертларда, татар композиторлары әсәрләреннән торган әдәби-музыкаль кичәләрдә, балалар өчен әзерләнгән музыкаль тамашаларда ул актив катнашучы, җыр сәнгатен пропагандалаучы талантлы башкаручы була. 1972 елда Гали Ильясов Мәскәүдә узган Бөтенроссия конкурсында халык музыка кораллары оркестрына кушылып халык җырларын башкара һәм лауреат исеменә лаек була.

Җырчы республиканың бай музыкаль тормышында актив катнаша. Филармониянең лекторий артистлары белән бергә илебезнең зур концерт залларында, Кавказ, Балтыйк буе республикаларында, Ерак Көнчыгышта, Сахалинда, Норильск һәм Якутск якларында, БАМда, Урта Азиядә чыгыш ясый. Шулай ук Монголия, Чехословакия, Венгрия, Англия шәһәрләрендә, Италия, Төньяк һәм Үзәк Африка җирләрендә гастрольләрдә була; 1977 елда Туниста Карфаген фестивалендә, 1978 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән Италиянең «Унита» гәзите бәйрәмендә катнаша.

Филармониядә эшләү елларында Гали Ильясов бигрәк тә, татар композиторлары әсәрләрен, татар халык җырларын зур осталык белән башкара. СССРның халык артисты Натан Рахлин җитәкчелегендәге ТР Симфоник дәүләт оркестрына кушылып Татарстан шәһәрләрендә чыгышлар ясый. Филармония музеенда аның атаклы дирижер Натан Рахлин белән Яр Чаллы шәһәрендәге чыгыштан соң төшкән фоторәсеме дә саклана. Ул шулай ук күренекле композитор Рөстәм Яхин белән иҗади дуслыкта яши.

Гали Ильясов иҗатта эзләнүчән, тынгысыз шәхес була, җырлар иҗат итә. Музыка белгече, профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов җырчы иҗаты турындагы бер мәкаләсендә болай дип яза: «*Гали Ильясов җырлары милли традицияләр, халыкчанлык белән сугарылган. Шул ук вакытта алар заман эстрадасы аһәңнәренә хас якты, матур, яңача яңгыраулары белән дә аерылып тора. Аларда итальян җырларына хас канто-гүзәл итеп башкару мөмкинлекләре бар. Г.Ильясов җырлары татар эстрадасы өчен яңалык булган Көнбатыш илләренең популяр поп-музыка ритмнары белән милли музыка сәнгатебезне тагын да баетты...*»

Дирижер Н.Рахлин җитәкчелегендәге Дәүләт симфоник оркестры белән Яр Чаллыда. 1979 ел

1997 елда «Мәгариф» нәшриятында аның «Оныттың бугай...» дип аталган, кырык җыр кергән җыентыгы дөнья күрә.

Гали Ильясов 1990-1994 елларда филармониядә вокал буенча педагог вазифасын да алып барган, яшь җырчыларга җырлау алымнарын, вокал серләренә өйрәткән.

Клара Таҗиева,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

«Гали Ильясов дигәндә, минем күңелемдә һәрвакытта кояшлы көн барлыкка килә. Филармониягә дә гел елмаеп-көлеп килеп керә иде ул, без дә аңа карап елмая идек. Ул сәхнәгә дә һәрчак елмаеп чыга иде. Музыкант буларак әйтәм, андый тавышлы җырчылар бармак белән генә санарлык. Ул табигатьтән бирелгән бик моңлы, матур тенор тавышлы җырчы иде. «Мин Россиядә соңгы белькантоларның берсе», – дип әйтә иде ул, үз-үзенә шулай бәя бирә иде. Ул гомере буе филармониянең лекторий бүлегендә эшләде. Кешеләрдән кара көнләшү аңарда беркайчан да юк иде. Чөнки аның күңеле чиста иде. Юморга да бик оста иде ул. Җырчы белән аралашырга бөтен кеше ярата иде. Шулкадәрле рәхәт һәм җиңел иде аның белән аралашуы, эшләве.

Гали белән күңелле хәлләргә дә еш очрарга туры килде. Бервакыт концерттан соң аның машинасына утырып, җырчы Әлфия Галимова, баянчы Рәшит Мостафин һәм мин төнге Казан урамнары буйлап өйләребезгә кайтабыз. Рәшитнең өе турысына җиткәч, Гали машинасын туктатты. Шулвакыт милиция хезмәткәрләре килеп җитте дә Галигә: «Сез юл кагыйдәсен боздыгыз», – дип, аннан юл йөрү таныклыгын сорады. Ул кесәләрен актара башлады, караса, алар юк, «өйдә калган», димәсенме. «Мин концертка дип яңа киемнәр кидем, документлар өйдәге пиджәктә калган», – ди. Сөйләшә-сөйләшә аның җырчы икәнлеген, сәхнәдә күрүләрен исләренә төшереп, тегеләр «Башка болай эшләмәгез», дип безне җибәрделәр.

Бер төркем сәнгать осталары Т.Синявская белән

Ул вакытта машина бик аз кешедә иде. Гадәттә, без артистлар Гали машинасына утырып барабыз, әгәр юл йөрү кагыйдәсен бозса, ул бер дә аптырамыйча, елмаеп: «Мастер үзе белә ул», – дип, тиз генә хатасын төзәтә иде. Самими кеше иде, күңеле гел яхшылыкта гына булды. Нечкә күңелле, бераз беркатлырак та. Аның дуслары күп, дошманнары, мөгаен, бөтенләй дә булмагандыр...»

Фәнис Гыйльметдинов,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

«Лекторий бүлегендә эшләгәндә төрле шәһәрләргә гастрольләргә бергә еш чыга идек. Без аның белән кайда гына булмадык: төрле заводларда, цехларда, тулай торакларның кызыл почмакларында... Әгәр аңа баянчы ошамаса, ул шунда ук үз фикерен әйтә. Лекторийда эшләү дәверендә без аның белән дус-тату булдык. Гали ага бик дөрес күңелле кеше иде.

Ул үзенә генә хас моңга ия. Русча җырласа да, татарча җырласа да, тембрының матурлыгы белән шаккатыра. Татар мохитендә үсмәү сәбәпле, ул ана телен камил белми иде. Әмма үзенең тырышлыгы белән, тиз арада халык арасында популярлык яулады.

Зөһрә Сәхәбиева,
Татарстанның халык артисты:

«Гали әфәнде Ильясовка минем хөрмәтем ифрат зур. Тавышы сирәк, көчле тенор тавыш, үзе югары зәвыкка ия кеше, академик юнәлештәге талантлы җырчы иде. Аның белән бер сәхнәдә еш җырларга туры килде. Дәүләт югарылыгында уза торган концертларның берсеннән дә калмый иде ул. Романсларны башкарырга да бик нечкәлек, хиссият кирәк, андый жанрда да ул яхшы эшләде. Безнең татар җыр сәнгатенә, аның үсешенә зур өлеш керткән җырчы ул».

Рөстәм Маликов,
Татарстанның халык артисты:

«Гали Ильясов классик әсәрләр башкаручы атаклы җырчы иде. Шулай ук бик матур көйләр дә язып калдырды. Әнгам Атнабаев сүзләренә язган «Әнкәй, синең куллар» дигән җырын Илһам абыйдан соң, бик озак еллар буе җырлап йөрдем. Хәзер дә бик яратып җырлыйм.

Аның белән бергә эшләргә туры килмәсә дә, гастрольләргә бергә чыгарга туры килгәләде. Смоленск шәһәренә без яшь җырчы Нурахмәт Мөхәммәтҗановны Бөтенроссия җыр конкурсында катнашырга алып бардык, ул анда уңышлы чыгыш ясап лауреат исемен яулаган иде. Анда маэстро А.Шутиков җитәкчелегендәге оркестр, Гали ага Ильясов, музыкант Рөстәм Вәлиев һәм мин бардык.

Гали ага көлке хәлләргә еш очрый иде. Шул Смоленскида, концертның икенче көнендә, шат йөзле Гали ага кунакханәгә: «Мин чегәннәрдән күлмәк алдым», – дип куанып кайтып керде. Матур итеп төрелгән төргәкне ачкан иде, шаккаттык, ул балалар күлмәге булып чыкты. Шуннан мин ул күлмәкне Гали агадан сатып алдым, ул вакытта минем малайлар кечкенә иде. Аның шундый беркатлы, кызык гадәтләре дә бар иде.

Иҗади күңелле, кояш кебек якты да, җайлы да кеше иде ул. Кызганыч ки, кыска гомерле булды шул. Әмма йолдыз кебек атылды, иҗат итте, көйләре калды, язмалары сакланадыр. Тик хәзер алар радио-телевидениедән бик яңгырамый шул.

Хәмдүнә Тимергалиева,
Татарстанның халык артисты:

«Гали абыйны эшкә Мәскәүгә Зур театрга да чакырган булганнар, аның

Татар Дәүләт филармониясе, Гали Ильясовның исемен мәңгеләштерү максатында, Сульяк Болак урамындагы ул яшәгән йортка мемориаль такта кую буенча эш башлады.

буе бераз озынрак булса, ул барлык опера театрларында да җырлый алырлык җырчыларыбызның берсе иде. Бик күп яшьләргә вокал дәресе бирде ул, күпме яшь җырчыга зур сәхнәгә чыгарга булышты, Россия күләмендәге бәйгеләрдә катнашырга ярдәм итте. Шулкадәр чиста күңелле кеше иде, аның күңелендә ялгышып та кешеләргә карата начар фикере булмады. Кеше турында начар уйлый белми иде, шуңа аңа самими, беркатлы итеп тә карыйлар иде.

Георгий Ибушев,
Татарстанның халык артисты:

«Беренче танышуда ук Гали абыйның эчкерсез, гаҗәеп чиста күңелле кеше икәнлеген күреп шаккаткан идем. Филармониянең йөзек кашы, бизәге иде ул. Сәхнәгә чыккач, кирәк җирдә биеп тә ала, йөз-мимика белән сурәтләп тә күрсәтә иде.

Мин аның юбилей концертларында да еш катнаштым. Үз эшен ярата торган гаҗәеп шәхес иде ул. Концертларда бер яки ике җыр җырларга кушылган булса да, ул, гадәттә, биштән дә кимне җырламый иде.

Гали абый белән бергә төшкән фотоларны карыйм да, күңелдә сагыш кузгала, нинди олы шәхес киткән икән бит безнең арадан, дип уйга каласың.

Филармония музее мөдире
***Алсу Хәкимова** әзерләде.* ■

Мөхәммәдьяр (1497-1549)

Шагыйрь Мөхәммәдьярның туувы якынча 1497 елга туры килә. Рухани гаиләсеннән. «Төхфәи мәрдан» поэмасында исеменең «Мәхмүд Хаҗи углы фәкыйрь Мөхәммәдьяр» булуын искәртә, ике урында «Ярмөхәммәд» дип атый. 1542 елда иҗат ителгән «Нуры содур» әсәрендә «Мөхәммәд Әмин хан каберендә» «мөҗавир» (сакчы) булып торуын әйтеп китә. Әдип «Төхфәи мәрдан»да үзенең күп мәшәкатьләргә, авырлыкларга таруын яза: *«Чикдем әмма рәнҗ вә мәшәккать бихисаб»*.

Шагыйрьнең гомер юлы фаҗигале рәвештә өзелә. Ул Казан делегациясе составында тылмач булып Мәскәүгә килә. Аны 1547 (яисә 1549) елның җәендә Явыз Иван гаскәрләре Муром (Карачар) тирәсендә вәхшиләрчә үтерә.

Колшәриф (?-1552)

Урыс елъязмаларында шагыйрь, сәет (дин башлыгы) Колшәриф Казан-Мәскәү арасында барган катлаулы дипломатия эшләрендә дәрәҗәле җитәкче буларак телгә алына. Мәсәлән, 1551 елның җәендә ул Зөя кирмәненә җибәрелгән илчелеккә баш була һәм хан тәхетенә утырырга өмет баглаучы Шаһгали белән бик җитди сөйләшүләр алып бара. Шул ук елны урыслар, татар хөкүмәтенә әйтеп тә тормастан, ягъни ике арадагы шартнамәне тупас бозып, Казан ханлыгының Тау ягын

Колшәрифнең соңгы көрәше. Фиринат Халиков рәсеме

үзенә куша. 14 августта әлеге мәсьәләне тикшерүгә багышланган Корылтайда Колшәриф Ватанын яклап ялкынлы чыгышлар ясый. Тәхеткә Ядегәр хан утыргач, хөкүмәт составына кертелә һәм дәүләтнең көндәлек эшләрендә тагын да активрак катнаша башлый. Явыз Иван да, 1552 елның 13 августында Зөя кирмәненә килгәч, Казан кешеләренә багышланган мөрәҗәгатен Колшәриф исеменә күндерә.

Сәетнең үлеме дә чын каһарманнарча була. Халкыбыз тарихындагы иң авыр көннәрдә – 1552 елның 2 октябрендәге Явыз Иван һөҗүме вакытында – ул, ханлыкның баш имамы, туган туфрагының мөстәкыйльлеген саклап калыр өчен, кулына кылыч-калкан алып иң алдагы рәтләрдә көрәшә. Ахырда үзенең иярченнәрен җыеп мәдрәсәгә керә һәм илбасарлар белән мәдрәсә түбәсенә чыгып сугыша. Урыслар аны мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшерә. Колшәриф шул рәвешле шәһит була...

Габденнасыйр Курсави (1776-1812)

Мәшһүр фикер иясе һәм дин белгече Габденнасыйр Курсави (Әбуннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави) хаҗ сәфәренә чыккан юлында ваба чире (холера) белән авырып китеп, Төркиядәге Үскүдар шәһәрендә (Истанбул каласының Азиядәге өлеше) вафат була.

Шәмсетдин Зәки (1825-1865)

Шәмсетдин Зәки (Шәмсетдин Ярәхмәт улы Гобәйдуллин) тома сукыр булып дөньяга килә. Рабит Батулланың Бакый Урманче сөйләвенә сылтама ясап язуынча, 1865 елда Габдулла Дәүләтшаһ исемле бер ахун, дин эшен ташлап, кантон башлыгы булып китә. Элек халыкны сәдака белән «генә» имгән булса, хәзер чыбыркылап талый, мал җыя, типтерә, урыс түрәләре белән әшнәләшә. Шагыйрь Шәмсетдин Зәки бу гаделсезлеккә түзә алмый, әче сүзле такмаклар чыгара.

Габдулла ахун, кантун булгач,
Окружнойга таныштың.
Башыңдагы ак чалмаңны
Фуражкага алыштың.
Габдулла ахун кантун булган
Исәнголга, башкортка.
Өч сум акча ала икән
Полгодовай пашпортка!

Бу такмаклар телдән телгә күчә, җәмәгатьчелек арасында бик тиз таралып өлгерә, ил буйлап сибелә. Габдулла ахунның үзенә дә барып ирешә. Озакламый сукыр суфи Шәмсетдин Зәки хаҗ сәфәренә кузгала, ләкин Россиядән дә чыгып китә алмый – типсә тимер өзәрдәй кырык яшьлек сау-сәламәт шагыйрь Таганрог шәһәрендә сәер рәвештә бакыйлыкка күчә.

Әхмәтҗан Тубыли (1826-189?)

Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли (Әхмәтҗан бине Шәмсетдин әл-Тубыли) 1825 елда хәзерге Татарстанның Лениногорск районына кергән Әби (Сарабиккол) авылында туа. Чистайдагы атаклы Мөхәммәтзакир Камалов мәдрәсәсендә белем эстәгәннән соң, кырык биш яшенә кадәр туган авылында мулла һәм мөгаллим булып эшли. Ялган шикаять буенча ике мукшы (мордва) кешесен үтерүдә гаепләнеп, 1871 елда Тубыл шәһәренә сөргенгә озатыла. Шигъри иҗатының үзәген тоткын-

лыкта кичергән тирән фаҗига, лирик-фәлсәфи кичерешләре алып тора.

Мифтахетдин Акмулла (1831-1895)

Акмулла Уфа губернасының Бәләбәй өязенә караган Дүсән исемле татар авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Ире Мөхәммәдьяр вафатыннан соң, шагыйрьнең анасы Өммегөлсем Туксанбай авылы башкорты Камалетдингә кияүгә чыга.

Шагыйрьнең гомер юлы фаҗигале рәвештә өзелә. Ул 1895 елның 27 октябренә каршы төндә Златоусттан Миасска барганда Гафиятулла Баймөрат улы һәм Дәүләтшаһ Надиршаһ улы дигән бәндәләр тарафыннан үтерелә.

Миркасыйм Госманов искәрткәнчә, шагыйрьнең Зәйнулла Рәсүлев куйдырган кабер ташында болай язылган була: *«Шәһидләрчә үтерелгән, 1313 елда сигезенче җөмади-әл-үләдә, җомга көнне кичен; Акмулла исеме белән билгеле мелла Мифтахетдин, нәсел буенча атасы Мөхәммәдьяр хәлфә, тәрбия буенча атасы Камалетдин. Тәмам, бетте»*. Вәләкин бу ташны Уфадан килгән делегация 1980 елда алып ташлый һәм аның урынына Камалетдинне Акмулланың чын этисе итеп күрсәткән язулы мәрмәр плитә куя.

Язучы Рабит Батулла шагыйрьнең соңгы минутларын түбәндәгечә сурәтли:

Юлбасарлар Акмулланы таларга уйлаган.

– Малыңмы, җаныңмы, Акмулла? – дигәннәр.

– Малымны бирер идем, малым юк, – дигән Акмулла. – Җанымны бирер идем, шуннан сезгә ни фәтва?

– Алдаша ул! – дип ысылдаган җәлпәк битле юлбасар. – Үзем ишетеп тордым, олы агайлар әйтте: Акмулланың байлыгы бихисап, диделәр.

Акмулланың Зәйнулла Рәсүлев куйдырган кабер ташы

– Дөрес әйткән олы агаңнар, мәхлук! Минем байлыгым әнә анда! – дип, Акмулла арбага ымлаган. – Ләкин ул байлыктан сез наданнарга ни файда?

Юлбасар атылып арба янына килгән. Кабаланып, арба сандыгын ачкан. Сандыкның бер башында балта, чүкеч – эш кораллары булган, икенчесендә – китаплар, китаплар... Сандыкта алтын-көмеш табалмагач, юлбасар коралларны чәчеп ташлаган, китапларны ботарларга тотынган.

– Тимәгез китапларга! – дип кычкырган Акмулла. – Кәгазьнең ни гаебе бар?

Юлбасар аның саен үҗәтләнеп китап умыра икән.

– Толпаркай, оч! – дип сызгырган шагыйрь. – Толпарым оч! Казакъ ягына таба оч, Толпар!

Толпар алга ыргыла, юлбасар җиргә мәтәлеп төшә. Атына атланып куып караса да, Толпарны куып тота алмый ул, арбадагы кулъязма китапларны сөйрәп, Толпар, томырылып, казакъ ягына чабып китә.

Акмулланың хәзерге кабер ташы

Ул арада юлбасарларның берсе пычагын Акмулланың бугазына ныграк тери төшә:

– Кайда синең байлыгың, сәсән!

– Байлыгым арбада китте, казакъка китте минем байлыгым. Ә бер өлеше менә монда! – дип, Акмулла башына күрсәтә. – Тагын менә монда минем байлыгым! – дип, шагыйрь йөрәгенә ымлый.

Юлбасар пычагын Акмулланың йөрәгенә кадый. Үлем ярасы алган Акмулла әйтә:

– Надан мәхлук! Зинһар, син өйләнә күрмә...

– Нимә дисең, сәсән? – дип сорый үтерүче.

– Син өйләнсәң, халык мескенлеккә дучар булыр. Син өйләнсәң, балаларың туар. Балаларыңның балалары булыр. Алар һәрберсе үз чорының акмуллаларын суя барыр... Шунда...

Шагыйрьнең соңгы сүзен кисеп, канлы пычак җәрәхәтле йөрәкне тагын бер кат айкап чыга.

Юлбасарлар, шагыйрьнең канлы гәүдәсен Сыңар Тирәк янында калдырып, кайтыр юлга кузгала...

Әдәбият

1. Акмулла. Шигырьләр. Төзүчесе Миркасыйм Госманов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. – 271 б.
2. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – 751 б.
3. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – 735 б.
4. Батулла. Тузга язмаган хәлләр: Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997. – 447 б.
5. Кол Шәриф һәм аның заманы = Кул Шариф и его время. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 192 б. (Татар һәм рус телләрендә.).
6. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 415 б.

Рүзәл Мөхәммәтша әзерләде.■

ТАССР мирасы

(ТР Милли музее фондларыннан)

1920 елның 27 маенда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм РСФСР Халык Комиссарлар Советы Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы турында Декрет кабул итә. Музейда бу чорга караган иң абруйлы экспонатларның берсе шул ук елның 25 июнендә оешкан республикабызның беренче байрагы. Ул кызыл бәрхет тасмадан ясалган һәм аскы өлеше алтын чуклар белән каймаланган. Байракта РСФСР гербы һәм алтын җеп белән татар телендә гарәп хәрефләре ярдәмендә

ТАССР игълан ителү уңаеннан банкет

«Бөтендөньяның эшчеләре берләшегез. Татарстан Социаль Советлар Җөмһүрияте. Төзелүе 1920 нче елда», – дигән язу чигелгән.

Шулай ук 1920 елда ясалган ТАССР картасы да зур кызыксыну уята. Яңа республиканың чикләрен ачыклау һәм билгеләү 1924 елга кадәр сузыла. Халык күреп белсен өчен әлеге карталар Казан шәһәре урамнарында эленгән.

1937 елның 25 июнендә Советларның XI съезды Республика Конституциясен раслый һәм җөмһүрият атамасы «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы» (ТАССР) дип үзгәртелә.

Гүзәлия Җәләлева *әзерләде.*

Фоторәсемнәр ТР Милли музей архивларыннан алынды. ■

Юнысов мәйданындагы ТАССР картасы янында

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

ПАПИРУС – латин һәм грек телләреннән кергән сүз. Субтропикларда елга буйларында, сазлык урыннарда үсә торган камышсыман үсемлек. Биеклеге 5 метрга җитә. Борынгылар аңардан язу кәгазе, тукымалар, аяк киемнәре, көймәләр һәм саллар ясаганнар.

Тар гына папирус тасмаларын ябыштырып ясалган озын кәгазьләргә язылган (иероглифлар төшерелгән) текстлар да *папирус* дип атала.

Ләкин папирус Мисырдагы табигый шартларда гына озакка чыдаган, салкын һәм юеш климат шартларында исә тиз бозылган. Шуңа күрә язу өчен яраклы һәм чыдам материал табу кешелек тарихы өчен гаять әһәмиятле була.

«Папирус» белән уртак тамырлы «папирос» сүзе дә немес телендәге *papier* – кәгазь сүзеннән.

Абхаз телендә папирус кәгазьне *амсыркиаад* диләр. Гомумән, кайбер мәгълүматларга караганда, борынгы Мисыр теле белән абхаз теле арасында зур охшашлык күзгә ташлана икән.

ПАР АТ – Парлап җигелгән атлар; пар ат җигелгән арба. Себер татарлары телендә «пар ат» сүзенең саф татарча тәңгәле бар – *кабат ат*. Төрек телендә пар ат җигелгән чананы мах-

Мисыр папирусы

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

сус исем белән атыйлар: *занка* (русча «санка»дан?) «Пар ат» сүзе аларда – *җөфт баргир*.

«Пар» сүзенең бу мәгънәсе (җөп-җефет, ишле-кушлы булу) русча пара сүзеннән, ә анысы руска нимес теленнән кергән (das Paar). Шунысын да әйтик, физикадагы *пар көч* терминын вакытында *җөп көч* дип алганда яхшырак буласы булган. Татар диалектында пар ат сүзенең «чи татарча» формалары да бар: Төмән өлкәсе сөйләшендә аны *кабат ат* диләр. Шунда ук *ат кушлау* – пар ат җигү.

Габдулла Тукайның «Пар ат» дигән шигыре XIX гасыр рус шагыйре А.Апухтинның «Пара гнедых» дигән романсы белән аваздаш.

ПАР БАСУЫ – Диалектта – *парна*, русчасы – *паровое поле*. // *Иртә пар* – парга беренче кат сөрү. *Яшел пар* – парга икенче кат сөрү. *Кара пар* – парга өченче кат сөрү. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә: «Кара пар – ныгытып эшкәртелеп, бөтен җәйгә чәчелми калдырылган җир». *Чиста пар* – «вегетация чоры дәвамында чәчелмичә, чүп үләннәреннән арындырылып һәм чиста, йомшартылган хәлдә тотыла торган басу» («Татар энциклопедия сүзлеге» буенча).

ПАРИЖ АВЫЛЫ – Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районында урнашкан казаклар авылы. Аның атамасы 1812-14 еллардагы сугышта керәшен казакларның атаман М.И.Платов җитәкчелегендә Парижны алуда катнашулары хөрмәтенә бирелгән. Хәзерге вакытта Париж авылы халкын Уфа губернасының Бәләбәй өязеннән күчеп килүчеләрнең варислары тәшкил итә (Максим Глухов). Алар татар теле диалектында сөйләшә. 2005 елда авыл халкы үзләрендә Париждагы мәшһүр Эйфель манарасының тимер күчермәсен булдырды. «Нагайбәк манарасы» Париждагы оригиналыннан 6 тапкыр гына кечкенәрәк.

ПАСКОРТ ***иск.*** – Паспорт. Гади сөйләм телендә *пашпорт* варианты да йөргән, ягъни бу сүзнең рус теленә кергән беренчел формалары татар телендә дә кабатланган. // *Минем сигез йөзнең ун икенче елында паскортның пушинәсе* (пошлинасы, дөхулиясе – ***А.Т.***) *алты сум булды*. Елъязмадан.

Чыганакларга караганда, миляди IX гасырның беренче яртысында Кытайда паспорт системасы кертелгән була инде. Мисырда Ислам таралуның башлангыч чорында катгый *паспорт режимы* гамәлдә була. Әгәр юлчылар арасында *сидҗилсез* (паспортсыз) кеше очраса, аны кулга ала торган булганнар. Ул заманның «паспортлары» безгә папируслар рәвешендә килеп җиткән. Аларны *җәваз* дип тә атаганнар.

Тоталитар режим шартларында СССР да колхозчылар паспорт алу хокукыннан мәхрүм һәм, димәк, *беркетелмеш крепостнойлар* хәлендә иде (мәгънәви тавтология өчен гафу).

ПӘДӘР ***ф.*** – Ата, әти, атакай (латинча – *патер*, нимесчә – *Vater*). *Патриарх* сүзе дә шуннан. Татар телендә бу сүз *тамагыбызны туйдыручы* мәгънәсенә дә ия. Русчадагы *названный отец* сүзенә туры килә. Төрек телендә дә *пәдәр* – ата, әти. //*Пәдәрем* – атакаем. *Пәдәрвәладем* – атам-анам (фарсыда «ана» мәгънәсендәге *мадәр* сүзе дә бар). *Пәдәр үгәй* – үги ата; уллыкка алган кеше, *тарын/тарун*.

ПӘРВӘРДИГЯР ***ф.*** – Хәлык кылучы, яраткучы, тудыручы, Алла. Бу сүз татар телендәге яратучы/яраткучы сүзенең, ахыргы исәптә, фарсы калыбы белән барлыкка килүен күрсәтә кебек (әйтик, «милләтпәрвәр» сүзендәге *пәрвәр* элементы *сөюче, яратучы* мәгънәсенә ия). // *Күрсәтер пәрвәрдигяр инде тыныч тормыш юлын* (Әбрар Сәгыйди шигыреннән).

Чаг.: ***Кәрдигяр.*** ■

«Тел күрке – сүз» тапшыруын әзерләгәндә. Сулдан уңга: Госман Әхмәтҗан (режиссёр), Рөстәм Акъегет (мөхәррир), Хуҗи Мәхмүтов һәм Вахит Хаков

Фидакярьбез

16 августта академик, Татарстан Җөмһүриятенең атказанган фән эшлеклесе **Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның** (1926-2008) тууына 90 ел тула.

Вахит ага Хаков Татарстан радиосының 40 елдан артык тарихлы «Тел күрке – сүз» тапшыруының чишмә башында торган кешеләрнең берсе булды дисәк, хакыйкатькә бер дә хилаф килмәс. Чөнки ул иң беренче авторларыбыз, танылган тел галиме Рифкать Әхмәтҗанов һәм шулай ук галим, язучы Хәсән Сарьянга табигый рәвештә бик тиз кушылып китте һәм тапшыруның халык арасында киң танылуына үзенең саллы өлешен кертте.

Тапшыру циклы башланган елларда редакциягә хатлар ташкыны ява башлады. Хатларның темалары төрледән-төрле иде. Күбесе әдәпле сөйләү, сүзләр тарихы, дөрес язу кагыйдәләренә карата, телебезнең көннән-көн аяныч хәлгә кала баруы, аның киләчәге, язмышы хакында борчылып язылганнары да байтак иде. Ул елларда шактый четерекле эчтәлекле бу хатларга эфир аша, ягъни цензура иләге аша мөмкин кадәр дөрес, мөмкин кадәр объектив җавап бирер өчен киң эрудицияле галим булу белән бергә «эзоп телен»дә оста куллана белә ала торган сәясәтче сыйфаты да кирәк иде. Менә шушы ифрат җаваплы вазифаны Вахит ага башкарды һәм бу эштә ул алыштыргысыз булды.

Моннан тыш фидакярь галимебез төрки халыкларның тел галимнәре хезмәтләре, туган телебезгә кагылышлы вакытлы матбугатта дөнья күргән язмалар белән тыңлаучыларны даими рәвештә таныштырып барды.

Латинга күчү мәсьәләсен дә «Тел күрке – сүз» тапшыруларында беренчеләрдән булып Вахит ага күтәреп чыкты һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шушы теманы игътибар үзәгенән ычкындырмады.

Ул редакцияне радиотыңлаучылар белән турыдан-туры бәйләүче авторларыбызның берсе иде. Хәзер укучыларыбызга аның радиотыңлаучыларның сорауларына җавап биргән бер язмасын тәкъдим итәбез.

Ул аның соңгы чыгышларының берсе булды.

Рөстәм Акъегет

– Сез хәзерге татар теленең торышына, телне саклау һәм үстерү буенча эшләнгән эшләргә нинди бәя бирәсез?

– Бүгенге көндә татар теленең югары камиллектә булган лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик нормалары бар, аның тарихи яктан төрле сөйләм формаларын эченә алган ныклы, тотрыклы сөйләү һәм язу кагыйдәләре барлыкка килгән. Хәзер элек-электән килгән тел байлыгын саклау һәм үстерү юнәлешендә киң эш алып барыла. Бу мәсьәлә игътибар үзәгендә тора дияргә була. Мәгълүм булганча, бездә – Татарстанда татар һәм рус телләре дәүләт телләре булып игълан ителде. Бу – Конституциябездә дә беркетелгән. Татар теле, рус теле белән беррәттән, гомумбелем бирү мәктәпләрендә, гимназия, көллиятләрдә, өлешчә, югары уку йортларында да укытыла. Татар телен рус балалары да, рус телле укучылар да өйрәнә. Аның турында матбугат битләрендә дә күп языла, радио һәм телевидение аша тапшырулар оештырыла. Дәүләт оешмаларында, учреждениеләрдә дә телгә багышланган төрле чаралар үткәрелә. Татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Парламентында яңа программа да кабул ителде. Тел мәсьәләсен һич тә үз агымына куярга ярамый. Дәүләт оешмалары һәм киң җәмәгатьчелек, бергәләп, татар телен саклау һәм үстерүне ныклы контрольдә тотарга тиеш. Әмма бу өлкәдә әле эш җиңел генә бармый. Татар телен рус телләләр һәм башка милләт вәкилләре – руслар тарафыннан өйрәнү канәгатьләнмәслек дәрәҗәдә тора. Телне дөрес куллануда, сөйләм культурасын үзләштерүдә бездә әле зур кимчелекләр яшәп килә. Телебез турында үзебез кайгыртмасак, берәү дә аны эшләмәячәк. Федераль җитәкчелек Русиядә милләтләрне кысу сәясәте алып бара, милли телләрне үстерү белән кызыксынмый, киресенчә,

«Тел – милләтне, халыкны, аның яшәешен күрсәтүче барометр; ул катлаулы, җанлы организмны хәтерләтә. Тормыш кануннары монда да хәрәкәт итә: телдә нәрсәдер искерә, нәрсәдер яңара, монда да ниндидер үзгәрешләр туа. Бу җәмгыятьтәге хәлләр, заман агышы, халыкның эше-гамәле һәм иҗтимагый-тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә килеп чыга. Минем елдан кубрәк тарихы, бай язма әдәбияты булган татар халкының теле дә җәмгыятьтә зур урын тота. Тел аралашу-аңлашу коралы гына түгел, халыкның рухи халәтен чагылдыручы чара да...»

азатлык юнәлешендә эшләнгән эшләрне хупламый, җөмһүриятебездә кабул ителгән кануннарны юкка чыгарып тора. Конституциядәге маддәләрне Русиянеке белән тәңгәлләштерүләр, Русия Дәүләт Думасының безнең латинга күчүебезгә каршы чыгуы һәм башка гамәлләр шул турыда сөйли. Әле күптән түгел РФ генераль прокуроры урынбасары А.Звягинцев республика Президентына кандидатлыкка сайлау цензы билгеләү мәсьәләсе буенча Татарстан Югары судына мөрәҗәгать итте. 31 нче мартта Суд Татарстан Республикасында Президентның ике дәүләт телен дә белүе мәҗбүри түгел, дип тапкан. Бу инде Президент кәнәфиенә урыс телен генә белгән кешеләр дә утыра алачак, дигән сүз, чөнки татар милләтеннән Президентлыкка сайланган кешеләр һәрвакыт ике телне дә (татар һәм урыс телләрен) камил беләчәк.

– Сез элеккеге әдәби телдә кулланылган, яңадан әдәби телебезгә әйләнеп кайткан икътисад, мөхәррир, сәркатиб, табиб, канун кебек сүзләрнең кулланылуына ничек карыйсыз?

– XX гасыр ахырында җәмгыятьтә

барлыкка килгән зур үзгәрешләр нәтиҗәсендә телебездә элек кулланылган күп сүзләр яңадан кайта башлады. Мәсәлән: табиб, канун, мөхәррир (редактор мәгънәсендә), икътисад, мәдәният, рәис, сыйныф (мәктәптәге класс мәгънәсендә), маддә (законнардагы «статья» сүзе урынына), гыйбарә, мәҗмуга (журнал һәм җыентык мәгънәсендә), нотык, могътәбәр (хөрмәтле сүзенең синонимы), фирка, мөнбәр, мөһаҗир (эмигрант), тәхәллүс (псевдоним урынына), инкыйлаб, иганә, кавем (токым мәгънәсендә) һәм башкалар. Алар арасында бер үк кушымчалар белән кулланыла торганнары да бар: рухият, зарурият, гамәлият, мөхтәрият, хакимият, көллият, илһамият, мөйләмият, иминият, хөррият, сәяси, гамәли, икътисадый, нәзари (теоретик), җәмгыяви, кыйблаи.

Соңгы елларда намә һәм ханә сүзләре кушма сүзләр ясауда киң катнашалар. Мәсәлән: шартнамә, әмернамә, бәянамә, солыхнамә, кануннамә (конституция), боерыкнамә, бурычнамә, елнамә, килешүнамә, кисәтүнамә, өндәүнамә, сораунамә (анкета), сыйфатнамә, тасвирнамә, тәбрикнамә, тәкъдимнамә, хәбәрнамә, хисапнамә, ышанычнамә, юлнамә һ.б. Ханә сүзе белән: тамашаханә, кәбабханә, коралханә, саклауханә, тамгаханә, укуханә, чәркәханә, кунакханә, хастаханә (больница), шифаханә (санаторий), сырхауханә (поликлиника), даруханә (аптека), дәваханә (лечебница), сабакханә, ашханә, остаханә, мирасханә, базарханә, чатырханә (павильон) һ.б. Әлбәттә, мондый сүзләрнең әдәби телдә тулысынча урнашып бетмәгәннәре дә бар. Вакытлы матбугат битләрендә һәм сөйләмдә аларны очратырга мөмкин. Мисаллар: мәхкәмә (хөкем йорты, суд мәгънәсендә), әбүнәче, мәгъмәрият (архитектура), зиһният (интеллект мәгънәсендә), казый (арбитр, спорттагы судья), мәхәллә (квартал), сәркатыйб (секретарь мәгънәсендә), мотлак (абсолют), хатыйб (оратор мәгънәсендә) һ.б.

Тулаем алганда, телебезгә бу сүзләрнең керүен уңай тенденция, уңай күренеш итеп бәяләргә кирәк.

– Сез искергән (архаик) төрки татар сүзләрен (Чулман, турун, чирү) кайтаруны кирәк дип табасызмы?

– Гасырлар дәвамында телнең тарихи үсешендә төрки-татар сүзләренең бер өлеше телдән бөтенләй төшеп калган. Алар хәзерге телдә кулланылмыйлар диярлек. Мәсәлән, кот (бәхет), чиркин (яман, начар мәгънәсендә), сазган (аждаһа), бусу (качып тору), сү, чирү (гаскәр), өл (кул мәгънәсендә), турун (онык мәгънәсендә), сагым (мираж мәгънәсендә) йазы (дала, кыр мәгънәсендә), йийү (ашау мәгънәсендә) һ.б. Мондый искергән, телдән төшеп калган сүзләрнең кайберләре тарихи вакыйгаларны, борынгы яшәү рәвешен сурәтләгәндә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, бүгенге көндә без онык төшенчәсенең борынгы телдәге турун сүзе белән бирелгән очракларын күрәбез. Еш кына Кама елгасының исемен Чулман сүзе белән атыйбыз. Хәзерге телдә гаскәр мәгънәсендә килгән сүзне борынгы чирү сүзе белән дә белдерәбез. Бу сүзнең элекке синонимнары – сү, ләшкәр сүзләре хәзер бөтенләй кулланылмый. Кайбер искергән сүзләрнең мәгънәләре төрле атамаларда сакланып калган. Мисалга үлән мәгънәсендәге ут сүзен алырга мөмкин: ул үлән исемнәрендә бүген дә очрый, ләкин без аны ике сүздән торган атама булабрак кына күз алдына китерәбез: сарутсары – ут, ягъни ул сары үлән дигән төшенчәне белдерә. Олыяз, Торнаяз дигән авыл атамаларында да йаз сүзе борынгы телдәге дала, кыр төшенчәсенә туры килә (Олы дала, Торна даласы) һ.б. Елга исемнәрендә дә халык борынгылыкны саклый: Каманы Чулман, Вятканы Нократ дип йөртә.

Шул рәвешчә, хәзерге тел өчен аерым сүзләр дә теге яки бу күләмдә үзләренең борынгылыгын сиздереп торалар. ■

Танылган мәгърифәтчебез, милли мәгарифебез, мәдәниятебез тарихчысы, этнограф һәм этнолог, филология дигән күпкырлы фәннең күренекле эшлеклесе, Рәсәй Федерациясе География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы М.Ф.Рәхимколованың туууына йөз ел тулды. «Татар энциклопедиясе» хәбәр итүенчә, Мәдинә Фәтхетдин кызы Рәхимколова 1916 елның 30 июнендә Уфа губернасының Бәләбәй өязенә кергән Олы Кәркәле авылында туа һәм 2004 елның 15 февралендә Санкт-Петербург каласында җирләнә.

САГЫШТАН ТУГАН САБЫРЛЫК

Айдар Хәлим

Барлык гомерен туган якны өйрәнүгә биргән үзешчән тарихчы, педагог Казан университетында укый, Ырымбур педагогия институтын (1942) тәмамлый. Сыйнфый көрәш кызган 1929-1932 елларда раскулачивание дигән афәткә эләккән унөч яшьлек «кулак баласы»на Башкортстанның Дәүләкән элеваторында төрле эшләрдә эшләргә туры килә. Авыр язмыш аны төрле җирләргә куып йөртә. Җидееллык фабрика-завод мәктәбендә белем алган кызкай 1932-36 елларда Кыргыз АССРда башлангыч мәктәп мөдире була. «Узтранс» автобазасында да эшли һәм Сәмарканд рабфагында да укуын дәвам итә. 1943-53 елларда Ырымбур һәм Ырымбур өлкәсе мәктәпләрендә укытучылык белән шөгельләнә. 1953-71 елларда Ырымбур авыл хуҗалыгы институтында укыта. Татар һәм башкорт халыкларының тарихы, мәдәнияте буенча хезмәтләр авторы.

Мәдинә Рәхимколованың «Ырымбурда «Хөсәения» мәдрәсәсе», «Революциягә кадәр татар мәктәпләрендә табигый фәннәрне укыту» кебек капиталь хезмәтләре бар.

Фәтхетдин мулла һәм укытучы Фатыйма гаиләсендә туган, гомере һәм язмышы XX гасырның искит-

кеч катлаулы, фаҗигаи чорына туры килгән бу мәгърифәтче шәхеснең тулы иҗади биографиясе, тәрҗемәи хәле һәм фәнни-гамәли хезмәтләре бу әсәрләр белән генә чикләнә алмый. Без бу уңайдан аның Риза казый Фәхреддиннең фәнни мирасын, атап әйткәндә, галимнең тәрбия-әхлак мәсьәләләренә кагылышлы «Тәрбияле бала» , «Шәкертлек әдәбе» , «Тәрбияле хатын», «Гаилә», «Нәсыйхәт», «Җәвамигуль кәлим шәрхе» дигән ифрат та асыл җәүһәрләрен гарәп имлясыннан кириллга күчереп нәшер итүен генә әйтсәк тә, моны бөек гыйльми казаныш дип бәяләү хаклыкка туры килгән булыр иде. Әйтелгәннәргә өстәп, Мәдинә Рәхимколованың 1962-1983 елларда «Совет мәктәбе» журналында чыккан «Физика дәресләрендә ярымүткәргечләрне өйрәнү», «Математикадан татарча беренче дәреслекләр», «Татарча география дәреслекләре тарихыннан», «Физика һәм химиядән татарча беренче дәреслекләр», «Риза Фәхреддиннең педагогик карашлары» кебек һәм башка шундый сирәк кулланма хезмәтләр авторы булуын әйтү җитәдер. Онытмыйк, ул бит әле Казан, Уфа, Мәскәү, Ырымбур матбугатында мәдәниятебезнең үзәк мәсьәләләрен күтәргән өч йөзгә якын мәкалә авторы да. Мәдинә Рәхимкулованың бай гыйльми-мәгърифәтчелек иҗаты, ни кызганыч, әле бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән.

Галимәнең үзе иҗат иткән, урысчага һәм татарчага тәрҗемә кылган, гарәп имлясыннан бүгенге имлябызга күчергән, системага салган һәм үзе үк нәшер иткән хезмәтләрнең исемнәрен генә атап китү дә безнең авыр заманнарда, аеруча дөнья мәшәкәте белән изелгән хатын-кыз гакылы ирешә алган биеклекләрне раслыйдыр кебек. Аның хезмәтләренең тематик төрлелеге таңнар калдыра: «Ырымбур сәүдәгәрләре», «Ырымбур якларында ислам нуры», «Рәмиевләр», «Искәндәр һәм Бәшир Рәмиевләр», «ЮНЕСКО карары буенча 1997 ел Галимҗан Ибраһимов елы», «Садретдин Айни. Иске Бохарада», «Гатаулла Камский һәм башка зыялылар», җәмәгате Якуб Шабакаев белән бергә авыллардан авылларга йөреп җыйган, системага салган һәм бастырып чыгарган сирәклрдән-сирәк «Борынгы милли җырлар», «Җырлы-моңлы Ырымбур» һәм башкалар – болар барысы да Мәдинә Рәхимколованың илһамлы кулларыннан төшкән шәрәфәтләр. «...*Мәдинә ханым татарларда мәгърифәтчелек, мәшһүр уку йортлары, милли театр, матбугат, дәреслекләр, мәдәният учаклары, мәчетләр тарихы, дин. әхлак, тәрбия һ.б. турында яза. М.Рәхимколова татарның атаклы мәгърифәтчеләре, галимнәре, сүз осталары, күренекле зыялылары турында образлар (Р.Фәхреддин, М.Акмулла, И.Гаспралы, Дәрдемәнд, Ф.Кәрими, М.Биги, Г.Тукай һ.б.) галереясын иткән кеше булды,* – дип язды галимәнең 95 еллыгы уңаеннан чыккан «Күренекле тарихчы, мөгаллим» дигән мәкаләсендә тарих фәннәре докторы Равил Әмирхан («Мәгариф». № 9, 2006). – *Мәдинә апа Ырымбурның Х. Ямашев исемендәге китапханәсенең нигез ташларын салучыларның, аның эшендә актив катнашучыларның, бирерә үткәрелгән конференцияләрдә, кичәләрдә, очрашуларда, әңгәмәләрдә әйдәп баручыларның берсе булды... Кимендә ун гасырлык төкәнмәс тарихы, мәдәнияте булган милләтебезнең шушындый затлы вәкилләре белән без хаклы рәвештә горурлана алабыз. Ә аның гаҗәеп эшчәнлеген, иңли алмастай фигълиятен, мөкатдәс омтылышыларын барыбызга да өлге итәсе килә...»*

Галим биргән бәясендә хаклы иде: татар милләтенең асыл баласы Мәдинә

А.Хәлим, М.Рәхимколова хозурында. 2000 еллар

Рәхимколованы чынлап та. соңгарак калып булса да, илгә күрсәтәсе иде. Биредә минем дә шактый соңлаган бурычларым бар. Мәдинә апа миңа авылдаш кына түгел, ә бәлки якыннан-якын кан-кардәшем. Минем әтиемнең әнисе Гайнекамал әбиемнең Фәррәхетдин белән Мәдинә апаның әтисе Фәтхетдин бертуганнар. Шулай итеп, без туганнан туган балалар булып чыгабыз. Мин бу язмамда татарның гомуммилли язмышында күренекле роль уйнаган нәселебез тамырларын Мәдинә апа һәм аның ире Якуб җизни куйган «җәяүле кеше хезмәте»н – ягъни алар сабый чакларыннан күңелләрендә саклаган, калганнарын авылдан-авылга йөреп җыйган, мелодик яңгырашларын Санкт-Петербургта яшәгән кызлары Диләрә сеңелем нотага салган өч борынгы татар халык җырлары аша ачарга тырышсам, укучыларыбыз күңеленә муафыйкъ килер иде, дип уйлыйм.

Әүвәлдә ачыклау: җыентыкта илле өч җыр. Илле өч җәүһәр. Илле өч хәзинә. Аларга башка бәя куеп булмый. Аларны укыганда арка үзәгеннән тир калка. Җырлаган очракта, белмим, нинди тойгылар-тирләр калкыр иде икән? Әгәр алар башка халыкларда булган булса, симфоник оркестрлар, академик хорлар белән ишеттергән, миллион доллар акча сауган булырлар иде. Кая ди җырлау, вокал, яисә хорлар белән җырлау, Мәдинә апа үзе бастырып чыгарган үзешчән басмаларны исәпләмәгәндә, алар моңа кадәр зур матбугатта беркайчан да чыкмаган. Бу җыентыктан әлегә бер генә җыр җырлана: ул «Аһ, Ырымбур-кала». Аны минем тәкъдимем буенча атаклы җырчыбыз Фердинанд Сәлахов башкара. Рәхмәт аңа. Мин җырлар җыентыгын Татарстан җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Айдар Фәйзрахмановка да биргән идем, әмма ул, ошбу җыентыктан ике җырны алса да, нишләптер бик озак вакытларга йомылды.

Җырларның үзләренә кадәр мин бу тетрәткеч дебютны Мәдинә апаның «Шигырьләр. Әкиятләр. Борынгы милли җырлар» дигән китабына (Ырымбур, 2000) «Кереш сүз» рәвешендә язылган мәкаләсе белән ачып җибәрәм. Җырлар кебек, ул да үзәк матбугатта беренче тапкыр басыла.

ҖЫРЛАР

Бу җырларны башкаручылар үзләренең әби-бабаларыннан ишетеп, отып алганнар: җыентыкта барлыгы 53 җыр.

1. Аларны җыючы Якуб Габдрахман улы (минем ирем), 1911 елда туган, Ульян өлкәсе, Иске Кулатка районы, Карамалы авылында – 50 җыр.

2. Мәдинә Фәтхетдин кызы Рәхимколова, Башкортстан, Миякә районы, Олы Кәркәле авылында 1916 елда туган – 7 җыр.

3. Арифулла Таишев, 1914 елда туган, Пенза өлкәсе, Решетино авылында – 3 җыр. (*Автор ялгышканмы, Мәдинә апа язмасында саналганча, биредә 60 җыр килеп чыга. Әмма мин ревизия уткәреп тормыйча, язылганынча калдырдым –* **А.Х.**)

Ноталарын Диләрә Якуб кызы Позднякова һәм Татьяна Колпакова язды. Җырларга исемнәрне, эчтәлегенә карап, үзебез бирдек.

Бу җырлар хәзергәчә бер кайда да бастырылып чыгарылмаган. Җырларның күпчелеге – мишәр җырлары. Мишәрләр Идел буенда Хвалын, Сарытау, Әстерхан тирәләрендә яшәгән һәм яши. Ә Ульян өлкәсенең Иске Кулатка районы бөтен авыллары белән мишәр. Җәгърәфияне аз гына белгән кеше, бу тирәдәге мәдәнияттә Алтын Урда йогынтысы көчле булганын аңлар. Шуны да әйтәсебез килә: Якуб Шабакаевның әтисе яки әнисе ягыннан 19 йөздә шагыйрь һәм композитор һәм башкаручы бер кеше яшәгән булса кирәк. Бу җырларны бүгенге көнгә кадәр онытмыйча саклап алып килгән Шабакаевлар гаиләсе, кырда ял иткәндә җырласа, чит кырлардан килеп тыңлап тора торган булган. Якуб Шабакаев, ничә еллар үткәч тә, әле һәммәсенең көен белә.

Бу җырлар бик киң әтрафларны эченә алган һәм аларда берничә гасырның йогынтысы күренә. Шул сәбәпле алар әле татарларның күчмә тормышлы булган чакларында ук җырлана башланганын күрсәтә. Идел, Агыйдел, Ташкент, Казан аралары безгә бик ерак кебек тоелса да, күчмә халыкка бу аралар якын булган, гомерләре буе шул җирләрне үтеп йөргәннәр. Французлардан килгән чуар ситсалар шул чакларда сәүдәгәрләрнең бик ерак җирләргә китеп йөргәннәрен күрсәтә. Идел суындагы балыкларны тере килеш сулы мичкәләргә салып, Парижга җиткергән татар сәүдәгәрләрен искә алу җитә.

Җыентыкны төзүче – Мәдинә Рәхимколова.

Бераз аста русча язылган текстны тәрҗемәдә бирәбез:

«Китапта борынгы, әмма онытылмаган җырлар китерелә. Алар Егерменче гасырның башларында Ульян өлкәсенең Карамалы авылында; кайбер ләре Пенза өлкөсендә һәм Башкортстанның Миякә районы Олы Кәркәле авылында җырлана иде».

Мин бу җыентыктан укучыларга, сайланып тормыйча, алдагы беренче өч җырның текстын һәм Диләрә Шабакаева-Позднякова башкаруындагы ноталарын тәкъдим итәм. Сайланып тормыйм, дим, чөнки аларны үлемсез җәүһәр итеп тарих үзе сайлган.

АҺ, ЫРЫМБУР-КАЛА...

Аһ, Ырымбур-кала, сәхра-дала...
Күккә тиеп тора манара!
Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,
Бәлки күрешә алмабыз тиз ара.

Аһ, Ырымбур-кала, сәхра-дала...
Күккә тиеп тора Тора-тау.
Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,
Бәлки күрешә алмабыз исән-сау.
Аһ, Ырымбур-кала, сәхра-дала...

Елкылары чыкан бәйгегә.
Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,
Бәлки күрешә алмабыз мәңгегә...



СИН, МӘВИЯ КЫЗЫ...

Син Мәвия кызы булсаң,
мин Сөләйман җегете,
Тагы да кырык ел эзләсәң дә,
тапма минем кебекне. *(2 кат)*

Җыр җырлыйлар, сүз сөйлиләр,
килә безнең тиңебез.
Сак-Сок кебек саргаешып,
үтә безнең гомребез. *(2 кат)*

Якуб абый, хатлар язсаң,
сәлам куй син ярыңа.
Теләп сөйгән яр булмаса,
утлар чыксын малыңа. *(2 кат)*

Тәрәзәңнең пәрдәләре
нинди асыл коленкор.
Әти-әни сизде инде,
бер-ике көн килми тор. *(2 кат)*

Безнең кырның уртасында
борылып үсә бер бодай.
Теләгәнне, җан сөйгәнне
бирмәде бит бер Ходай *(2 кат)*.



ТУРАЙ АТ

Турай аткаем нидән аксый,
Аягында даганың ярасы.
Сөеп, сөйгән ярыңны ятлар алса,
Ярыладыр йөрәкнең парәсе.

Кушымта:
Ник юкка буй үстерден кыз булып,
Дарьяларга агасың боз булып.

Кара урманнарның уртасында
Карчыга аулыйдыр пибекне[1].
Ике дә кулыңа шәмнәр тотып,
Таба алмассың шундый ла җегетне.

Кушымта.

Кара урманнардан чыккан чакта
Камчы сабым калды ла каерылып.
Камчы сапкаем бер ни тәгел,
Сөйгән ярым калды ла аерылып.

Кушымта.



[1] Пибек – бу сүзнең мәгънәсе сүзлекләрдән табылмады. Күрәсең, җирле сүз. (А.Х.)

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның август ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Солдатлар тәшәккере [рәхмәте]

Гаскәри ахун Фәсыйх Мөхетдиновның рапорты сәбәпле, командующий войскаминың бу ел бәйрәмдә мөселман солдатларына рәсми рәвештә бәйрәм биргәнлеге өчен, мөселман солдатлар исеменнән прапорщик Мансуров, ахун Фәсыйх Мөхетдинов җәнапларына тәшәккер итеп, идарәбезгә хат яза.

Фәсыйх ахунның мөселман солдатларның дини ихтыяҗларын вакытында кайгыртуы аркасында, һәммә мөселман солдатлар гаеткә төшеп, өч көн рәттән шатлык илә бәйрәм иткәннәр. Пасха бәйрәмнәрендә дә бер генә көнгә бәйрәм бирелә торып, мөселман солдатларына өч көн бәйрәм иттерү чыннан да зур бер игътибардыр.

Кояш. – 1916. – №1003. – 4 август.

Абруй ханым концерты

Җомга көн Большой театр бинасында, «Сәйяр» труппасының чакыруы буенча, спектакльдән соң Абруй ханым концерт бирде.[1] Абруй ханым, гәрчә Уфа халкына таныш булса да, сәхнәләргә чыгып концерт биреп йөрүчеләрдән түгел. Әлегә кадәр без сәхнәгә менеп татар моңын ишеттерергә теләүчеләрнең бик күбесен беләбез. Ләкин, игътираф итәргә [кимчелекне танырга] кирәк ки, аларның һичберсе (мәрхүм Солтан Рахманколыйдан башка) безгә фәкать татар йөрәге илә генә аңларга мөмкин булган татар моңнарын бөтен хосусиятләре илә күрсәтә алганнары юк. Безнең җырчыларыбызның күбесе татар көйләрен яуропалаштыру фикеренә мөбтәля [дучар] булганнар. Шуның өчен безгә татар көен яуропалаштырабыз дип, такмаклар көенә җырланган әллә нинди мәгънәсез моңнар тәкъдим иттеләр. Абруй ханым хәзергә ул авырудан сәламәт икән. Аның тавышы көчле булмаса да, моңлы, тыңлар өчен күңелле генә тавыш. Иң зур хосусияте: татар моңнарын бер дә бозмыйча, үзгәртмичә, табигый рәвешендә күчерә алуыдыр. Фәкать татар көенә генә махсус булган һәм фәкать татар йөрәге илә генә тәкъдир ителә вә аңлана торган борылмаларны һәм буынлы-буынлы сузышларны Абруй ханым шулкадәр дөрес, табигый бирә алды ки, аның җырлавы аркасында бөтен татар халкының халәт рухиясен, тормышын күз алдына китерерлек бер тәэсир калдыра алды. «Бөдрә тал» һәм «Ком бураны» көйләре халыкның бигрәк хушына китеп алкышландылар. К.

Кояш. – 1916. – №1004. – 7 август.

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] «Кояш»ның 1003 санында: «Борынгы татар вә башкорт көйләрен саф рәвештә җырлау илә Уфа халкына танылган Абруй ханым бер мәртәбә концерт бирәчәктер. Борынгы көйләрдән «Аккош», «Бөдрә тал», башкорт «Тәфтиләү»е, «Тау башы», «Ком бураны» вә башкаларны җырлаячак», – дип хәбәр ителә.

Кул буе (мәдрәсәи «Касыймия») мәдрәсәсеннән

Бу ел мәдрәсәнең ибтидаи кыйсеме [башлангыч бүлеге] август 20сендә, шимбә көн ачылып, шәкертләрне мәктәп дәфтәренә кайдителә [теркәлә] башлап, 22 нче августта, дүшәмбе көн укулар башланачактыр. Ибтидаи сыйныфка шәкертләрдән айлык акча хәленә монасиб [яраклы] рәвештә тәгаен ителер. Мәдрәсә кыйсеме 10 нчы сентябрьдә ачылып, дәресләр 12 нче сентябрьдә, шимбә көн башланачактыр. Мәдрәсә кыйсемендә һәрбер шәкерттән 15 сум дөхулия[2] акчасы алыныр. Мәдрәсәгә керү өчен лязим шартлар: 1) кабул ителәчәк шәкертләр йогышлы авырулардан сәламәт булу; 2) һәр шәкертнең паспорты үзе белән бергә булу; 3) ашау-эчү һәм кием-салымга җитәрлек сәрмая сахибе [акча иясе] булу; 4) мәдрәсәдә пакьлек вә тынычлык саклау, төзелгән кагыйдәләргә ригая [игътибар] итәчәгенә ышану; 5) дөхулия акчаны тәмам биреп бетереп керү; 6) яңа шәкертләрне мәктәп вә мәдрәсә кыйсемнәренә кулларындагы шәһадәтнамәләренә карап сыйныфка тәгаен итеп, шәһадәтнамәсе булмаган шәкертләрне имтихан берлән дәрәҗәләренә муафыйк сыйныфка куелыр. Мәдрәсәгә керү өчен ибтидаи укудан мәгълүмат иясе булу тиешледер. Мәдрәсәи «Касыймия» идарәсе.

Кояш. – 1916. – №1007. – 14 август.

Гаскәри имам

Казанда «Вәрәсәи Хөсәения»[3] китапханәсе мөдире Габдессәлам әфәнде Катиев 31 нче Сибирский стрелковый полкның имамы булып хидмәт итә икән. Берничә көнгә Казанга кунакка кайткан. Уфага барып, Духовный Собрание хозурында имтихан кылыну ниятендә икән.

Кояш. – 1916. – №1008. – 16 август.

Мосафирлар тәнбиһе [кисәтүе]

Без, байтак мосафир, Бишбалта бистәсендә 1915 нчы елдан бирле торабыз. Бишбалтаның без тора торган җирендә мөселман кибетләре юк хөкемендә аздыр. Шуңа күрә безгә күп вакытта кирәк-яракны рус кибетләреннән алырга туры килә. Бу рус кибетчеләре бәгъзе вакытта алган нәрсәләребезне Коръән кәгазьләренә төреп бирәләр. Шулай ук русларга да төреп биргәлиләр. Без шундый бик күп Коръән кәгазьләрен аяк астыннан җыеп алдык. Аңлашылуына күрә, мөселман кардәшләр бу кәгазьләрне рус кибетчеләренә үзләре китереп саталар икән. Мөселманнар газиз Коръән кәгазьләренең нәрсә төрергә йөртелүенә вә соңгыннан аяк астына тапталуына үзләре сәбәп булмаска тиешләр иде.

Кояш. – 1916. – №1009. – 18 август.

Зиярәт өсте мәхәлләсеннән

17 нче мәхәллә хозурындагы (ягъни зиярәт өсте мәхәлләсе) мәдрәсәи «Мансурия»нең ибтидаи вә рөшди [урта] сыйныфларына сентябрьнең 1ендә шәкертләр кабул ителә башланачактыр. Мәдрәсәдә русский класс та бар. Шәкертләр сентябрь 10ына кадәрле кабул ителерләр. Аннан соң уку башланыр. Мәдрәсә идарәсе.

Кояш. – 1916. – №1013. – 28 август. ■

---

[2] Дөхулия – берәр җиргә керү өчен алына торган хак.

[3] «Вәрәсәи Хөсәения» – китапчы Шәмсетдин Хөсәенов варислары.

Вак-вак лəтыйфəлəр һəм хикəя кисəклəре*

***

– Доктор əфəнде, караңыз əле, минем малай ничек таза, ничек көр.

– Шулай да һəркөн сез аны ваннага утыртсагыз, зарарлы булмас иде.

– Нəрсəгə аңа ванна, ул болай да таза бит.

– Дөрест, ул таза, лəкин бик пычрак.

***

– Сездə кандала үтерə торган порошок бармы?

– Бар, күпмелек бирим?

– Хəер, бездə күпме кандала бар икəнен мин белмим.

***

– Син кайда булдың? Əллə ничə айдан бирле күзгə күренмисең?

– Иптəш, мин сəяси эш белəн төрмəдə утырдым.

– Нинди сəяси эш?

– Бер полицейскиның перчаткасын урлаган идем, шуның өчен утырттылар.

***

– Сезнең күмəчегездəн кичə бер папирос төбе чыкты.

– Синең өчен генə дүрт тиенлек күмəчкə сигара салып бирмəбез инде.

Ялт-йолт – 1913. – № 54. – Б.12-13.

РƏСЕМ БАЗАРЫНДА

Бер көн бер иптəшемə бик матур открытка алып җибəрим, диеп Проломный, Воскресенский урамнарын туздырып бетерсəм дə бер открытка таба алмадым. Керəм дə:

– Сездə открыткалар юкмы? – дим.

– Юк шул, – дилəр.

– Нишлəп бетте соң ул? – дигəч:

– Сезнең татар мөхəррирлəре үзлəренең рəсемле «журналлар»ына куярга алып бетерделəр.

---

* Лəтыйфə – мəзəк.

Шуннан соң гына мин безнең журналдагы рәсемнәрнең кайдан алынганын белдем. Юкса, мин алар рәсемне кайдан алалар икән, диеп бик аптырап йөри идем. Әле әйткәндәй, мин дә дурак шул, аларның сөйләнгән сүзне һич изах итмәгән, җыен чүп-чар рәсемнәр бастырып журналларын «рәсемле» иттерүләрен онытып йөрим икән...

Без дә исеме «рәсемле бит» дим дә үз-үземне җуатам.

БЕЗДӘ НИ ЭШЛИЛӘР?

– Ни эшләсеннәр? Итекче шагыйрь була, шагыйрь итекче була; мөхәррир итче була, итче мөхәррир була; наданнар мөхәррир була, галимнәр тик тора; аксак теләнче мөгаллим була, мөгаллим теләнче була; адвокат надан була, надан адвокат була; кулсыз рәссам була, рәссам кулсыз була.

Менә шушыларны уйлаганда Крыловның:

«Беда, коль пироги начнет печь
сапожник,
А сапоги тачать пирожник», –

дигән сүзләрен уйлыйсың да, харап булдык, диеп кенә куясың.

АДВОКАТТА

– Минем атайдан калган мениямне күршем дәгъвалый, шуны калдырырга юл бармы?

– Бар... Юридический эшләрне карый торган безнең кебек кешегә аны эшләү бик җиңел инде..

– Соң сез күпме алырсыз икән?

– Аңа мин әлләни күп алмам, 50 сум бирсәңез канәгать итәрмен.

– Соң инде инабәтледер бит?

– Ник инабәтле булмасын? Мин мәшһүр адвокатлардан чутланып йөрим, минем өстемә алган эшемнең һичберсе булмый калганы юк... Минем шушы адвокат булып торган кадәр гомеремдә бары бер генә оплошать иткәнем булды. Мин үзем бераүне судка биргән идем, судта тегенең файдасына хөкем иттеләр. Югыйсә...

– Туктагыз инде, господин адвокат, сез үз эшегезне проиграть иткәч, без илле сумны икенче бераүгә биреп торыйк инде...

Ялт-йолт. – 1913. №63. – Б.10-11.

БЕЗНЕҢ ГИПНОТИЗЁРЛАР

Профессор мөселман студентыннан сорый:

– Дөньяда мәшһүр гипнотизёр кем?

Студент:

– Безнең муллалар.

– Кит аннан!

– Ник? Чөнки безнең муллалар җомгада вәгазь укыган вакытта бөтен халыкны искиткеч дәрәҗәдә йоклаталар.

Ялт-йолт. – 1914. – №76. – Б.16.

ИПТӘШЛӘР АРАСЫНДА

– Әй, иптәш! Рузаны ничек үткәрәсең? То есть рузаны соблюдать итәсеңме?

– Как же соблюдать итмәскә! Әле мин өч көннән бирле ашаганым юк, ач йөримен.

Ялт-йолт. – 1914. – № 78. – Б.14-15.

ШАГЫЙРЬ ИЛҺАМЫ

Шагыйрь:

– Син кайчан гына мине кочакласаң да, миндә шигырь язу хисе уяна, сөеклем.

Мәхбүбә:

– И? Миңа моны синең кебек бик күп шагыйрь әйтә.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага
***Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Мирасворд

Борынгы сугыш киеме

Ауга өйрәтелгән бөркет баласы

... Сараи

Баласагунлы, Акчура

... Дәүли

Төркем, өер (иск.)

Татар халкында ярдәмләшү йоласы

Борынгы грек математигы

Арча районындагы авыл

Абхаз язма әдәбиятына нигез салучы

Шагыйрь Зыя ...

Итальян драматургы, Нобель премиясе лауреаты

Әстерхан чикләвеге

Гайнан ... (башкорт әдибе)

Язучы Мәгъсум Хуҗин туган авыл

... читек

Натрийның искергән атамасы

Телеканал

Сальвадор ... (испан рәссамы)

Азиядә яшәгән борынгы күчмә төрки халык

Шагыйрь Рәмис ...

Чыңгыз хан империясе таркалгач оешкан дәүләтләр исеме

Нәкъ (диал.)

Шагыйрь Харрас ...

Кытай (иск.)

Борынгы Римда коллар восстаниесе башлыгы

Госман, Миңнегулов

Төрле төстән буй-буй сугылган киндер

Грек хәрефе

Габдерәхим Утыз ...

Одиссей ватаны

Шигырьдә үзенә махсус рифмалы сигез юллы строфа

Коелган орлыктан үскән иген (диал.)

«... килде» пьесасы (Шәриф Хөсәенов)

Морза

Йомырка куырмасы

Язучы Иво Андричның милләте

Балавыз (иск.)

Пар

Казансуның сул кушылдыгы

Җайдак утыргычы

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Ширкәт», «Мәйдан», хис, макмал, угыз, мән, ала, Ясәви, баб, ут, Тәкмәк, «Бала», ила, «Афәт», «Маидә», Шаман, Мар, Гыйззәт, Сен, быр, Нух, әзәр, Даут, Ла, рун.

Өстән аска: яубашы, Бәл, Мостафа, сыза, Ләмберә, Шамуков, ата, «Рәйхан», тил, Дилә, әл, ым, әсас, Мокамай, ода, арзу.

Рәис Габдулла төзеде.

Җамигъ мәчетенең бер өлеше. Ленинград. 1920-30 еллар

«Безнең мирас» *елъязмасы / август*

• 465 ел элек (1551)

14 августта Мәскәү-Казан солых килешүе төзелә.

• 170 ел элек (1846)

17 августта данлыклы татар сәүдәгәре Мөхәммәтзакир Габделкәрим улы Апанаев (1846-1912) дөньяга килә.

• 130 ел элек (1886)

17 августта Казанда һөнәрчелек һәм авыл хуҗалыгы күргәзмәсе ачыла.

• 95 ел элек (1921)

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының Әдәбият бүлеге (Лито) татар әдәбияты буенча лекцияләр циклы оештыра. Лекцияләр укуга Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин һәм Хуҗа Бәдигый җәлеп ителә.

• 85 ел элек (1931)

10 августта күренекле милләтпәрвәр, хакимият-хуҗалык җитәкчесе, техник фәннәр докторы Әхмәт Мөхетдин улы Галиев (1931-2015) дөньяга килә.

• 80 ел элек (1936)

Август башларында үзбәк язучылары Әмин Гомәри, Гафур Голәм һәм Шакир Сөләйман Татарстандагы мәдәни төзелеш белән танышу һәм Татарстан турындагы әдәби әсәрләргә материал туплау өчен башкалабыз Казанга килә.

75 ел элек (1941)

28 августта Татарстанның Балтач районы Кормала авылына эвакуацияләнгән эстон язучысы Оскар Ургарт, татар әдәбияты белән танышуда ярдәм кылуларын үтенеп, Татарстан Язучылар союзы идарәсенә мөрәҗәгать итә.

50 ел элек (1966)

«Казан утлары» журналында Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» исемле повесте дөнья күрә. ■



СОДЕРЖАНИЕ:

Историческое наследие: «Булгар. Ханская палата»; «Новые источники о Хади Атласи». И.Гафаров; «Дом Юсуфа Акчурина». Н.Таиров, И.Таиров; «Постановление 20-22 февраля 1901 года Святого Синода об обращении Православной Греко-Российской Церкви к верующим детям и о графе Льве Толстом»; «Ответ на постановление 20-22 февраля Святого Синода и на письма, адресованные мне, по данному случаю». Л.Толстой.

Татарский мир: Интервью Л.Лерона с И.Гильмутдиновым.

Татарские эмигранты: «Хамит Зюбеир Кушай». Ф.Гаффарова.

Литературное наследие: «Кутадгу билик». (Благодатное знание). Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана». Ч.Айтматов; «Сабирзян агай: роман, повествующий о голоде 1906 года». К.Биккулый.

Творческое наследие: «Луч творчества на лучезарной сцене». А.Зарипов; «Светлой души великий певец». А.Хакимова

В глубине памяти: «Наследие ТАССР»;

Татарская песня: «Терпение, рожденное печалью». А.Халим;

100 лет назад…: «Казанские вести» в газете «Кояш»: август 1916 года».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

Historic heritage: «Bulgar. The khan's chamber» by N.Shaydullina; «The new origins about Khadi Atlasi» by I.Gafarov; «Yusuf Akchurin's house» by N.Tairov, I.Tairov; «20-22 February, 1901 resolution of St. Synod about Orthodox Greek-Russian church's appeal to the faithful children and about the count Leo Tolstoy»; «My response to the 20-22 February resolution of St. Synod and letters addressed to me on this occasion» by L.Tolstoy.

Tatar world: The interview by L.Leron with I.Gilmetdinov.

Tatar emigrants: «Khamit Zubeir Kushay» by F.Gaffarova.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov (novel); «Sabirzyan agay: a novel telling about the hunger of 1906» by K. Bikkuliy.

Creative heritage: «The sparkle of art on the radiant stage» by A.Zaripov; «The great singer of pure soul» by A.Khakimova.

From the depth of memory: «Heritage of TASSR».

Tatar song: «The patience born by the grief» by A.Khalim.

100 years ago … : «Kazan news» is in the «Koyash» («The sun») newspaper: August of 1916».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Әлфия Ильясова

Әлфия Ринад кызы Ильясова 1967 елның 20 октябрендә башкалабыз Казанда туа. Казан сәнгать училищесын (1986), Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын (2014) тәмамлый. Әлфия Ильясова – Татарстанның (1992) һәм Россиянең (1993) Рәссамнар берлеге әгъзасы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2011). Рәссамның әсәрләре 1986 елдан бирле төбәкара, республика һәм халыкара күргәзмәләрдә катнашып килә.

«Бакчасарай. Хан сараеның хатын-кызлар ягы». Киндер, темпера. 2015 ел

«Болгар ир-аты». Аутентик агач, левкас, майлы буяу. 2015 ел

«Нур сибүче Әл-Борак». Аутентик агач, левкас, майлы буяу. 2015 ел

АЛДАГЫ САННАРДА:

Чыңгыз Айтматов. «Чыңгызханның ак болыты»
Әзһәр Мөхәммәдиев. «Зөләйха»
Гали Гатауллин. «Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы»
Һади Максуди мәкаләләре
Атилла Расих. «Дөньяда сүзем калыр...»
Рүзәл Мөхәммәтша. «Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре»
Фәридә Гаффарова. «Сания Гыйффәт»
Мәгъсум Хуҗин – истәлекләрдә
Тәэминә Биктимерова. «Габдулла Гыйсмәти»

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172